**Роберт Миңнуллин**

**Әсәрләр**

Җиде томда

4 том

Балалар өчен шигырләр,

Кечкенә әкиятләр,

Ирекле тәрҗемәләр,

Төрле язмалар

КАЗАН

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ

2007

УДК 821.512.145-1:3

ББК 84 (2 Рос=Тат)-5:4

М46

Редколлегия:

З.Р.Вәлиева, Р.А.Ратников, Ш.Г.Галиев, И.М.Ибраһимов, Д.С.Шакиров, Р.Х.Корбанов, Х.Г.Әюпов

**Миңнуллин Р.М.**

Әсәрләр: 7 томда / Роберт Миңнуллин. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2007.

4 т.: Балалар өчен шигырьләр, кечкенә әкиятләр, ирекле тәрҗемәләр, төрле язмалар / кереш сүз авт. Ш.Галиев. — 2007. — 2000 д.

Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Татарстан Дәүләт премиясе, М.Җәлил исемендәге яшьләр премиясе һәм Г.Х.Андерсен исемендәге халыкара Почетлы диплом ия-

се Роберт Миңнуллин әсәрләренең бу томында аның балалар өчен шигырьләре, тәрҗемәләре һәм төрле язмалары урын алды.

ISBN 978-5-298-01623-0 (4 т.)

ISBN 978-5-298-01612-4

© Татарстан китап нәшрияты, 2007

© Миңнуллин Р.М., 2007

Сөенсеннәр әле сабыйлар

Мәктәпләрдә туган телебезнең тыны беткән чорларда «Туган тел»не гимн итеп, эчке бер бирешмәү, сагышлы тантана һәм өмет белән җырлый идек. Татар телендә укытучылар һөнәр алыштырырга мәҗбүр елларда ана телебез өзелмәгән соңгы мәктәп Балалар әдәбияты булды. Фидакарьләр максатка тугры иде — сабый күңеленә шигъри сүз булып кереп калырга, онытылудан сакларга тырыштылар. Шул сирәк сафтагылар арасында, укытучыларча әйтсәк, Роберт Мөгаллим улы Миңнуллин да бар. Мөгаллим улы... үзе дә укытучы. Сабаклары: телебезгә мәхәббәт, кешелеклелек тәрбияләү. Балалар әдәбиятында Г.Тукай, Б.Рәхмәт, Ә.Фәйзи традицияләрен дәвам итеп шушы жанрда да үзенчәлеген тапкан талантлы шагыйрь. Форма ягыннан оста һәм кызыклы, эчтәлеге белән мавыктыргыч ачышлары бар.

Бүгенге мең дә берне белүче баланы авызыңа-әсәренә карату өчен ни сөйләвең, ничек язуың бик мөһим. Шагыйрьне, күңелдәш итеп таныйлар икән, хикмәте — әсәрләренең балачакның үзедәй табигый булуында. Күзендә — ярату, сүзендә мөлаемлык күрәләр, димәк. Рухи «дефицитка» — ачык колач, ачык күңелгә, үзен аңлаучыга тартыла балалар. Канат астына борын төрткән бәбкә сыман, сабыйлар да җан җылысы эзли...

Р.Миңнуллиндай балачагын онытмаганнар күп түгелдер. Кеше дигән адәм баласы сәер бит ул: иң яхшы хәтерләгәне балачагы аның, «онытканы» да шул, баласы хәлен аңламый башлый, уртак тел табалмый! Сәбәбе — тигезсезлектә, җәмгыятебездә таралган чир — түрә булып, командалык итеп, «акыллы күрсәтмәләр» биреп өйрәтүдәдер? Ата-ана белән бала арасында читләшү дигән «Берлин стенасы» шулай үсә. Шул стена артында аерым утрау булып яшәүче балалар бакчасы, биегрәк рәшәткәле мәктәп, аннары... чәнечкеле коймалы балалар колонияләре... Читләшү еш кына бусына да китерә...

Әле дә, бәхеткә, баланың күңел «телен» аңлаучы «сакаллы сабыйлар» бар. Робертның популярлык сере дә әнә шул балалар белән уртак сыйфатларында — ихласлык, тапкырлык, шаянлыкта. Юмор торгынлык елларында да рәсмилектән тәмам гарык бала күңелен, әдәбиятын сәламәт саклаган хасият булды. Шигырьләрендә олылар дөньясына, тормышка тоташтырган бик гадәти күренгән чара да шул. Юмор, сатира — рухи хөрлек, бәйсезлек билгесе, демократия юлдашы.

Робертның балаларга әйтер сүзе — китаплары — бер-бер артлы чыга тора. Шулардан инде укучылар яратып өлгергән соңгыраклары Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә тәкъдим ителде. Менә алар: «Безнең авыл зоопаркы» (1988), «Җәйнең

яшел аты» (1987), «Балачак бәйрәмнәре» (1985), Мәскәүдә русчага тәрҗемәдә дөнья күргәннәре: «Наш тигренок» (1987, «Малыш» нәшрияты), «Глядит в окошко человек» (1986, «Детская литература» нәшрияты). Бусында Сергей Михалковның кереш сүзе бар: «Күңелсез китапларны, гәрчә алар бик файдалы һәм акыллы булса да, беркем укырга яратмый. Роберт Миңнуллин күңелле һәм кызыклы итеп яза. Бик рәхәтләнеп укыдым...» — дигән атаклы «Степа абый»ның авторы. Робертның шигырьләре илебездә төрле телләргә тәрҗемә ителде. «Детская литература» журналында яхшы бәя алды, шунда ук аның иҗат портреты да басылып чыкты.

Югарыда әйтелгән «Балачак бәйрәмнәре»н укыгач, Сибгат ага Хәким дә аны балалар әдәбиятының казанышы дип бәяләде. «Социалистик Татарстан» газетасының 1985 елгы 21 декабрь санында Р.Миңнуллин иҗатын күзәтеп: «...җырларын яратуыма карамастан, башлап аның балалар өчен язылган шигырьләре турында фикер әйтергә булдым», — диде өлкән шагыйребез. Балалар әсәрләрен олылар да укуын истә тотып, татар халкында «бер миллионга бер балалар шагыйре туры килә» дигән кызыклы чагыштыру әйтте. Сирәк сәләтләргә аеруча игътибар кирәк, диюе иде. Халык шагыйренең «Гөлҗәүһәрнең оныклары» исемле әлеге мәкаләсе милләтебезнең бүгенге һәм туар онықларын да кайгыртуы иде. «Ә балачак шушындый «Бәйрәмнәр»дән башлана. Мин мондый бәйрәмнәрнең күбрәк булуын теләр идем», — дигән сүзләре соңгы теләге булган икән — вафатына ярты ел гына калган... Шагыйрь урамына бәйрәм килүен күреп әле дә сөенер, хуплау сүзләре табар иде Сибгат ага.

Адәм баласы гомере буе балачак тойгы-тәэсирләре белән «туенып» яши. Әйтик, безгә әнис орлыгының тәме рәхәт болыннарны, печән өсте бәйрәмнәрен хәтерләтә. Нәни бөртеккә болын сыйган, болында — балачак! Шул истәлек күңелне имин матурлыкка көйләп, иркәләп тора... Шәһәрдә үскән берәүгә орлыкны бирәм, тәмләп карый да, сәерсенеп йөзен чыта... Балачак хәтерендә юк ул аның, болын тулы ямь юк, сагынырлык тәм юк...

Бала чакта укылган шигырьләр дә нурланып күңел төбендә ята. Өлкәнәйгәч тә тормыш «тәмләткеч» буларак кирәк алар, әйбәт күңелле булу өчен кирәк. Р.Миңнуллинның шигъри болынында андый хис-әнисләр күп. Халык иҗатының шифалы чәчәкләренә, сүз хәзинәләренә, күркәм гореф-гадәтләр, сабан туйларына тоташкан әсәрләр алар. Авылдамы, шәһәрдәме, шул тәмнәрне татып үскәннәрнең балачак бәйрәмнәре гомергә истә калыр.

Күңелле, тыныч, имин булырга тиеш балачак. Уены-чыны бергә, мәгънәле гамәлләрнең кызыгын-тәмен белеп калсын бала. Матурлыкны танып, шәфкать-миһербанны тоеп үссен. Хыяллар канатланып үзенә ышаныч туган, шәхес нигезләнер зур бер дәвер бу. Роберт иҗатында әнә шул эзләнүчән, бер үк вакытта тыныч та, тынгысыз да, хәвефле дә балалар дөньясы. Безнең балалар әдәбияты, бүтәннәргә караганда, тормышка якын булуы, борчыган, җанга тигән мәсьәләләрен күрсәтүе белән көчле. Авторның менә бу шигыренең исеме, белеп торам, сәеррәк тоелыр: «Кечкенә бер авылдагы кечкенә бер башлангыч мәктәптә укучы кечкенә малайлар турындагы моңсу шигырь»... Кечкенә дә кечкенә... ә бит зур проблема! Шигырьнең озын-зур исеме үк шуңа ишарә.

Беләсезме, ничәү без?

Бөтенебез — бишәү без!

Биш партада — бишебез.

Мәктәптә биш кеше без! —

ди әлеге «перспективасыз», ягъни киләчәксез авылда укучы бала. Бишәү — бер кул бармаклары гына — сыңар кул... Киләчәксез авыл «перспективасыз тел» дигәндәй сискәндерә...

Робертның шигырьләре туган телнең гомерен озайта торган чын, саф, халыкчан телдә язылганнар. Сурәтләнгән малайлар-кызлар да шуңа җанлы-җисемледер, шуңа яраттырадыр. Нинди сыгылмалы, тере, канатлы сүзләре очып-уйнап торган телебез бар, дип шөкрана кылып куясың. Рәвешең, рухың, иманың телдә, бабайлар васыяте, яшәү догасы ул. Шагыйрь юктан да кызык таба кебек. Юктан түгел — сүздән таба, сүз эчендәге хикмәтне табарга өйрәтә. Кайчакта шигырь баланың хәйләсез сөйләме сыман. Алданма. Хуҗа Насретдиндай беркатлыга салышкан тиктормасның сынап каравы ул! «Балалар шагыйре булып туарга кирәк», дигәнне телгә талант дип тә аңлыйм. Бәхетең шунда. Бәхетсезлегең дә — булмаса, кемгә үпкәлисең... Балалар шигырендәге урынсыз бер сүз дә тәгәрмәч астындагы таш сыман шигырь-арбаны аударуы ихтимал...

Р.Миңнуллин сынчы оста турындагы бер шигырендә «тылсымчы» дигәнне «тылсынчы» дип уйната. Сүз белән сын тудыручы буларак аның үзен дә «телсынчы» дияргә була.

Шигырьләре җанга ятышлы, җырга ятышлы — композиторлар бик теләп көй язып торалар. Балаларга дигәннәре дә өч-дүрт дистәдән артыктыр. Бүләккә күрсәтелгән китапларда да бар алар. Шунысы кызык, балалардан кайчак өлкәннәр эләктереп ала. Әйтик, «Әни кирәк» җыры шулайрак булды. Хәер, балалар да аптырап калмый — әниләр турындагы бүтән җырларны бер дә өлкәннәрнеке дип тормыйлар. Әле әти-әниләр белән бергәләп җырлаганнары күпме! Бигрәк әйбәт, уй-тойгылары бер дигән сүз, шагыйрь уртак хисләр тапкан. Бу җырлардан япа-ятимнәрнең үзәге ничек өзеләдер дип уйланып каласың.

Тормыш тоташ бәйрәм түгел шул. Кырыслыгын, каршылыкларын да яшерми шагыйрь. Нәкъ менә шуларны җиңү өчен күңел тотрыклыгы кирәк, көчле булып үссеннәр, шыңшып-бөрешеп яшәрлек булмасыннар, ди. «Мин көрәшергә тиеш!» җырындагы малай шундый:

Көрәшче булган бабамнар,

Көрәшче мин үзем дә.

Ә минем кебек малайлар

Меңләгән җир йөзендә, —

дип әйтә ала ул. «Малайлар сөйләшә» шигыренә колак салыйк, әнә ничек уй йөртә замана балалары: «Ә мин начальник булам, йөрим «Волга»да гына!», «Ә мин кибетче булам!» — дип һөнәр сайлаучы яшьтәшләрен тыңлап, берсе: «Ә миңа әни үскәч куша КЕШЕ булырга» — дип үзенчә йомгаклап куя. Намус, вөҗдан, әхлак, әдәп дип сөйләшмәсәләр дә, гомергә нинди буласылары шушы сабый чакларда хәл кылына, юллар сайлана...

«Әйдәгез, дуслашабыз!» дигән җыр милләтара мөнәсәбәтләр кискенләшкән бер вакытта аеруча актуаль яңгырый:

Җирне саклап калалмабыз

Дуслашмаган килеш без.

Шуңа күрә барыбыз да

Дус булырга тиеш без!

Мәңге какшамас тоелган чакырулар гамәлдән төшкәндә дә шагыйрьнең бер шигыренә исем иткән «Бөтендөнья балалары, берләшегез!» дигән өндәве үз көчендә калыр. Тату булсыннар, дөнья аларга, алар яшисе, киләчәк аларныкы. Роберт шигырьләрендә бүгенге яшәешебезнең кайнар сулышы бар, тематикасы тормышның төрле якларын колачлый.

Р.Миңнуллин турында, балалар язучысы, дип язам. Беләсез, танылган олылар шагыйре дә ул. Лирик Роберт уйчан, тирән хисле, балалар Роберты зирәк, җитез, шаян вә наян. Рәхмәт инде, юмор-күчтәнәчләрен балаларга дип саклап тора. Ике Робертны ярыштырмастан, балалар өчен эшләгәнен әдәбиятыбызда вакыйга дип саныйм. Ул моны ике дистә еллык иҗаты белән раслап килә. Анда-санда балалар өчен язгалаган каләмдәшләргә дә рәхмәт. Әмма Роберт тумыштан балалар шагыйре, аның гомерлек максаты шул.

Язучының иң зур җәмәгать эше — иҗаты дип саныйм. Әлбәттә, савапка эшләнә торган бүтән бурычлары да аз булмый. В.И.Ленин исемендәге Совет балалар фондының Татарстан бүлеге идарәсе рәисе буларак Р.Миңнуллинның үз вазифасын ничек үтәвен күрергә туры килә. Кем әйтмешли, үзең түземлек бир: ятимханәләр, ятимнәр хәлен, имгәтелгән язмышлар фаҗигасен, аһ-зарын, күз яшьләрен, мохтаҗлыгын күңелгә сыйдырырга, күтәрергә кирәк... Ул нарасыйларның һәркайсы: «Кайсыгызның кулы җылы? Бәйлисе бар йөрәкне...» — дия алыр иде. Роберт абыйларының кулы җылы, тулы ятимнәрне генә түгел, таш бәгырьләр ташлаган әниледән әнисез, әтиледән әтисезләрне дә кайгырта...

Балалар фонды оешу турында сүз чыккач та Татарстан бүлеге рәисе итеп Р.Миңнуллинны уйлаган идем. Балаларны кайгыртып телевидениедә күп еллар «Шигъри тәлгәшләр» тапшыруын оештыручы, бердәнбер балалар газетасы «Яшь ленинчы» редакторы, балалар әдәбияты секциясе җитәкчесе, танылган балалар язучысы... Бала җанлы, күркәм сабырлыкка ия кеше. Рухи халәте белән үз яшеннән олы тоела ул миңа. Сыңар канат — яшьли әтисез калу өлгерткән, бүтәннәрне кайгыртырга, җаваплылыкка өйрәткән. Сугыш чоры балаларына — безнең буынга бик таныш бу...

Әле генә булып узган сайлауларда Р.Миңнуллинның Татарстан Югары Советына депутат итеп сайлануын халыкның ышаныч белдерүе һәм аңа җаваплылык өстәве дип карыйм.

Каян ала әдип көчне, илһамы нинди чыганаклардан?

Туган җир көч бирә, дип язабыз. Туры мәгънәсендә дә шулай икән. Галимнәр сынап караган: имәнгә сөялеп торсаң, куәтең арта — туган җир үз көчен сиңа күчерә икән. Шул хакта укыгач, бер фоторәсем күз алдыма килде. Еш күрәм мин аны: мәһабәт гәүдәле дәү әтисенең аякларына сыенган малай... Ул да бит дәү әтисе аша үзе күрмәгән бабаларына тоташкан, ә нәсел-нәсәбе белән милләтенә, туган җиренә береккән — дәрман алып тора. Тамырлары тирәндә, буыннар, гасырлардан килә рухи кодрәт... Борынгылар, шәҗәрәне «нәсел агачы» дип бик белеп әйткән: көч бирә торган мәңге тере имән ул!

Туган тел язмышы, милләтебез яшәве турында ачыктан-ачык борчулы сүз барган бу елларда балалар тәрбиясенә, әдәбиятына игътибар артты, Тукай бүләгенең «Балалар әдәбияты һәм сәнгате әсәрләре өчен» дип махсус тәгаенләнгән булуы — моның бер чагылышы. Әйе, зур бүләккә вакыйга булырдай әсәрләр генә лаек. Бүген безнең балалар әдәбиятында андый автор бар. Ул — шагыйрь Роберт Миңнуллин дип ышанып әйтә алабыз.

Шәүкәт Галиев

1990

Очасым килә!

Кызык кеше

Бәләкәй чакта мәктәптә

Ул бик әйбәт укыган.

Кызлар белән утырса да,

Бик тәртипле утырган.

Ә шулай да кайчагында

Дәресе калгалаган,

Аннан

Математикадан

«Өчле»ләр алгалаган.

Еларга яратмаса да,

Аны еш елатканнар,

Еш кына елатсалар да,

Үзен бик яратканнар.

Ул әле дә үзен кеше

Ярата диеп белә.

Килешмәсә дә, йөри ул

Эшләпә киеп кенә.

Бик аз сүзле —

Бер дә юкка

Бик көенми ул артык.

Шөгыльләнми спорт белән,

Шуңа бераз юантык.

Бераз гына юан булу

Аңа бик тә килешә.

Кызлар гына, аны күргәч,

Ни өчендер көлешә.

Ул бик озын буйлы түгел,

Һәм бик үк кыска түгел.

Уйнаган була гармунда,

Ләкин бик оста түгел.

Бик оста уйнамаса да,

Ул күңел биреп уйный.

Һәм үзен, ни сәбәптәндер,

Талантлы диеп уйлый.

Балалар аны тиз таный,

Ә күбесе белми дә.

Шигырь укып көлдерә ул,

Үзе никтер көлми дә.

Сәхнәгә бер чыгып басса,

Сибә генә борчакны.

Ул үзе начар да түгел,

Шәп тә түгел ул чаклы.

Ул ипи дә бик ярата,

Үзе үстермәсә дә.

Хәтта кәнфит ашый!

Хәер,

Ансы башка мәсьәлә...

Шундый кызык бер кеше ул!

Кем дисезме?

Мин ул, мин —

Шагыйрь Роберт Миңнуллин.

Вакытында йокларга ятмаган,

йокларга яратмаган кайбер шаянрак

малайларга махсус язылган бишек җыры

Күрәсеңме, соң инде,
Кайчан ятасың инде?
Тәрәзәгә карале! —
Тышта нинди караңгы.

Әлли-бәлли-бәлли-бәү,
Минем улым инде дәү!
Йом инде, йом күзеңне,
Тыңла инде сүземне.
Син бит минем бердәнберем,
Бик яратам үзеңне!

Телевизор караудан,
Балам, кайчан туктыйсың?
Соңгы тапкыр кабатлыйм —
Йоклыйсыңмы, юкмы син?

Әлли-бәлли-бәлли-бәү,
Минем улым инде дәү!
Йом инде, йом күзеңне,
Тыңла инде сүземне.
Тыңламасаң, калдырам да
Ташлап китәм үзеңне!

Иптәшләрең күптәннән

Йоклый торгандыр инде,

Төнге сәгать унике

Күптән тулгандыр инде.

Әлли-бәлли-бәлли-бәү,

Минем улым инде дәү!

Йом инде, йом күзеңне,

Тыңла инде сүземне!

Тыңламасаң, бабайлар

Алып китәр үзеңне!

Уйнадың көн буена,

Һаман уйныйсың, балам.

Шаярудан, уйнаудан

Ничек туймыйсың, балам?

Әлли-бәлли-бәлли-бәү,

Минем улым инде дәү!

Йом инде, йом күзеңне,

Тыңла инде сүземне!

Тыңламасаң, чыбык белән

Сыйлыйм хәзер үзеңне!

Иртәгә дә мәктәпкә

Соңга каласың инде.

Соңга калгачтын, тагын

«Берле» аласың инде.

Әлли-бәлли-бәлли-бәү,

Минем улым инде дәү!

Йом инде, йом күзеңне,

Тыңла инде сүземне!

Тыңламасаң, каеш белән

Яткырам бит үзеңне!

Ә-ә-ә-ә-әәә...

Дөньядагы иң зур алма

Бу юлы сезгә

Мактанып тормыйм.

Сөйләгәндә дә

Берни арттырмыйм:

Мин бит, малайлар,

Зур алма таптым,

Ул зур алмага

Үзем шаккаттым!

Шундый зур алма! —
Исең китәрлек,
Бөтен авылны
Кунак итәрлек!

Белмим, ул ничек
Шулай уңгандыр?
Ул җирдә иң зур
Алма булгандыр.

Тотарлык түгел
Ике куллап та.
Таба алмадым
Сезне юллап та.

Шуңа мин сезне
Көттем-көттем дә
Кайтардым өйгә
Тәгәрәттем дә!

Чынлап зур иде,
Алдамыйм сезне.
Ә ул зур алма
Кайда, дисезме?

Тәмле иде шул —
Бетте, калмады.
Бер генә каптым
Мин ул алманы!

## Архимед белән Спартак

Безнең авыл — данлы авыл,
Ышанасыңмы, туган:
Архимед та, Спартак та
Безнең авылда туган!

Беләм әти-әниләрен,
Беләм бабаларын да.
Туганнары авыл тулы —
Беләм мин аларын да.

Аларның ничек үскәнен
Бигрәк тә әти белә,
Чөнки алар икесе дә
Укыган әти белән.

Икесе дә безнең урта
Мәктәптә укыганнар.
Икесе дә бер партада
Янәшә утырганнар.

Архимед физикадан гел
«Өчле»ләр алгалаган.
Ә Спартак ярышларда
Гел артта калгалаган.

Ә шулай да мактый халык.
Чыннан да мактарлык та —
Спартак Гапсаттаров та,
Архимед Акмалов та!

Малайлар бәйрәме иде...

Шушы Гөлнар аркасында
Әй хурлыкка калдым ла!
Бөтенесе алдында бит,
Бөтен класс алдында.
Малайлар бәйрәме иде.
Минем янга килде дә,

Елмайды да, көлде дә,

Тоттырды миңа бүләк.

Бар класс куйды гүләп!

Малайлар: «Ухxx!» — иттеләр,

Ә кызлар: «Ахxx!» — иттеләр.

Телсез калдым мин үзем,

Кызарды бугай йөзем,

Агарындым аннары,

Каралды күз аллары...

Кызык түгел калганы...

Гөлнарны әйтәм әле —

Миннән көләдер әле.

Ярар, ярар, үзе дә

Берәр эләгер әле.

Ул әле хур булачак —

Күзләре дүрт булачак!

Алдымда бер кызарып,

Бер агарып торачак!

Алай хур да иттергәч,

Ачуны да китергәч,

Берәр җае чыкканны,

Ярар, көтәрмен әле —

Үзенә иң матур чәчәк

Бүләк итәрмен әле!

Моннан ары Гөлнар да

Йөри алмас шат кына...

Җитсен әле, җитсен әле

8 нче Март кына!

Мактанчык

Минме?

Су астындамы?

Рәхәтләнеп торалам.

Кирәк икән, тын алмыйм.

Кирәк икән, тын алам.

Бер минут та торалам,

Бер сәгать тә торалам!

Ике сәгать, өч сәгать

Тора алам кимендә...

Водолаз киемендә!

Спортның яңа төре

Спорт өчен тугандыр ул,

Шул спорт — бөтен эше.

Спорт төрләренең Алмаз

Ярата бөтенесен.

Спортның телевизион

Төрләрен ул бигрәк тә

Нык ярата һәм мавыга

Көннәр буе — кирәктә!

Калдырмый ул хоккеен да,

Футбол, волейболын да,

Баскетболын, мотоболын,

Тагын... ягъни барын да!

Аннан тотына тенниска,

Бөтен эшен ташлый да.

Ә нәфис гимнастиканы

«Ясый» ашый-ашый да.

Иртәнге гимнастиканы

Ясый ул ятып кына.

Тик озаграк ятып булмый —

Кыскарак вакыт кына.

Күренеп тора Алмазның

Авыр атлет икәне.

Шуңа күрә калдырмый ул

Авыр атлетиканы.

Җиңел атлетиканы да

Карап бара — калдырмый.

Анысының зыяны юк —

Җиңел булгач, ардырмый.

Көн буена спорт, спорт...

Юк, барыбер арый ул.

Хәлсезләнә, хәлдән тая,

Ә шулай да карый ул.

Ә телевизор карарга

Сәбәп чыгып тора шул.

Әмма Алмаз түзә һаман —

Спорт чыныктыра шул!

Күңелем дә гөл кебек

Гөлгә дә гел якты кирәк,

Торсын өчен гел көлеп.

Әллә үзем дә гөл микән? —

Күңелем гел гөл кебек.

Тәрәзәгә баккан саен

Яктырамын көн кебек.

Ничә көн инде минем дә

Тәрәзәдә күзләрем.

Шушы якты тәрәзәдән

Алып булмый үзләрен.

Белмим, кемне көтүемдер?

Белмим, кемне күзләвем?

Хаталар өстендә эшләү

Дәрестә без узгандагы
Хаталарны төзәтәбез:
Кайбер сүзне үзгәртәбез,
Кыекларын төзәйтәбез,
Хаталарын табалмасак,
Күршеләрдән эзләтәбез.
Дәрес бетә башлаганда,
Төзәтүне тизләтәбез!

Сызгалыйбыз, бозгалыйбыз,
Үз хатабыз — кызганмыйбыз!

Ә югыйсә язган чакта
Гел «бишле»лек бер эш иде —
Бөтенесе дөрес иде!

Ә тикшергәч, ачыкланды:
Күп сүз дөрес язылмаган.

Кирәк сүзләрнең астына
Ни өчендер, сызылмаган,

Иң кирәкле җөмлә никтер
Кызыл юлдан башланмаган,
Артык хәреф, артык өтер
Никтер сызып ташланмаган.

Табылмаган күзәтүче,
Вакытында төзәтүче...

Инде менә хаталарны,
Инде ничә кат аларны
Төзәтәбез янып-пешеп,
Ялгыш язган сүзләрне без
Үзгәртәбез тиргә төшеп...

Иншаны да, диктантны да
Язулары уен икән.
Хаталарны төзәтүе
Язганнан да кыен икән!
Муса Маликов булсам...

Мин дә Маликов булсам,
Маликов Муса булсам,
Сәләтле Муса булсам,

Сәнгатьле Муса булсам,

Әтием җырчы булса,

Әнием җырчы булса,

Яңадан җиде тулса,

Түбәтәем дә булса,

Ул килешеп тә торса,

Алкышларга күмсәләр,

Яратсалар, көлсәләр,

Шундый гармуным булса,

Шундыйрак моңым булса,

Җыр белән дус та булсам,

Җырларга оста булсам,

Матур итеп җырласам,

Оялып та тормасам,

Тавышым булса матур,

Тавышым булса көчле,

Их, мин дә җырлар идем

Маликов Муса төсле!

Булмас инде...

Булсам да,

Була алмам җырчы да,

Була алмам Муса да...

Нишләсәм дә... ни инде...

Мусага җитми инде!

## Зонтик

Зонтик алган әни миңа —
Их, яңгыр яусын әле!
Кызлар кызыккан булалар,
Күзләре янсын әле!

Кызганмыйм ла зонтигымны —
Ярар, алыгыз инде,
Яңгыр ява башлаганчы
Уйнап калыгыз инде!

## Җәйне озатканда

Җәй җыена ерак юлга,
Җәй җыена китәргә.
Җәйнең әйләнеп кайтканын
Тагын күпме көтәргә?

Әллә җәйне озатканга,

Чык кына чәчәк, үлән.

Озатабыз җәйне менә

Үз чәчәкләре белән.

Базда – сигезаяклар!

Әти язын

Өйнең базын

Карый әнә ачып-ачып.

Күзен анда без бәрәңге

Салган идек капчык-капчык.

Үзе ача,

Үзе кача —

Белмим, аңа нәрсә булган?

Мин дә базга баккан идем —

Базга әллә нәрсә тулган!

Бәрәңгеләр

Болганалар,

Әйләнәләр,

Тулганалар —

Караңгыда ята-ята

Сигезаяк булган алар!

Бүре җиләге

Җиләкләр

Кызыл гына.

Әй тәмле —

Сузыл гына!

Үзләре

Кызыктыра,

Күзләрем

Кызып тора.

Мин күптән

Күзлим инде,

Шулай да

Өзмим инде.

Бүре үзе

Ашасын,

Мин табармын

Башкасын —

Татлы булып

Үскәнен,

Кызарыбрак

Пешкәнен.

Үзе үрелсен бүре

Үзенең җимешенә.

Нигә тиим ди әле

Мин кеше өлешенә?!

Кәрзин кая эленгән?

Кәрзинне мин ботакка

Элгән идем урманда.

Кәрзинем дә, ботак та

Юк булды тик торганда.

Бик озак йөрдем күзләп,

Шул кәрзинемне эзләп.

Эзли торгач таптым да,

Таптым да, шаккаттым да.

Күренәме күземә?

Аптырадым үзенә —

Элгәнмен кәрзинемне

Мин болан мөгезенә.

Сыбызгы җил

Урамда җил

Сызгыра,

Шундый җилле

Сыздыра,

Хәтта тузан

Туздыра,

Хәтта мине

Уздыра.

Сыбызгысы

Шәп бигрәк —

Нәкъ минеке

Кебегрәк!

Тик ул

Югалган иде,

Юк, кемдер

Алган иде.

Алган икән

Менә кем?!

Кире бирер ул,

Бәлкем?

Сызгыртсын инде,

Ярар.

Әтием миңа

Табар

Сыбызгының

Яңасын.

Сызгыртырмын

Аннан соң.

Сызгыртырмын

Нык итеп —

Җил чыгарырлык

Итеп!

Көзге

Карыйм да карыйм көзгегә,

Ала алмыйм күзне дә —

Миңа карап, бер матур кыз

Елмая бит көзгедә.

Көлдерербез!

Кызык булса, барыбыз да
Елмаеп-көлеп тора.
Бер малай бар,
Көлмәвеннән
Көләсе килеп тора.

Көлми торган кеше булмас,
Көлә беләдер әле,
Берәр җирдә үзе генә
Качып көләдер әле.

Алай дисәң, бер ялгызың
Көләсе килмидер ул.
Үзе генә тик торганнан
Берәү дә көлмидер ул.

Ярар, белмәсә өйрәнер —
Берәр җаен табарбыз.
Кәмит күрсәтеп алырбыз,
Мәзәк сөйләп карарбыз.

Инде алай да көлмәсә,
Нишләтергә белербез —
Көлдерергә...
Ш.Галиев

Шигырьләрен бирербез.

Көлдерербез!

Буранда

Беркем чыкмый

Урамга,

Буранлы көн

Булганга.

Буран ала

Бөтереп,

Салкын ала

Өттереп!

Кошлар гына

Һавада

Чайкалалар

Һаман да.

Рәхәтләнеп

Очарга

Бик кыендыр

Кошларга!

Мин барсын да булдырам

Мин җил кебек улый беләм,

Яңгыр кебек елый беләм,

Кояш кебек көлә беләм,

Чишмә кебек җырлый беләм.

Агач булып шаулый алам,

Күгәрчендәй гөрли алам.

Бик тырышсам, балык кебек

Сөйләшми дә йөри алам.

Сәер яңгыр

Өстән яңгыр
Сибәли,
Өскә яңгыр
Тигәли.

Ныклап кына
Таммый да,
Яумый да,
Туктамый да.

Әллә нинди лә
Һава:
Йә яумый да,
Йә ява.

Бәлки, яумас...
Бәлки, явар...
Ярар инде,
Үзе карар!

Әллә нинди
Бүген һава:

Үзе яумый,

Үзе ява...

Базарда

Базарда — карбыз да,

Йөзем дә, өрек тә.

Авызга кабуга

Бетәләр эреп тә.

Алмасы, чиясе

Әй тәмле, әй татлы.

Әфлисун-лимоннар

Өелгән кат-катлы.

Телеңне йотасың,

Капсаң да бер генә.

Чыннан да, йотачак

Капса да кем генә.

Малайлар ашыйлар

Карбыз да, кавын да.

Тик менә эләкми

Миңа бер кабым да.

Аларга аз гына

Кызыгып та куям.

Юк ла, мин базарның

Исеннән дә туям.

Шулай да җитәр лә —

Мин кайтып китәм лә,

Базардан тиз генә

Бер генә үтәм дә.

Базарда әтисез,

Базарда әнисез

Күңелсез икән лә!

Дөрес түгел бу бер дә!

Болытларга

Ук очып

Менә ала

Шул чыпчык!

Ә мин Алмаз

Булып та

Оча алмыйм

Болытка.

Очалмаммы

Гомердә?

Дөрес түгел

Бу бер дә!

## Кар яуды көн буена...

Кар яуды көн буена,

Кар яуды төн буена.

Күмеп китте юлларны,

Күмеп китте урамны...

Күмеп китте өйләрне,

Тагын әллә ниләрне...

Күмә иде мине дә,

Бик тә күмәр иде дә,

Бик нык яуганын күреп,

Качтым шул өйгә кереп!

Минем яныма кереп

Карасын инде күмеп!

Таулар бигрәк биек шул!

Ышанмас иде, әгәр дә

Сөйләсәм берәрсенә.

Аптырадым мин, карагач

Тауларның түбәсенә.

Тау түбәсен җәй көне дә

Ап-ак карлар каплаган.

Гөрләвекләр булып алар

Яз көне дә акмаган.

Кояшка тиеп торса да,

Кояш та эретмәгән.

Эссе җәйдә дә нишләптер

Һаман эреп бетмәгән.

Тау түбәсендә, мөгаен,

Тылсымлы кардыр әле.

Күптән эреп бетәр иде —

Хикмәте бардыр әле...

Диңгездә — җәй, ә тауларның

Кар каплаган түбәсен.

Биек булгач, тауларга җәй

Менә алмый, күрәсең!

Саный беләм

Мин инде

Саный беләм,

Саннарны

Таный беләм.

Саныйм мин

Берәм-берәм

Әлегә

Бармак белән.

Өйрәндем шул

Санарга,

Була санап

Карарга.

Тырышсам

Бик нык әгәр,

Саныйм мин

Унга кадәр.

Уннан соңмы?

Уннан соң...

Бик күп инде

Шуннан соң.

Алма бабай алмасы

1

Алма бабай алмагачы
Ай-яй бигрәк алмалы.
Урамга ук чыгып тора —
Өзеп кенә алмалы!

Берсе әнә бигрәк пешкән —
Кызыл гына, ал гына.
Сизеп торам, эче тулы
Ширбәт кенә, бал гына!

Шунсын гына, берсен генә
Өзсәң дә ярый кебек.
Ул кызыл алма үзе дә
Гел миңа карый кебек.

Узган саен карап узам:
— Исән икән, исән, — дим. —
Бүген тими торыйм әле,

Йә үпкәләр, тисәм, — дим.

2

Ә бер көнне исем китте —

Җилләр искән алмадан!

Авыз итәргә, ичмасам,

Яртысы да калмаган.

Бабай бүген бакчасына

Кермәсә ярар иде,

Шул алмасын миннән генә

Күрмәсә ярар иде.

Бик кызыккан булсам да, мин

Алмага тимәс идем,

Тиярлек булсам, ялганлап,

Мин алай димәс идем.

Нигә ялганлап торыйм ди,

Түгел лә мин ялганчы...

Башкалары пешсен иде,

Бабай сизеп алганчы.

3

Өйгә кайтсам, Алма бабай

Мине көтеп утыра,

Чәй янында, тирләп-пешеп,

Мине «тетеп» утыра.

Шул бер алма өчен хәзер

Тиргәшә башлый инде,

Әни алдында бур итеп,

Хур итеп ташлый инде...

Үзе, миңа күз кыскалап,

Кеткелдәп көлеп тора.

Алманы кем урлаганны,

Янәсе, белеп тора.

Миннән күзен алмый үзе:

— Сине озак көттем, — ди. —

Җиде чынаяк чәй эчеп,

Тәмам тирләп беттем, — ди. —

Синең алма яратканны

Сизеп калган идем, — ди. —

Бу алманы сиңа диеп

Өзеп алган идем, — ди. —

Жәл дә түгел, — дигән була, —

Синең кебек малайга.

Түбәм күккә тия язды,

Рәхмәт әйттем бабайга.

Бабай үзе көлә-көлә

Басып тора каршымда.

Каян белде икән бабай

Уйларымның барсын да?

Ә алмасы шундый баллы —

Торганы балдан икән!

Әллә кайчан ук кызыгып

Йөрисем калган икән.

Ява карлар, яңа карлар...

Ява карлар, яңа карлар —

Кышның ак гөлләре.

Якты булсын, ап-ак булсын

Илемнең көннәре.

Ишетелеп торсын җирдә

Балалар көлгәне.

Ява карлар, яңа карлар,

Ак — гомер юллары,

Дәвам итсен гомер буе

Тынычлык еллары.

Яңгырасын җир өстендә

Тынычлык җырлары.

Ява карлар, яңа карлар —

Тынычлык карлары.

Безгә бәхет алып килсен

Тынычлык таңнары.

Тыныч булсын илләр генә —

Җайланыр калганы!

Отличник

Ур-ра!

Мин «бишле» алдым!

Ничек итеп алганымны

Үзем дә сизми калдым.

Бер сәгатькә булса да,

Бер дәрестә булса да,

Отличник булып алдым!

Ни бар гармун эчендә?

Кагылсам гармуныма,

Гармунымның моңына

Кенәри дә кушыла,

Охшатадыр тавышын

Берәр таныш кошына.

Гармунымның эчендә

Кош дип уйлыйдыр инде.

Аннары... мин үзем дә

Матур уйныймдыр инде.

Ялгыз калгач...

Өйдә Алмаз — ялгызы.

Куркыта әллә нигә.

Берәр нәрсә, берәр ни

Бар микән әллә өйдә?

Нәрсәдер дөп-дөп итә.

Күзгә күренми генә

Нәрсәдер үтеп китә,

Нәрсәдер этеп китә,

Нәрсәдер төртеп китә.

Нәрсәдер дөп-дөп итә

Бүлмә түрендә генә,

Нәрсәдер дөп-дөп итә

Колак төбендә генә.

Башта ул

Бер яктан дөп-дөп итә,

Аннары

Өч яктан дөп-дөп итә,

Аннары

Бар яктан дөп-дөп итә,

Шуннан соң

Почмактан дөп-дөп итә,

Шуннан соң

Чоланда дөп-дөп итә,

Чыннан да дөп-дөп итә.

Әллә инде берәр карак

Керәме? — дөп-дөп итә?!

Юк ла, курыкканга гына

Йөрәге дөп-дөп итә!

Тими тел очына да

Кыза башлый да

Күзем,

Бетә башлый да

Түзем,

Кызулый башлыйм

Үзем!

Каян килә бу тизлек,

Бу тизлек,

Бу җитезлек?

Күзгә күренеп кими,

Тел очына да тими —

Шоколад та тиз бетә,

Лимонад та тиз бетә,

Варенье да тиз бетә,

Печенье да тиз бетә...

Кими алар — күземне

Ачып йомган тизлектә.

Әһә, белдем!

Ашыгучы

Мин түгел, алар икән.

Мин ярый инде, алар

Ник ашыгалар икән?

## Банкадагы «балыклар»

Карап-карап

Торган да,

Мыекларын

Борган да,

Иренен

Ялаган да,

Тагын бер

Ялмаган да,

Банкага

Үрелгән ул —

Андагы кыярларны

Балык диеп

Белгән ул!

Песиебез

Яланган —

Ялманган да

Алданган!

Без таган атынабыз!

Без таган атынабыз!

Биеккә атлыгабыз!

Кояшка атылабыз!

Без таган атынабыз!

Атындыр син

Безне, таган,

Кояшка һәм

Айга табан!

Без таган атынабыз!

Очып та китәр идек,

Ныгытып тотынабыз!

Без таган атынабыз!

Син бит, таган,

Безгә канат,

Очырт безне

Кабат-кабат!

Без таган атынабыз!

Канатланып очабыз!

Без Җир шарын кочабыз!

Без таган атынабыз!

Әйдә, таган,

Канат кагын,

Атындыр син

Безне тагын!

Печән өсте

Авылда җәй.

Җәйге болын.

Печән өсте.

Печән чапкан

Абыйларга

Ай-яй эссе!

Печәнчеләр

Бу эсседә

Янып пеште.

Ярый әле

Аз булса да

Җилләр исте.

Печән исә

Биек кибән

Булып үсте.

Күренми дә

Биектәге

Кибән өсте.

Кибән өсте

Нәкъ тау төсле!

Качып кына
Менеп киттек
Кибәнгә без.

И уйныйбыз,
И уйныйбыз,
Кинәнәбез!

Тик кибәннең
Асты өскә
Килә язды.
Үзебезнең
Түбә күккә
Тия язды!

Безнең хәтта
Буй да бераз
Үсә төште —

Безнең якта
Бигрәк
Биек
Печән өсте!

Йөрибез!

Автобуста йөрибез,

Троллейбуста йөрибез,

Бигрәк оста йөрибез,

Җәй дә, кыш та йөрибез,

Билет алып йөрибез,

Күбрәк бушка йөрибез,

Теплоходта йөрибез,

Самолетта йөрибез,

Самокатта йөрибез,

Хәтта атта йөрибез,

Пар атта да йөрибез,

Корабта да йөрибез,

Утырып та йөрибез,

Тотынып та йөрибез.

Ябышып та йөрибез,

Ярышып та йөрибез,

Кысырыкта юри без

Кысылып та йөрибез,

Ниләр генә күрмибез,

Тик барыбер йөрибез,

Җәяү генә йөрмибез.

Ләкин барыбер күбрәк

Җәяү йөрергә кирәк!

Ник икәнен үзегез

Җәяү йөргәч күрерсез.

Шуннан соң үзегез дә

Күбрәк җәяү йөрерсез!

Күрерсез!

Без йолдызлар саныйбыз

Булат белән ятабыз

Йолдызлы күккә карап,

Булат белән ятабыз

Шул йолдызларны санап!

Булат белән йолдызларны

Без ярышып саныйбыз.

Ә иң башта йолдызларның

Эреләрен сайлыйбыз...

Ул йолдызларны санап

Бетерәчәкбез тиздән:

Артты да менә йөздән,

Җиде йөздән, бер меңнән,

Ике меңнән, ун меңнән...

Бик күп лә бу йолдызлар,

Күпмелеген кем белгән?!

Ә йолдызлар нигәдер

Биешә башладылар,

Селкенә башладылар,

Сикерә башладылар,

Җемелди башладылар,

Дерелди башладылар,

Чуалышып беттеләр,

Буталышып беттеләр...

Курыкты бугай алар,

Санап бетерерләр дип,

Санап бетерерләр дә

Кызык иттерерләр дип.

Без дә санап тормадык,

Күзләр дә арган иде.

Юкса санап бетерергә

Аз гына калган иде!

Оча торган чаңгылар

Оча гына

Чаңгылар —

Алар гүя

Җанлылар!

Сикәлтәдән чаңгылар

Очып китә бик биек.

Шуңа тизрәк төшәбез,

Очып китмәсен диеп!

Әгәр җиргә төшмәсәң,

Очар алар ары да.

Бар икән чаңгыларның

Оча торганнары да!

Сез дә бәхетегезне

Берәр сынап карагыз!

Әти-әниегездән

Сез дә сорап карагыз!

Хәлегезгә

Кирәрләр,

Бәлки, алып

Бирерләр?!

## Сайрый торган агач

Мин агач утырттым,

Ул күккә чөелде.

Үземнән дә бигрәк

Кошларым сөенде.

Ул кошлар агачта

Туйганчы тирбәлде —

Агачым шатлыктан

Сайрап ук җибәрде!

Аптырап калдым мин

Агачны тыңлагач —

Утыртканмын икән

Сайрый торган агач!

Сандугачлы агач!

Җәйнең яшел аты

Атландым да ялт кына

Җәйнең яшел атына,

Җәй буйлап чаптым гына

Мин талпына-талпына!

Малайлар, кызлар кала

Су буенда кайнашып,

Чишмәләр чыңлап кала,

Кошлар кала сайрашып.

Кул изи печәнчеләр,

Гөрләп кала болыннар.

Безнең арттан иярә

Болындагы колыннар.

Җәйнең матурлыклары

Кала күренеп кенә,

Аз гына күренә дә

Кала күмелеп кенә.

Их, атым арсын иде,

Акрынрак барсын иде!

Кире бормакчы идем,

Туктап тормакчы идем,

Тик җәй аты туктамый,

Туктап бер дә ял итми,

Туйганчы бер утламый...

Әй чабабыз!

Тик алда

Сары бер ут күренде.

Җәйнең аты кинәттән

Сарыга әверелде.

Бигрәк җитез барганбыз,

Сизмичә дә калганбыз —

Атым белән бергә без

Күзгә килеп кергәнбез!

Мин дә катнаштым!

Быел авылда

Мин басу күрдем.

Ипинең ничек

Үскәнен белдем.

Шофер абыйга

Утырып йөрдем,

Хәтта руленә

Тотынып йөрдем!

Иген кырына

Бардым мин көн дә...

Урып-җыюда
Катнаштым мин дә!

Болытлар

Болытлар безнең өстә
Төрлесе төрле төстә,
Төрле-төрле рәвештә,
Килә алар әвеш тә,
Килә алар тәвеш тә.

Йөзәләр микән алар?
Әллә инде бер-берсен
Сөзәләр микән алар?

Шуалар микән алар?
Әллә инде бер-берсен
Куалар микән алар?

Очалар микән алар?
Әллә инде бер-берсен
Кочалар микән алар?

Ник шулай чабалардыр?
Мөгаен, аралардыр!
Арыганда тиз генә
Җилгә утыралардыр.

Юкса арырлар иде,
Туктап алырлар иде,
Ял итә-итә генә
Җайлап барырлар иде.

Арыгачтын, бөтенләй
Туктап калырлар иде.

Ә болытлар һаман да
Очалар да очалар.
Җилгә утырып баргач,
Арымыйлар ич алар!

## Таш, чыпчык һәм алма

Агачка кунган чыпчык,

Алмага кунган чыпчык —

Минем иң зур алмага,

Алланасы алмага,

Балланасы алмага

Кунган бит ул

Чукынчык!

Гел карап үтә идем,

Пешкәнен көтә идем!

Чык бакчадан,

Чык, дим, чык!

Юк, кузгалмый да чыпчык!

Әмәлен ләкин таптым —

Агачка мин таш аттым.

Юк ла, алмага аттым,

Чынлап, аңа да аттым.

Юк ла, чыпчыкка аттым!

Ахрысы, юкка аттым...

Ташым да очып китте —

Чыпчык та очып китте,

Алма да очып төште,

Ямь-яшел килеш төште.

Вәт кызарды,

Вәт пеште!..

Боек үгез

Утарда яши үгез.

Беркемгә дәшми үгез.

Ул дөньяга

Ачулы,

Көтә капка

Ачуны,

Тизрәк чыгып

Качуны.

Басып тора

Ул оеп,

Бик күңелсез,

Бик боек.

Мөгезләргә

Эш тә юк,

Эш булмагач,

Көч тә юк.

Мондый тормыш үгезгә

Бөтенләй хаҗәт түгел,

Болай яшәү үгезгә

Бөтенләй мәзәк түгел.

Болай ул беркемгә дә

Күрсәтә алмый көчен —

Боек ул

Шуның өчен!

Йөгәнсез чаптар

Чаптар ясадым беркөнне —
Җитез, көчле иттердем,
Ә ялларын диңгездәге
Дулкын төсле иттердем.

Елгыррак булып чыккан ла —
Үзен күпме сакладым,
Тик барыбер дәфтәремнән
Чыгып чапкан чаптарым!

Ясамаганмын йөгәнен,
Куймаганмын бәйләп тә.
Шуңа күрә качкан да ул —
Качуы бик әйбәт лә!

Әнә анда бер көтү ат
Утлап йөри болында.
Ә берсе уйный-уйнаклый,
Торалмый бер урында.

Шул елгыры, йөгәнсезе,
Мөгаен, мин ясаган.
Дәфтәр түгел, болын да тар...
Бер дә юкка качмаган!

Йөрсен әйдә рәхәтләнеп,

Йөгән әле табылыр.

Тик табылса да, йөгәнне

Кидертмәс ул барыбер!

Аңа беркем якын бармый,

Күргәч ничек йөргәнен!

Ярый әле кидертергә

Оныткан мын йөгәнен!

## Канатлы ут

Килеп кунды кулыма

Якты бөҗәк — җанлы ут.

Кара төндә учымны

Яп-яктыртып янды ут!

Күпме ут күргәнем бар!

Җирдә яна төрле ут!

Диңгез буенда гына

Ул канатлы, тере ут!

Кечкенә фонарь кебек,

Канатлы фонарь кебек,

Яктырак янар кебек,

Ныграк үссә тагын да!

Очып кит син, җанлы ут,

Канатыңны кагын да!

Икенче килүемә

Үсеп зур булыр әле,

Зур фонарь булыр әле,

Тирә-якны тере ут

Яктыртып торыр әле!

Килгәч монда тагын да,

Мин аны шул чагында

Алып кайтырмын өйгә —

Чын фонарь чаклысын да.

Диңгезне сагынырмын

Мин аның яктысында!

Яңгыр

Кешеләр
Яңгыр көткән,
Яумаган
Яңгыр күптән.

— Яңгыр кирәк! — дигәннәр.
— Ява сирәк! — дигәннәр.
— Яусын тизрәк! — дигәннәр.

Яңгыр
Ялындырмаган,
Көттереп тә тормаган.
Яңгыр
Ява башлаган,
Шактый явып ташлаган.

Ә кешеләр
Өркешеп,
Этешеп тә
Төртешеп,
Чатырларын
Ачканнар,
Чатыр чабып
Качканнар...

Ә яңгыр

Үпкәләгән,

Әз генә

Сипкәләгән,

Бер-ике тамган,

Аннан

Тиз генә

Китеп барган.

Кешеләр карап калган!

Үзебез ясаган машина

Шәп машина ясадык:

Кабинасын ясадык,

Әрҗәсен дә ясадык,

Ясадык фарасын да.

Машинага ни кирәк —

Ясадык барысын да!

Ялт итте машинабыз,

Йөрергә ашыгабыз!

Машинаны без йөртеп
Карадык әле генә —
Тик йөрми әле менә.

Шуңа этеп йөртәбез,
Әй артыннан этәбез,
Этәбез дә төртәбез,
Арып-талып бетәбез,
Тик барыбер этәбез.

Йөрер өчен, машина
Тиеш йөри белергә.
Шуңа күрә без аны
Өйрәтәбез йөрергә!

Шүрәле

Ишеттегезме әле?
Сез белмисездер әле —

Бүген безнең кибеткә
Китергәннәр шүрәле!

Шундый кызык шүрәле,
Шүрәлене күргәчтен,
Рәхәтләнеп көлмәле!

Күрдем аны мин үзем:
Әй тырпайткан мөгезен,
Кимәгән эшләпә дә.
Бармакларын, мөгезен
Ул әллә нишләтә дә
Әй көлдерә өзлексез!
Үзе никтер күзлексез.
Ә шулай да ул шүрәле
Күзлексез дә бик ямьсез,
Күзлексез дә иләмсез.

Унбиш тиенлек кенә —
Түгел үзе кыйммәт тә.
Ә үземе?
Ә үзе
Чын шүрәле, әлбәттә!

Олылар һәм балалар,
Очсызга күрәме соң,

Кызыкка күрәме соң,

Чират торып алалар

Тукайның «Шүрәле»сен!

Җилләр исте куяннан!

Машинада барганда,

Бер дә уйламаганда,

Без бер куян

Күреп алдык,

Тик аз гына

Күреп калдык —

Әй тиз җилдерә иде,

Гүя җил генә иде!

Әти күреп калган икән

Колакларын,

Ә мин күрдем ул куянның

Аякларын.

Энем исә

Койрыгын да

Күрмәгән,

Күрергә

Өлгермәгән.

«Куян кайда, әйтегез!» — ди.

«Яңадан күрсәтегез!» — ди.

Куянны без

Каян табыйк,

Куянны без

Каян алыйк?

Ничек тотыйк аны без?

Юк инде куяныбыз!

Борчылма бер дә, энем.

Ис китми менә минем.

Әле менә ул куянны

Уйлап куям:

Куян иде микән әле

Ул ак куян?!

Җайдаклар

Безнең якның малайлары

(Әйтү түгел мактанып)

Тәпи йөри башлау белән

Чаба атка атланып!

Атларда чаба малайлар —

Атлары да атлары!

Малайларның әле шулай

Чаба торган чаклары.

Атлана да чаба алар

Иярсез дә йөгәнсез.

Бу инде — безнең малайлар

Чын җайдаклар дигән сүз.

Чаба алар, оча алар,

Калмый хәтта эзләре.

Канатлы әллә атлары,

Әллә инде үзләре...

Кызлар кала кызыгып,

Энекәшләр — көнләшеп.

Әй оча, оча малайлар

Абыйларга тиңләшеп.

Кирәк булса, очар алар

Йолдызларга, айларга...

Кемдер атларга соклана,

Ә кемдер — малайларга!

Качып калган яңгыр

Яңгыр явып

Үткән иде,

Күптән инде

Беткән иде,

Күптән узып

Киткән иде...

Мин яңгырдан

Качкан идем.

Мин каенның

Төбенә үк

Баскан идем.

Шул каенга

Ялгыш кына

Тиеп киттем —

Нигә генә

Алай иттем?!

Каен куйды

Шыгырдап,

Яңгыр койды

Шыбырдап.

Калдым яңгыр

Астында.

Югыйсә бит

Качтым да...

Хәйләкәр икән яңгыр,

Карачы, карасана! —

Качып калган булган ул

Яфраклар арасына!

Тирәкләргә җил кирәк!

«Их, җил чыксын иде дә

Безне уятсын иде,

Их, җил чыксын иде дә

Безне уйнатсын иде,

Их, җил чыксын иде дә

Безне кузгатсын иде,

Их, җил чыксын иде дә

Безгә сүз катсын иде!..

Шыбыр-шыбыр

Шыбырдап,

Шыгыр-шыгыр

Шыгырдап

Сөйләшкән булыр идек,

Серләшкән булыр идек,

Җилләнеп алыр идек,

Сафланып калыр идек!

Җилсез булмый,

Җил кирәк!» —

Диеп уйлый тал-тирәк.

## Куркак туп

Тупның бөтен курыкканы
Кадак белән энә, без.
Ә менә без тупның нигә
Курыкканын беләбез!

## Очасым килә

— Әтием, минем
Очасым килә!
Ак болытларны
Кочасым килә!

— Син инде, кызым,
Очасың күптән.
Кайтып кермисең
Болытлы күктән.

— Кошлар янында

Тирбәнер идем,

Канатларым юк

Нигәдер минем.

— Канатларың бар,

Кызым, синең дә.

Син аны үзең

Сизмисең генә.

— Йолдызларга да

Менәсем килә.

Анда ниләр бар —

Беләсем килә.

— Гомер юлларың

Әле бик озын —

Йолдызларга да

Очарсың, кызым!

Өрә белүче шкаф

Барыбыз беткәч ятып,

Шкафыбыз бервакыт

Әй өрергә тотынды —

Алды бөтен котымны!

Өрә-өрә, туктамый —

Беребез дә йокламый.

Ачкан идем ишеген,

Килеп чыкты көчегем!

Койрык

Карале, кара, кара:

Бер койрык китеп бара.

Ул алан буйлап бара,

Уйнаклап, уйнап бара.

Боргаланган да була,

Сыргаланган да була.

Озынлыгын күрсәгез,

Йомшаклыгын күрсәгез,

Шунда ук таң калырлык,

Күзнең явын алырлык!

Ник йөридер кагылып —

Шул төлкегә тагылып!

Пешмәгән

Сатып алдым мин карбыз.

Тәмле микән? Карарбыз!

Турадым өйдә ваклап.

Ә эче... эче ап-ак.

Тукта, тукта, туктагыз —

Пешмәгән бит бу карбыз...

Ә бит күпме сайладым?!

Бик-бик күпне сайладым.

Чирткәләгән дә идем,

Төрткәләгән дә идем,

Каккалаган да идем,

Суккалаган да идем...

Менә бит нишләгәнмен —

Үзем дә пешмәгәнмен!

## Туган тел

«Туган телем —

Анам теле!» —

Дияр әле

Балалар.

«Туган телем —

Балам теле!» —

Дияр микән

Аналар?

Алма

Алмасы да алмасы —

Өзеп кенә аласы!

Өзмим әле — баллансын,

Бераз гына аллансын!

◊◊◊

Минем газиз Җирем бар,

Җирдә туган илем бар,

Илдә туган җирем бар.

Туып үскән җиремдә

Авылым бар минем дә!

Авылда — туган өем,

Ә өемдә — әнием!

Иң кадерлем

Ул минем!

## Тычкан елында туганмын

Тычкан елында тугачтын,

Мин, мөгаен, тычкандыр.

Сиздермичә генә миңа

Берәр тычкан поскандыр...

Тычкан алмагач кимерә,

Ә мин алма кимерәм.

Яисә кишер кимерәм —

Шуңа бугай симерәм.

Тычкан чиный, малай чакта

Үзем дә чиный идем.

Тычкан төсле урлашуның

Мин кимен куймый идем.

Әнкәйнең шикәр-кәнфите

Савытта тормый иде.

Кәнфитләрне, миннән калса,

Тычкан да урлый иде.

Тычкан төсле тиктормас мин,

Тычкан төсле килбәтсез.

Тик мин татар тычканы бит,

Ә тычкан ул милләтсез.

Мин дәү тычкан, нәни булсам,

Йөрер идем ыштансыз.

Дөнья кызык булмас иде

Булган булса тычкансыз.

Ә мәчедән мин дә куркам:

Ул әллә нишләр кебек,

Мине тычкан дип белер дә

Килер дә тешләр кебек!

Йөрим мин дә тычкан төсле

Шыпырт кына, тын гына.

Коеп куйган тычкан бит мин,

Юк тик койрыгым гына.

Тычкан төсле шөкәтсез мин,

Тычкан төсле сөйкемле:

Минем хәтта мыегым да

Тычканныкы шикелле!

«Ялкын» журналының 70 яшенә

Сүзләрең — алтын,

Хисләрең — алкын,

Данлыдыр — атың,

Алтындыр — хакың!

Яктырып-балкып

Биеккә талпын,

Дөрләт малайлар

Һәм кызлар халкын!

Син безгә кирәк,

Син безгә якын.

Булмасын салкын,

Яшәсен «Ялкын»!

## Бәхтиярның туган көненә

Бәхтияр бик тә дәү булган —

Яшьләре дә дүртәү булган!

Ике күзе ут диярлек,

Маңкасы да юк диярлек.

Бакчага да йөреп тора,

Авырмаса, чирләмәсә...

Авырмый да, чирләми дә,

Йөгермәсә, тирләмәсә...

Әтисен дә, әнисен дә,

Бабасын да, әбисен дә

Тыңлый икән... тыңлаганда,

Бик карышып тормаганда,

Колакларын бормаганда,

Бабай тамак кырмаганда...

Дүрт яшь тулган Бәхтиярга —

Дәү булган ул бәхте барга!

Бу шигырьне Бәхтиярның

Туган көнен котлап яздым —

Дүрт яшен дә хуплап яздым,

Бар талантны туплап яздым,

Ныклап яздым!

19.04.90

## Терел инде, Гөлнара!

Гөлнара Нурисламовага

Чирләп ята бер бала.
Ул бер бала — Гөлнара.

Бит очлары кызылланган,
Кызылланган, алланган!

Килә бик тә торасы —
Бар температурасы!

Эчкән була дару да,
Юк бәйрәмгә бару да.

Тор инде, тор, Гөлнара,
Яңа ел үтеп бара.

Бүген Яңа ел төне,
Иртәгә — туган көнең.

Яңа елның килгәнен
Күрми каласың инде.

Яңа ел бүләгеннән

Колак кагасың инде.

Чирле кызлар елмаймый,

Чирле кызлар көлешми.

Ә син елмай, ә син көл —

Сиңа чирләү килешми!

Синең туган көнең бит!

Гел шушылай көлеп тор!

Без сине яратабыз —

Син шуны гел белеп тор!

Айгөл белән Гүзәл дә

Борчыла синең өчен.

Ютәлләмәү, төчкермәү,

Терелү — синең эшең.

Әнә Таңсылуга да

Син чирләгәч күңелсез.

Болай чирләп ятарга

Тиеш түгел бүген сез!

31.12.95

Чакыру

«Яшь ленинчы» безнең һаман

Яшь әле, япь-яшь әле.

Сезнең кебек малайларга,

Кызларга яшьтәш әле.

Ул үзенә эзли дуслар.

Чын дуслар була сирәк.

Ә дуслар аңа бик кирәк,

Сезнең кебекләр бигрәк!

Ул сезне бик тә ярата.

Әйтим инде чып-чынын:

Сезгә кунакка барасы

Килә «Яшь ленинчы»ның.

Бергә уйланыр идегез,

Бергә уйнар идегез...

Шулай булыр дип, әлбәттә,

Ышанабыз инде без.

Шатланырсыз, борчылсагыз,

Ял итәрсез, арсагыз —

«Яшь ленинчы»ны алсагыз,

Алгач, укып барсагыз!

Белмим, нишләрсез инде

Язылмыйча калсагыз?!

12. 09.90

## Безнең якта...

Безнең якта бөркетләр юк,

Бөркетләр без үзебез.

Ә шулай да бөркет эзләп

Күкне күзли күзебез!

Көләч шигырь

Кояш көлә,
Гел көлә!

Кояш көлгәч,
Көн көлә!

Көн көлгәчтен,
Гөл көлә!

Гөл көлгәчтен,
Кем көлә?

Гөл көлгәчтен,
Мин көләм!

Кояш көлә,
Мин көлгәч!

Шуңа да мин
Гел көләч!

Әгәр...

Әгәр бер эш

Төбәсәң,

Әгәр бик нык

Теләсәң,

Бик-бик-бик-бик

Теләсәң,

Әгәр бик нык

Тырышсаң,

Тырышканда үзеңә

Бик ныгытып

Булышсаң,

Күп тапкырлар

Тырышсаң,

Һәм тырышсаң

Тагы бер,

Теләгеңә беркөнне

Ирешәсең

Барыбер!

Өр-яңа киез итек

Аягымда
Киез итек —
Атлап киттем
Тигез итеп.

Тигез итеп —
Тиз-тиз итеп,
Тип-тиз итеп,
Төп-төз итеп!

Йөри итек
Кызык итеп —
Чабып китә
Кызып китеп.

Үзе йөри
Киез итек,
Киез итек —

Көяз итек!

Кар көртләрен
Гизде итек,
Кар диңгездә
Йөзде итек:

Батмады да,
Чуммады да,
Өшемәде,
Туңмады да!

Әй йөрелде,
Әй йөрелде,
Чабылды да
Йөгерелде...

Йөри торгач,
Киез итек
Вездеходка
Әверелде!

Тамчы, таммачы!

Тамчы, дисәң,
Тып та тып!

Булмый гына

Туктатып:

Тып та тып!

Тып та тып!

Булмый гына

Йоклатып:

Тып та тып!

Тып та тып!

Тамчы, тамчы,

Аңлачы,

Тамчы, тамчы,

Тыңлачы,

Тамчы, тамчы,

Таммачы! —

Дигән идем,

Тамчы да

Таммады бер

Тамчы да!

Әгәр дә яңгыр булса...

Яңгыр яуса озаклап,
Яңгыр койса чиләкләп,
Яуса унбер көн рәттән,
Һәм яуса тагын бер көн,
Һәм койса тагын бер көн,
Идел диңгез
Булыр иде,
Суы тиңсез
Булыр иде,
Бөтен дөнья
Тулыр иде,
Өйләр суда
Торыр иде,
Елгалар да
Ташар иде,
Җәнлекләр дә
Качар иде,
Дөньяны су
Басар иде...

Менә шуның өчен дә
Яумый шул яңгыр
Көн дә!

Яңгырны кызганып

язылган шигырь

Яңгыр яуганда миңа
Яңгыр яумаган кебек —
Яңгыр елаган кебек,
Ярдәм сораган кебек.

Чынлап елыйдыр яңгыр,
Берәр сәбәбе бардыр?

Сәбәбе бар, әлбәттә.
Куям үзен жәлләп тә.

Яуды да ул үтте дә...
Әле генә бар иде —
Инде әнә бетте дә.
Ул яңгыр була ала
Бары яуганда гына,
Җиргә тамганда гына.

Ә җиргә төшү белән

Әйләнә күлдәвеккә,

Әйләнә гөрләвеккә,

Инешкә агып китә

Йә җиргә тамып бетә...

Мин үзем дә

Йә җиләккә әйләнсәм,

Йә чиләккә әйләнсәм,

Йә иләккә әйләнсәм,

Бер дә оялмас идем —

Еламый калмас идем!

Җәйге яңгыр яуганын

күзәтеп торганда язылган шигырь

1

Ерак офыкта

Яшен камчылый.

Тып та тып итеп

Яңгыр тамчылый.

2

Минем башка да

Бераз тигәли.

Юк, тамчыламый,

Яңгыр сибәли.

3

Караңгылана,

Бозыла һава.

Юк, сибәләми,

Бу яңгыр ява.

4

Яшеннәр яшьни,

Күк күкрәп куя.

Юк, яңгыр яумый,

Чиләкләп коя!

Күкнең тарту көче

Җирнең тарту көче бар!
Җир бик ярата безне —

Шуңа күрә үзенә
Көчлерәк тарта безне!

Ләкин кеше барыбер
Тартыла өскә таба —

Очарга көч тә таба
Иң биек төшкә таба!

Кешене галәм тарта,
Тартылу һаман арта!

Оча ул йолдызларга!
Димәк, анда эше бар.

Гел күккә омтылабыз —
Күкнең тарту көче бар!

Кояшлы яңгыр

Яңгыр да
Явып тора,

Кояш та
Янып тора.

Белмимен,
Әллә нигә

Керәсе килми
Өйгә!

Яңгырда яланөс бик оза-а-ак
торганнан соң язылган шигырь

Яңгыр ява.

И-и-их, ява!

Яңгыр ява.

Э-э-эх, ява!

Яңгыр ява.

У-у-у, ява!

Яңгыр ява.

Ну-у-у, ява!

Яңгыр ява.

Бр-р-р...

Бер-р-раз гына

Яумый тор-р-р...

Һәркайсының үз моңы

Чут-чут, чут-чут, чут-чут итеп,
Чут итеп сайрый урман.
Безнең якның урманнары
Нәкъ шулай сайрый торган.

Әгәр игътибар итсәгез
Җәйлектә йә язлыкта,
Бак-бак, бак-бак, бак-бак итеп
Сайрый белә сазлык та.

Му-му диеп җырлый абзар,
Беззз-безз дип — умарталык.
Кыт-кыт дип сайрый кетәклек...
Тыңлыйбыз хәйран калып.

Һәрберсенең үз җыры бар,
Һәркайсының үз моңы —
Үзегез дә һәр көн саен
Ишетәсез сез моны!

Яшелгә әйләнәсең килсә...

Агачта бар яшел төс.

Агачта — бар яшел төс!

Нәкъ әнә шул яшел төс

Агачларны яшәртә,

Нәкъ әнә шул яшел төс

Яфракларны яшәтә!

Әгәр агачның кайчан

Яфрак ярганын белсәң,

Нәкъ шул чагында гына

Агач башына менсәң,

Торсаң

Күзең талганчы,

Торсаң

Тәмам арганчы,

Агач

Яфрак ярганчы,

Бераз туңа башлыйсың,

Калтырана башлыйсың,

Чыкмый башлый сүзең дә.

Менә шунда яшелгә

Әйләнәсең үзең дә!

Йөгерә чебиләр урамнан

Көзге җил җилферди урамда,

Ул минем чабуга ябыша.

Җил белән ярыша-ярыша

Сап-сары чебиләр чабыша.

Йөгерә чебиләр урамнан,

Йөгерә берни дә күрмичә.

Кинәттән бер чеби чак калды

Машина астына кермичә.

Туктап ук калды ул куркудан.

Йөрәгем жу итте минем дә...

Ул сары яфракка әйләнде,

Мин аны тотмакчы идем дә!

Карбыз

Ашаган идем
Бер карбыз,
Ашаган идем
Зу-ур карбыз!

Ләкин бер дә
Шатланмадым,
Чөнки чак-чак
Шартламадым!

Карбыз йоткан
Төсле булдым,
Мин зур карбыз
Эчле булдым!

Юкса мин ул карбызны
Ваклап ашаган идем,

Тышын ташлаган идем,

Төшен ташлаган идем...

Булды бу

Ничек болай? —

Күбрәк

Ашалды бугай!

Помидор белән булган

бер кызык вакыйга

Бакчада зур бер яшел

Помидор яшәгән, ди.

Аны бер малай өзеп

Кояштан яшергән, ди.

Чөнки озак көткән, ди.

Ә җәй узып киткән, ди.

Ә помидор пешмәгән,

Ни өзелеп төшмәгән.

Малай шуның өчен дә

Помидорны салган, ди,

Киез итек эченә!

Шуннан бирле помидор

Караңгыда яткан, ди,

Бик кайгыга

Баткан, ди...

Шуннан соңмы?

Шуннан соң

Помидор

Пыр тузган, ди,

Ачуыннан

Кызган, ди.

Шуннан малай помидорны

Алыйм дисә кызганып,

Помидорыбыз ачудан

Чыккан шундук кызарып!

Самолет иллюминаторыннан

җиргә карап барганда язылган шигырь

Акрын гына, салмак кына
Аста Идел агып бара.
Ул иңенә баржаларын
Һәм салларын салып бара.

Кара әле, кара, кара:
Бер олы юл китеп бара,
Машиналарын тезгән дә
Казанга ук җитеп бара.

Поездларын төягән дә,
Тимер юл да китеп бара,
Боргалана-боргалана
Елан кебек итеп бара.

Бер сукмак та барган була,
Башкалардан, ахры, күреп.
Бер малайны иярткән дә
Чаба гына терек-терек...

Көтмәгәндә генә бүлмәгә

килеп кергән тынлык турында шигырь

Бүлмәгә

Көтмәгәндә

Килеп керде бер Тынлык.

Без шунда ук тын гына

Утырырга тотындык.

Куркып тын да алырга

Утырдык без тын гына.

Ә Тынлык бүлмә буйлап

Йөрде акыртын гына.

Тынлык хәйләкәр икән —

Күзгә дә күренмәде.

Хәтта аның бүлмәдә

Йөргәне беленмәде...

Бәлагә тарыгандай

Тынлыкка тарыдык без.

Тынлыкта тын утырып

Тынлыктан арыдык без.

Һәм шауларга тотындык,

Карап-карап тордык та.

Куркып безнең шау-шудан

Чыгып качты Тынлык та!

Өмет

Сөн диңгезгә әйләнергә

Агып китә еракка!

Әйләнер микән минем дә

Кәгазь көймәм корабка?

Аптыраш!

Тәме тәмле әйбернең

Элгә дә

Калакка,

Кереп кача

Тамакка!

Кошларның матур җыры

Кереп кача

Колакка —

Табып булмый

Юллап та!

Чәчәкләрнең хуш исе,

Чыксам әгәр

Болынга,

Кереп кача

Борынга!

Ә кич белән яктылык

Кереп кача

Күземә! —

Аптырыйм мин

Үзем дә!

## Яңа итек

Әнием алган итек.
Кияргә ничек итеп?

Аякка сыймый итек —
Кибетенә яңадан
Биримме әллә илтеп?

Аңлый алмыйм
Һич кенә —
Әллә инде аяк зур,
Әллә итек кечкенә?

## Дулкынлану

Бөркет канат кагынды —

Үләннәр дулкынланды.

Былбыл канат кагынды —
Күңелләр дулкынланды.

## Төнге урамнар

Шәһәр. Урам. Фонарьлары
Кабыналар берәм-берәм.
Ә без авыл урамнарын
Яктыртабыз йолдыз белән!

## Каеннар телендә

Каеннар шауламый,
Каеннар серләшә.

Алар бит үзләре

Телендә сөйләшә.

Теләгән кешеләр

Аңа тиз төшенә.

Иң матур бер тел ул

Төшенгән кешегә.

Шул каеннар белән

Каеннар телендә

Сөйләшкән, серләшкән

Чаклар бар минем дә!

Күрше абый

Урам себерүче абый

Яратып эшли эшен —

Ялт иттереп куя ул

Урамның бөтен төшен!

Тамчылап тама тире,

Бүрегеннән пар чыга.

Ул көрәккә тотынса,

Чыда гына, кар, чыда!

Бураннар уйнап тора

Ул урам себергәндә.

Ул урам себергәндә

Буранрак Себердән дә!

Буран чыккан бүген дә,

Урам калды буранда —

Күрше абый бүген дә

Кар көридер урамда!

Табын янында

Вил белән Нур ашаганда

Ашый ярышып.

Нигә алар бер-берсеннән

Торсын калышып!

Һәркайсының үз савыты

Һәм үз кашыгы.

Шулай булгач, ашыйлардыр

Нигә ашыгып?

Виле: «Бетә бит!» — дип, Нурны

Тора котыртып.

Нуры тиз-тиз ашый ашын,

Бетә дип куркып!

Трамвайда «куян» булып йөрергә

яраткан малай турында

Төшкән чакта трамвайдан,

Кызыл бәйләгән абый

Килеп чыккандыр кайдан?!

Мине күреп калды да,

Эләктереп алды да:

— Эләктеңме, «куян»! — ди. —

Билет алмый йөрергә

Өйрәндең син каян? — ди. —

Мәктәбеңә, өеңә

Җиткерәм бу хакта, — ди, —

Кызармыйсың хәтта! — ди...

Мин шундый каушаганмын,

Мин шундый курыкканмын,

Куркудан кызарырга

Чыннан да оныткανмын.

Кызарсам да, соң инде,

Тиргәделәр шул инде!

Кайттым.

Кайткач,

Шаккаттым!

Әздер миннән

Көлсәң дә —

Билет булган

Кесәмдә!

Хәмдия әби пәриләре

Капка төбенә җыелып
Сөйләшәләр әбиләр:
«Хәмдияләрнең өенә
Ияләшкән пәриләр!»

Хәмдия әби үзе дә
Башта бик нык курыккан,
Ләкин әби пәриләрнең
Әйбәтенә юлыккан!

Алар Хәмдия әбигә
Суга баралар икән,
Үзе күрмәгәндә генә
Утын яралар икән.

Бәрәңге алалар икән,
Кар да көриләр икән,
Ләкин үзләре әбидән
Качып йөриләр икән...

Ә бабайлар, әбиләр

Нишләргә дә белмиләр.

«Мондый хәлләрнең булганы

Юк иде күптән инде,

Безнең авылда пәриләр

Бишбылтыр беткән иде.

Хәмдиянең пәриләрен

Нишләтәбез, җәмәгать?»

Тик Хәмдия әби үзе

Пәриләрдән канәгать!

Бары укучылар гына

Ни өчендер көләләр —

Пәриләрнең кем икәнен

Алар, ахры, беләләр!

«Баһадир» кибетендә

«Баһадир» дигән кибет

Бар Такташ урамында.

Аптырашта каламын

Мин шунда буламын да.

Биредә күлмәкләрнең,

Туннарның иң олысы.

Камил кебек малайның

Сыя анда унысы.

Көймә итеп йөзәрлек

Ул зур ботинкаларны.

Госман күмелер иде,

Әгәр кисә аларны.

Андагы зур бүрекләр

Ярый Алыпка гына.

Миңа да ярар иде,

Бераз үссәм тагы да!

Әгәр үссәм, ул киемнәр,

Әлбәттә, ярар иде.

Ул киемнәр мин үскәнче

Бетмәсә ярар иде!

Сезне дә чакырачакмын!

Мин иң усал җанварларны

Өйрәтүче булыр идем,

Арысланнар арасында

Курыкмыйча торыр идем —

Сезне шаккатырыр идем...

Энем бик аптырар иде

Һәм авызын ерыр иде,

Күрше кызы Сөембикә

Ышанмыйча торыр иде,

Әби белән әниемнең

Күңелләре тулыр иде,

Әти тамак кырыр иде

Һәм мыегын борыр иде,

Ә күрше малайларының

Күзләре ут янар иде...

Арысланнар кирәк миңа,

Юлбарыслар кирәк миңа,

Берәр фил дә ярар иде!

Шул хакта сүз чыкса әгәр:

— Арысланнар ерткыч! — диләр. —

Алар бик куркыныч! — диләр. —

Песиеңне өйрәт! — диләр. —

Маэмаеңны, бахбаеңны

Өйрәтергә кирәк! — диләр.

Алар миңа кызык түгел,

Алар миңа кирәкмиләр.

Кызык миңа өйрәтүе

Урмандагы җанварларны.

Өйрәтсәмме мин аларны? —

Берсе миңа тимиячәк!

Өйрәтсәмме? —

Урмандагы

Күпме ерткыч кимиячәк!

Зурлар хәйләләшә генә,

Алар мине белмиләр лә —

Мин курыкмыйм

Бернидән дә!

Куркалар

Алар үзләре —

Шуңа алып бирмиләр дә.

Мин барыбер

Арысланнар

Өйрәтүче булачакмын!

Сезне шаккатырачакмын! —

Арысланнар арасында,

Юлбарыслар арасында

Рәхәтләнеп торачакмын!

Әтине дә, әнине дә,

Сезне дә чакырачакмын!

Кулларыгыз авырткачы

Сездән кул чаптырачакмын!

Нишләрбез инде?!

Әллә нинди кыз бу Ләлә:

Әллә ниләр кылана,

Боргалана-сыргалана,

Кыскасы, маймыллана!

Инде берәр эш кушсалар,

Әй Ләлә чәбәләнә,

Киреләнә, үҗәтләнә,

Кыскасы, кәҗәләнә!

Әгәр инде җае чыкса,

Пыр туза безнең Ләлә —

Дусларына очып куна,

Кыскасы, әтәчләнә!

Җитәр инде сиңа, Ләлә!

Үзең түгелме син әллә?

Кәҗәләнмә, әтәчләнмә,

Маймылланма — түз инде!

Кинәт кенә маймыл булсаң,

Йә әтәч, йә кәҗә булсаң,

Белмим, нишләрбез инде?!

## Тәмлетамаклар

### Жираф ашый

Пирожный,

Морж ашый

Морожный.

Челән эчә

«Боржоми» —

Шундый су да

Бар, җаный!

Барбос

Ярата

Ирис,

Ә юлбарыс —

Барбарис.

Яратыр шул,

Яратыр —

Барбариста

Бал бар ич!

Какао һәм

«Кока-Кола»

Ярата, ди,

Коала.

Ә кабан

Ярата, ди,

Банан.

Антилопа

Ярата, ди,

Ананас.

Ул аннан да

Ананасрак

Ананасны

Табалмас!

Пудель —

Коктейль,

Бегемот —

Беренче сорт

Торт,

Ә кит —

Ит белән

Кәнфит.

Кашалот белән

Ат —

Салат

Һәм дә

Лимонад.

Маэмай

Ярата, ди,

Ак май.

Пони белән

Попугай

Помидор

Ярата

Бугай.

Ә мин бик тә

Канәгать,

Әгәр булса,

Җәмәгать,

Бәрәңге белән

Әйрән —

Миңа шулар да

Бәйрәм!

Аннары

Булмас

Артык

Эремчек белән

Катык.

Сез дә карагыз

Татып!

Тик вакытында туктагыз —

Телегезне йотмагыз!

Томау, җиң һәм кулъяулык

Ах, төшкән миңа томау,
Әйбәт түгел томаулау.

Борыннан ага гына!
Сөрткән идем югыйсә
Борынны яңа гына.

Үч иткәндәй, кулъяулык
Нигәдер калган өйдә.
Йөрим менә урамда
Шул томаулаган көйгә...

Борынымны сөртергә
Ярый әле бар җиңем.
Юешләтеп бетердем
Ул җиңемнең бар җирен.

Юпь-юеш шул, юпь-юеш,
Тагын сөртер идем дә.
Борчылмагыз!

Минем әле

Бар икенче җиңем дә!

## Булат барган балыкка

Булат барган балыкка —

Сөн буена таллыкка!

Әле иртә ич, иртә,

Ә балык шундый чиртә!

У-у-у бу Сөндәге балык,

Өлгереп булмас алып!

Көн буена утырып,

Бер басып та бер торып,

Беткән, ди, Булат арып,

Беткән, ди, арып-талып.

Көн буе тоткан балык,

Шаккатыр инде халык!..

Тик буш чиләк күтәргән
Ул балык урынына,

Чөнки балык шәп чирткән...
Булатның борынына!

## Салават күпере

Сөнгә кунган — матур булган
Салаватның күпере.
Тора күзнең явын алып,
Дугаланып, күпереп.

Теге очы — теге якта,
Ә бу очы — бу якта.
Бизәкләре аллы-гөлле...
Әй куйганнар буяп та!

Сөнне мин күп кичкән инде,

Сөн аша күп йөрелгән.

Ә бу юлы чыгып киттем

Салават күпереннән.

Акбай да арттан калмады,

Әмма чыга алмады.

Калды каушап, югалып —

Салават күпереннән

Төшеп калды егылып.

Салават күперенең ул

Белми шул ни икәнен.

Ә мин беләм!

Белгәч менә

Менәмен дә китәмен!

Көз

Авылда алтын көз,

Аз гына салкын көз;

Аз гына җылы көз,
Кошлы һәм җырлы көз;

Кояшлы, якты көз,
Уңышлы, татлы көз;

Уңган һәм тырыш көз,
Тымызык, тыныч көз;

Күңелгә хуш бу көз —
Быелгы ошбу көз.

Еш булмый мондый көз,
Шулай да моңлы көз.

**Шаяннар**

**Н.Гәләвиева рәсемнәре**

Шаяннар

Үртәшкәннәр бер-берсен...
Кем гаепле? Кем белсен...

Алмаз телен тыймаган,
Хәтта кулын тыймаган...

Кәҗә карап торган да,
Мөгезләрен борган да,

Алмазны куып йөртеп,
Төшергән суга төртеп...

Үзе япь-яшь бит әле —
Юньләп сөзә дә белми.

Ә Алмаз нишләр инде —
Ул бит йөзә дә белми.

Кое янында

Ике сәгать гайбәт сата

Суга килгән ике апа.

Онытып бөтен эшләрен,

Бушата алар эчләрен.

Ә казларга тик шул кирәк:

Кое суы тәмле бигрәк!

Мондый тәмле сулар сирәк —

Җитәр микән ике чиләк?

Сабантуй. Көрәш

Көрәшәбез, көрәшәбез,

Яңа баштан керешәбез.

Беребез дә бирешмибез,

Беребез дә бил бирмибез,

Көчебезне белдермибез,

Көчсезлекне сиздермибез.

Без беребез дә җиңмибез,

Беребез дә җиңелмибез...

Сабантуй. Кашык белән йөгерү

Чаптар атлардай ярсып,

Түтәйләр тора басып,

Көчләре тора ташып.

Авызларында — кашык.

Һәр кашыкта — бер күкәй...

Әй чапканнар, чапканнар...

Артта калган бер түтәй.

Ул түтәй озак чапкан,

Барсыннан да соңарган.

Ул финишка җиткәнче,

Күкәй чеби чыгарган.

## Шаян бабай

Шаян бабай, мут бабай,

Наян бабай, ут бабай!

Уйнап тора күзләре,

Янып тора йөзләре!

Карт бабай да димәссең, —

Бу картларны белмәссең...

Өтәч тора: «Ай–яй! — дип. —

Өтәчләнмә, бабай!» — дип.

Күршеләр

Күрче, күрче,
Йон эрли ике күрше.

Күр, күр әле,
Йоннары бик күп әле.

Кара, кара,
Эшләре акрын бара...

Икесенә бер орчык шул,
Икесенә бер каба.

Чәй эчкәндә

Өй эчебез әй ямьле,
Ә чәебез әй тәмле!

Эчәбез өрә-өрә,

Эссе булганга күрә...

Ә мәче юкка ятмый,

Чөнки ул чәй яратмый.

Аңа тәмле сөт булсын! —

Сөт булсын, сөт күп булсын!

Мәчегә аңа сөтнең

Өсте булса да ярый.

Ә сөтнең өсте булса,

Эссе булса да ярый.

Авылда

Гайникамал әбекәй

Ничә генә санамый:

Бер бәбкәсен табалмый.

Эзләп карый аннан да,

Эзләп карый моннан да!

Бер керә дә бер чыга,

Тик ул юкка борчыла.

Ул бәбкә иртә таңнан

Арыган, арган-талган,

Ул шуңа артта калган,

Рәсемгә сыймый калган.

Иртәнге хәбәрләр

Чыккач абзар-курага,

Чыккач көтү куарга,

Онытып сыерларын,

Серләшәләр серләрен.

Хәбәрләрне апалар

Әйтерсең автоматтан,

Пулеметтан аталар...

Ә сыерларның исә
Тик телләре салынган.

Чөнки хуҗабикәләре
Телләренә салынган.

Серле көлдә

Алтын ай, алтын тарак.
Утыра Гали басмада
Алтын таракка карап.

Алыр иде, шикләнә,
Курка су анасыннан.
Килеп чыгар шикелле
Төнбоек арасыннан...

Алтын ай, алтын тарак...
Ялгыш уйлый күрмәгез,

Түгел лә Гали карак.

Тиктормас-йокламас

Әлли-бәлли-бәү инде,

Минем әни дәү инде!

Ул хәзер бәү-бәү итә,

Бәү итә, йоклап китә.

Әнә, йоклап та китте,

Чөнки вакыты җитте...

Уйныйм әле туйганчы,

Әнием уянганчы!

Өй түбәсендә

Көндезен дә, төнлә дә
Ике мәче түбәдә.

Берсе ап-ак — көн төсле,
Берсе кара — төн төсле.

Тапканнар бит әй юлын,
Тапканнар тыныч урын.

Монда беркем шауламый,
Беркем комачауламый...

Әйдә, алар мырлашсын,
Теләкләре булгачтын.

Тәмле сөт

Сыер сава әнием.

Ә минем

Бик сөт эчәсем килә,

Тизрәк үсәсем килә.

Сыер тәмле сөт бирә,

Сөтне сыер күп бирә.

Тик сыер үзе никтер

Ялый минем битемне.

Ярар инде, мин сөт төсле

Тәмле түгел бит инде.

Җәй

Чәчәкле җәй, җылы җәй,

Тургайлы җәй, җырлы җәй.

Кояш кебек якты җәй,

Алма кебек татлы җәй.

Канатыңны, яле, җәй,

Җиләкле җәй, ямьле җәй!

Уйна, гармун!

Егетләр урам буйлый,

Ә берсе гармун уйный.

Җыр суза калганнары,

Җыр җырлый алганнары.

Әйттерә генә алар,

Типтерә генә алар.

Сиптерә генә алар...

Кызлар гына күренми,

Тәрәзәдән үрелми...

Ишетеп ята алар

Җыр җырлап уйнаганны.

Кызлар гына уяныр,

Әбиләр уянганны.

Суык

Кыш килде.

Полундра!

Әйтерсең лә

Тундра!

Өшеттерә,

Туңдыра!

Ну бу суык

Булдыра!

Суык башка

Кундыра!..

Ашамагыз

Туңдырма!

Әнә, песи

Ашаган...

Һәм йөткерә

Башлаган.

Керәсе килми өйгә

Әллә нинди бүген һава:
Өстебезгә нидер ява.

Яңгыр да яуган шикелле,
Яфрак та яуган шикелле.

Тик без аны тоймыйбыз да,
Без нигәдер туңмыйбыз да.

Керәсе килми өйгә дә,
Җылы бит шушы көйгә дә.

**Без сугыш теләмибез!**

КАДЕРЛЕ БАЛАЛАР!

Сез барыгыз да тынычлык телисез, тынычлык өчен үзегез дә көрәшәсез. Сезнең якты, имин тормышта яшисегез килә. Дөньядагы барлык балаларның да уртак теләгедер ул — ТЫНЫЧЛЫК!

Кайчандыр мин Америкада яшәүче балаларның атом сугышына каршы язылган сүзләрен укыган идем. Алар — сезнең яшьтәшләрегез, 6 — 10 яшьлек малайлар, кызлар. Аларның сүзләре мине тетрәндерде, дулкынландырды, уйландырды.

Алар да, сезнең кебек үк, тынычлык телиләр икән.

Алар да атом, бомба, сугыш, үлем кебек ямьсез сүзләрне күрә алмыйлар.

Аларның да иң яраткан сүзләре — тынычлык, бәхет, кояш, шатлык.

Аларның да тыныч Җиребездә бәхетле булып үсәселәре килә.

Америка балалары исеменнән язылган әлеге шигырьләрем сезнең дә теләкләрне чагылдырадыр дип ышанам.

Дулкынландырмагыз мине!

Берәрсе бомба турында

Сөйли башлады исә,

Йә берәрсе ялгыш кына:

«Атом бомбасы», — дисә,

Кинәт дулкынлана башлыйм

Бернигә дә карамый.

Ә миңа дулкынланырга

Әле бер дә ярамый.

Дулкынлансам, бит очларым

Күз яшенә чылана...

Дулкынландырмагыз мине —

Докторлар ачулана!

7 яшьлек Билли К.

Ак кәгазь бите

Мин ясаган менә шушы

Рәсемне күрәсезме?

Бу бит чип-чиста ак кәгазь

Бите дип көләсезме?

Бу ак кәгазь бите түгел,

Түгел гади аклык та.

Сугыштан калган бушлык бу —

Хыял да бу, хаклык та.

Дөнья нәкъ шулай булачак

Бомба шартлаганнан соң —

Тормыш түгел, ап-ак бушлык

Калачак бит аннан соң.

8 яшьлек Синтия К.

Сорагыз!

Атом-төш коралы

Куркыткыч,

Коточкыч!

Атом-төш коралы

Коточкыч

Куркыныч!

Аның ни икәнен

Үлгәннәр

Белгәннәр.

Сорагыз, сорагыз —

Әйтерләр

Үлгәннәр!

9 яшьлек Филлис Х.

Авыру йоксын иде!

Елмаймыймын да көлмимен —

Нишләргә дә белмимен

Бомбаның нәрсә икәнен

Белгәнемнән бирле мин.

Бомбаларны җил очыртсын

Яки җир йотсын иде,

Йә аларга йогышлы бер

Авыру йоксын иде.

Ул чагында бомбаларга

Беркем дә тимәс иде,

Хәтта иң явыз кеше дә

Янына килмәс иде!

7 яшьлек Джей Р.

Без сугыш теләмибез!

Сугыш теләми балалар,

Бәбиләр һәм сабыйлар.

Нәни җәнлекләр дә сугыш

Кирәкми дип саныйлар.

«Сугыш» дигән сүз үзе дә

Кыса безнең сулышны.

Зурлар белән крокодиллар

Телидер ул сугышны.

10 яшьлек Энтони Р.

Теләмим!

Атом бомбасы турында

Мин берни белми идем.

Ул бомбаны хәзер инде

Күрәсем килми минем.

Бомбаларның кешеләрне

Үтергәнен беләм мин.

Җирдә иң соңгы кеше дә

Булырга мин теләмим!

Ялгызым җирдә нишләрмен? —

Куркам хәтта уйларга...

Аннары, яратмыйм да мин

Үзем генә уйнарга.

6 яшьлек Лора Р.

Әкияттә генә булган...

Атом бомбасы ниндиме? —

Ул Аждаһа төследер.

Усалдыр, бик тә явыздыр,

Ерткыч төсле көчледер.

Охшагандыр Убырлыга,

Пәригә йә Диюгә.

Шулар килә күз алдыма

«Бомба! Атом!» диюгә.

Ул ут чәчеп торган күзле,

Зур капкорсак эчледер.

Бик ямьсездер — зур авызлы

Һәм бик озын тешледер.

Ачылгандыр безне йотар

Өчен ул зур авызлар...

Элек әкияттә генә

Булган андый явызлар.

8 яшьлек Энди Х.

Ничек уйлыйсыз?

Генераллар алар бары

Сугыша гына белә.

Күрә алмыйм мин аларны

Шуңа күрә дә менә.

Төяр идем дә көймәгә

Бөтен генералларны,

Океан уртасына ук

Илтер идем аларны.

Куркып тормас идем әле

Мин аларның каршында —

Бушатыр идем утрауга

Мин аларның барсын да!

Калдырыр идем онытып

Шул утрауда аларны.

Ничек уйлыйсыз, аларны

Шулай итсәм ярармы?

9 яшьлек Бобби С.

Яшәү рәхәт түгелмени?!

Үтенәм сездән, абыйлар,

Бомбаларны тыегыз!

Беркем табалмаслык итеп

Йә яшереп куегыз!

Әгәр үзен бетермәсәк,

Ул Җирне бетерәчәк.

Бомбалар Җирдәге бөтен

Кешене үтерәчәк.

Ясамагыз яңа бомба,

Кызыгып кара данга.

Яшәү рәхәт түгелмени

Үлүгә караганда?!

7 яшьлек Энни Г.

Астронавт абыйга хат

Астронавт абый!

Сез тагын

Очасызмы галәмгә?

Яңадан шунда очарга

Уйласагыз әгәр дә,

Минем бер шәп тәкъдимем бар.

Зинһар, көлмәгез, яме.

Минем шушы тәкъдимемә

Каршы килмәгез әле!

Бомбаларны ракетага

Төяп китмәссез микән?

Шуларны Марска яки

Айга илтмәссез микән?

Ятсыннар шунда тутыгып,

Бернигә кирәксезгә.

Астронавт абый!

Бу хакта

Уйларга кирәк безгә!

9 яшьлек Ричард Л.

Белмиләр шул әле...

Атом-төш бомбасын

Җәнлекләр белсәләр,

Аның ни икәнен

Әгәр дә күрсәләр,

Алар да җыелып

Киңәшерләр иде,

Бомбаларга каршы

Көрәшерләр иде!

Алар бомбаларны

Пыр туздырыр иде,

Сугыш чукмарларын

Әй кыздырыр иде!

Җәнлекләрдән качар

Иде ул бомбалар...

Их, белми шул әле

Бу хәлләрне алар.

7 яшьлек Марк М.

**Хәрефләр бәйрәме**

Хәрефләр бәйрәме

**Хәрефләр төрле-төрле,**

**Хәрефләр тере-тере...**

**Үзләре сәйлән-сәйлән,**

**Бииләр әйлән-бәйлән!**

**Тезелгән әнә бергә**

**Сүзләргә әйләнергә.**

**Рәхим ит, дустым, әйдә,**

**Хәрефләр бәйрәменә!**

Актаныш

Бигрәк ямьле Актаныш та,

Арча да, Аксубай да...

Гүзәл яклар илебездә

Бик күп икән шулай да!

Әтәч

Иң матур төш күргәндә,
Төшкә әни кергәндә,

Тотына кычкырырга —
Туры килә торырга.

«Тор! Тор!» — диеп әйткәч тә
Үпкәләмим әтәчкә!

Болгар белән Биләр

Безнең борынгы шәһәрләр —
Бөек Болгар һәм Биләр!

Заманында алар бик зур,

Бик гүзәл булган, диләр.

Үзегез барып күрсәгез,

Белерсез әллә ниләр!

## Вагон-вагон виноград

— Кайткан Казан вокзалына

Тәлгәш-тәлгәш виноград.

— Вагон-вагон виноградтыр,

Әйт сүзеңне уйлабрак.

## Герб

Россиядә — россияннар,

Марста — марсианнар.

Гербыбызда ап-ак барс,

Без хәзер — барсианнар!

Дамир белән доктор

Дамир: «Дару эчмим», — диеп,

Әнисен аптырата.

Укол кадап китәр әле

Дамирга доктор апа.

Елга

Бездә елгыр елгалар күп:

Агыйдел, Зәй, Мишә, Сөн...

Барсы да койгачтын, Идел

Киң булмыйча нишләсен?!

Жилет

Әнием алды жилет —

Шатлыгымның чиге юк!

Караган идем киеп —

Жилетымның җүне юк,

Чөнки аның нигәдер

Бер генә дә җиең юк.

Җәлил

Һәйкәл булып басып тора

Мәйданда Муса Җәлил.

Татарның батырлыгына

Менә ул кайда дәлил!

## Закон

Ул безгә бик кирәк китап,

Ул безгә бик тә якын! —

Ул бит Конституция,

Ул бит безнең Төп Закон!

## Итек

Колга башында — итек!

Менәргә ничек итеп?

Колга төбендә басып

Торам менә баш кашып...

Итексез йөрим микән?

Колгага меним микән?

## Йозак

Иртә кайттым бүген дә,

Торам ишек төбендә.

Торам инде бик озак...

Ачылмый гына йозак.

Көтәм әни кайтканын, —

Ачкычны югалтканмын.

## Казан

Кремль, Казансу, Кабан...

Күкләргә ашкан Казан!

Төбәлгән карашыбыз

Гүзәл Казанга табан!

## Ләгән

Безнең өйдә бөтенесе

Бер ләгән.

Ә кибеттә андый ләгән

Меңләгән!

Мәчет

Тора ерактан күренеп,

Тора нур чәчеп,

Тора күзнең явын алып,

Үзенә дәшеп,

Авылыбыз уртасында

Матур зур мәчет!

Нәүрүз

Хуш киләсең, гүзәл Нәүрүз! —

Язгы Яңа елыбыз.

Яңа елда туры булсын,

Нурлы булсын юлыбыз!

Еракларга яңгырасын

Безнең дәртле җырыбыз!

«ңат»

«ңат» дигән сүз булмый,

«Таң» дигән сүз була,

Чөнки «ң» хәрефе

Баш хәрефсез була.

Оя

Һәркемнең үз оясы бар! —
Безнең дә үз оябыз.

Татарстанда үзебезне
Без бәхетле тоябыз!

Өрек

Өшеткәч тышта йөреп,
Китәбез өйгә кереп.

Иренебезне бөреп,
Без чәй эчәбез өреп.

Салынган чәйгә өрек, —
Авызда тора эреп!

Песи

Песигә «перес!» диюгә,

Шунда ук читкә китә.

Күземә карап аннары

«Пес-пес» дигәнне көтә.

## Рам

Әтием ясый рам,

Мин тотышып торам.

Әйбәт чыкты бу рам —

Күренә бар урам.

## Сабантуй

Сабантуй — иң әйбәт бәйрәм,

«Сабантуй» — иң шәп гәзит!

Дөньяда андый бәйрәмнәр,

Андый гәзитләр әз бит!

Татарлар

Уралда да, Себердә дә,

Иделдә дә татар бар.

Мишәрләр дә, керәшеннәр дә,

Типтәрләр дә — татарлар.

Үзләрен алар һәрвакыт

«Татарлар» дип атарлар!

Улак

Салкын чишмә ургый-ургый

Агып ята улактан...

Моңы китми күңелләрдән,

Җыры китми колактан.

Үтүк

Тордым да иртән иртүк

Кулыма алдым үтүк.

Тик үтүк шундый итеп

Кулымны алды өтеп.

Чак кына еламадым.

Еладым... чыдамадым.

Флаг

Шундый матур яшел төсе,

Ул кызылы, ул агы!..

Җилферди Казан өстендә

Безнең дәүләт флагы!

## Хоккей

Кычкыралар: «Бәр! Гол! Ура!

Молодец! О,кей!»

Дер селкенә стадион,

Гөр килә хоккей!

## Һава

Сулап туймаслык

Бездәге һава.

Бездәге һава —

Үзе бер дәва!

## Цирк

Казан циркында — циркачлар,
Башларында — цилиндр!

Цилиндрлары тәгәри, —
Башларына сыймыйдыр.

## Чаллы

Чаллыда чаба «КамАЗ»,
Чаллыда ага Кама.

Чаллы матур, зур кала,
Безнең Казаннан кала!

Тырышса, Казанны да
Ул узып китә ала!

Шүрәле

Шүрәле и килбәтсез,
Чалбарсыз һәм күлмәксез.

Җәй дә, кыш та туннан ул,
Шундый булып туган ул.

Тугач нишләсен инде,
Шулай яшәсен инде!

Щи

Безнең өйдә бүген бәйрәм!
Кунакка дәшәм сине.

Авыз итәргә әнием
Пешергән тәмле щине.

## Ык

Карап торам мин кызыгып:
Агулары тымызык.

Суы тирән, суы суык,
Үзе тонык, үзе Ык.

## Элеватор белән эскерт

Бушап калган көзге басу —
Юк комбайны, сабаны.

Элеваторда — икмәге,
Ә эскерттә — саламы.

## Юл

Һава юлы, йолдыз юлы,

Трамвай юлы, су юлы...

Асфальттан гына Казанга

Барам әле бу юлы.

Ярыш

Атлар чаба сабантуйда,

Кыза гына ярыш!

Кыза гына узыш, алыш,

Кыза гына чабыш!

Читкә каермасын ялгыш,

Ялларына ябыш!

Дустым!

**Хәрефләр серле-серле,**

**Хәрефләр тылсым-тылсым.**

**Тылсымлы бу хәрефләр**

**Һәрвакыт юлдаш булсын!**

**Хәзер инде син, дустым,**

**Тылсымчы бит үзең дә.**

**Рәхәтләнеп укыйсың**

**Татарның бар сүзен дә!**

**Өркетмәгез!**

Безнең авыл зоопаркы

Шәһәр малайларының

Күргәне юк гомергә

Бездәге җәнлекләрне,

Бездәге кош-кортларны.

Теләсәләр күрергә,

Килсен алар авылга,

Аптыраштa калырга!

Алар бездә өй саен,

Күреп була көн саен!

Атлар бездә көн буе

Кешегә эшләшәләр.

Яшь тайлар хәлләреннән

Тайганчы кешнәшәләр.

Колыннар да туйганчы

Уйныйлар, тешләшәләр.

Кәҗәләр сөзешәләр,

Чучкалар җир чокыйлар,

Ә үрдәкләр, ә казлар

Көн дә үлән чукыйлар.

Күркәләр кабарына,

Җим эзли кабарына.

Әтәчләр һәм тавыклар

Тары чүпли савыттан.

Ә сарыклар, бәрәннәр

Киртәгә сыенганнар,

Бергәрәк җыелганнар.

Чебешләр һәм бәбкәләр,

Качып канат астына,

Йокларга җыенганнар.

Бирегә кайчагында

Мәче дә кереп чыга,

Бирегә кайчагында

Мәче дә кереп чыга,

Биредәге дусларын

Маэмай да күреп чыга.

Кайчагында бирегә

Каргалар килеп куна,

Саесканнар, песнәкләр,

Чыпчыклар кереп тула...

Алар янына безгә

Көн дә керергә була.

Көн дә кереп, аларның

Хәлен белергә була.

Һәрберсе таный безне,

Һәрберсе тыңлый безне.

Җәнлек һәм кошларыбыз

Барсы да — дусларыбыз!

Авылыбызда өй саен

Менә шундый зоопарк.

Зоопарктан ким түгел

Безнең дә абзарпарк!

Җиде абый тай җигә

Яшь бер тайны

Җигәр өчен,

Шул бер тайны

Җиңәр өчен

И тырыша

Җиде абый,

И булыша

Җиде абый!

Тик тай дулый!

Кыргыйдыр ул,

Шуңа да тик

Тормыйдыр ул,

Шуңа күккә

Ыргыйдыр ул,

Шуңа җирне

Тырныйдыр ул!

Аны һич тә

Җиңеп булмый,

Хәтта якын

Килеп булмый,

Тибүе бар! —

Белеп булмый.

Тайны әйтәм,

Шундый көчле! —

Коеп куйган

Минем төсле!

Мине ләкин
Җибәрмиләр,
Җитмәс синең
Җегәр, диләр.

Алар мине
Белмиләр шул,
Минем көчне
Күрмиләр шул.

Җәфа чиксәм
Чигәр идем,
Мин ул тайны
Җигәр идем,
Мин ул тайны
Җиңәр идем,
Туйганчы бер
Җиләр идем...

Ләкин мине
Җибәрмиләр,
Якын барма,
Тибәр, диләр,
Йә әниең
Тиргәр, диләр,
Кирәк монда

Ирләр, диләр...

Ә үзләре
Җигәлмиләр,
Шул бер тайны
Җиңәлмиләр,
Адәм тәганәләре!

Пират

Пират бара
Урамнан.
Курыкмагыз
Сез аннан!

Йөрми ул
Хәнҗәр асып,
Йөрми ул
Кораб басып.

Аның бит әле

Хәтта

Гомерендә бер

Кат та

Корабны

Күргәне юк,

Диңгездә

Йөргәне юк,

Бер дә су

Кергәне юк...

Алай булгач,

Ул пират

Каян килгән

Дисезме?

Шуны да

Белмисезме?

Ул бит Пират исемле

Маэмайның исеме!

Мөгезсез бозау

Бабайларга авылга

Кайтсам җәен кунакка,

Дәү әти һәм дәү әни

Тукый минем колакка:

— Бозаудан сак бул! — диләр. —

Усал, сөзгәк ул! — диләр.

Күргән инде мин аны:

Бозаулары — мөгезсез.

Мөгезсез ул беркемне

Сөзә алмый — күрерсез!

Белмиләрдер әле — мин

Үгездән дә өрекмим.

Чын баһадир кебек мин,

Чын матадор кебек мин!

Мин бит, әгәр теләсәм,

Үгезнең үзен егам!

Мин бит, әгәр теләсәм,

Үгезнең йөзен егам!

Мускулларны уйнатып

Киттем туры бозауга.

Алай бик усал икән,

Күрсәтербез без аңа!

Аннарымы? Аннары...

Дәвамы бик күңелсез:

Әлеге бозау мине

Сөзеп еккан... мөгезсез!

Авыртса да сөзгән төш,

Түзәргә була икән.

Теләсәң, мөгезсез дә

Сөзәргә була икән!

Кыр кәҗәсе

Нишләтергә

Кәҗәбезне?

Аптыратты

Кәҗә безне.

Бер генә дә

Тыеп булмый,

Бер дә ябып

Куеп булмый.

Ача — кача,

Ача — кача,

Аптыратты

Кача-кача.

Ялан-кырдан

Кайтып керми,

Куркыталмый

Аны берни!

Нигә куркак

Булсын ди ул?

Нидән куркып

Торсын ди ул?

Мин бит аның

Көчен беләм:

Кирәктә ул

Бүре белән

Сөзешергә

Хәтта әзер —

Кыр кәҗәсе

Бит ул хәзер!

Кызыл тавык

Безнең кызыл тавыкның
Чебиләре унбишләп.
Чебиләрен саклап кына
Йөртә микән ул нишләп?

Алар янына
Килсәм,
Килеп яратыйм
Дисәм,

Чебиләр
Тик тормыйлар,
Чебиләр
Тоттырмыйлар.

Кызыл тавык
Шунда ук
Килә дә
Очып кына,

Өстемә

Очып куна,

Котылам

Качып кына...

Кызыл тавык чебиләрен

Бер дә читкә таратмый.

Чебиләрен ярата ул,

Мине генә яратмый.

Чебиләрен яраттырмый,

Тоттырып та каратмый.

Әйтегезче, кызыл тавык

Нигә мине яратмый?

## Песнәк белән сөйләшү

И песнәгем, белеп торам,

Күреп торам — туңгансың.

Соң син бит безнең балконга

Җылы эзләп кунгансың.

Йоннарыңны кабарткансың,

Калтырыйсың — күр инде.

Җылыда җырлавы рәхәт —

Әйдә, безгә кер инде!

Югыйсә елап җибәрәм,

Торма инде салкында.

Кермәсәң безгә хәзер үк,

Үзем чыгам балконга.

Син туңсаң, мин дә туңармын.

Туңсам, белерсең әле...

Салкында торып авырсам,

Елап йөрерсең әле!

Елмаючы... бүреләр

Ясадым мин дәфтәремә

Бүренең би-ик явызын:

Озы-ын иттердем тешләрен,

Зу-ур иттердем авызын...

Шуннан соң ул миңа таба
Карап тора башлады.
Курыктым да, бүрене мин
Тизрәк ертып ташладым.

Юкса нишли дип торам,
Мине тешли дип торам.

Бүреләрне усал итеп
Ясамам мин моннан соң —
Бүреләр ямьсез булса да,
Усал, явыз булмасын!

Мин ясаган бүреләр гел
Әйбәт кенә булырлар,
Тыйнак кына утырырлар,
Елмаешып торырлар.

Безгә килгәч, рәсемемне
Дусларым да күрерләр.
Ошамый калмас аларга
Елмаючы... бүреләр!

Акбайга

Йөрмә, Акбай, безнең янда,
Йә тешләрсең, кит әле!
Песиебезгә дә өрмә —
Ул бәләкәй бит әле.

Юлбарыска охшаган ул
Безнең песи баласы.
Чынлап юлбарыс булган, ди,
Аның ерак бабасы!

Ул да үскәчтен юлбарыс
Булыр әле — күрерсең.
Алай бик батыр икәнсең —
Менә шунда өрерсең!

Урамнан фил китеп бара

Урамнан фил китеп бара,
Урамнан фил үтеп бара.
Барсы да аптырыйлар,
Гаҗәпләнеп карыйлар.

Каян килгән, ничек килгән,
Кайчан килгән ул, диләр.
Безнең Казанга килергә
Ничек белгән ул, диләр.

Фил янында кешеләр дә,
Трамвайлар да кечкенә.
Ничек шулай үсә алган? —
Аңлап булмый һич кенә.

Ә фил бер дә гаҗәпләнми:
Каранып ары-бире,
Казан урамнары буйлап
Бара да бара бирә...

Казан циркына барырга
Чыккан икән филебез.
Фил күрергә теләсәгез,

Сез циркка килегез!

Без барып тормыйбыз инде —

Әле яңа таралдык,

Циркны билетсыз гына

Без урамда карадык!

Акбай цирк карый

1. Аюлар

Әйбәтләп аңлатып бирсәң,

Әйбәтләп куштың исә,

Чаж да чож да чаж да чож

Аюлар утын кисә.

Әмма утын кискән өчен

Сөт эчертергә кирәк.

Эш җиңел түгел, янәсе:

Сөт — көч кертергә кирәк!

Ай-яй иркә өйрәнгәннәр —

Кара инде нишлиләр?!

Сөт бирсәң, утын кисәләр,

Сөт бирмәсәң, кисмиләр!

2. Зебра

Зебраны күргәч, Акбаем

Чак артыннан чапмады.

Көчкә тыйдым!

Чабар да ул —

Була андый чаклары.

Мондый буйлы-буйлы атны

Күргәне юк шул аның,

Мондый атка бер тапкыр да

Өргәне юк шул аның.

Өрер иде дә, зебра бит

Әйләнеп тә карамый.

Аннары, кеше күп җирдә

Өрергә дә ярамый!

3. Маэмай

Бер маэмай чабып чыкты,

Баш иде безгә карап.

Әллә кем диярсең — үзен

Тотышы ай-яй харап.

Божрадан сикерә белә,

Ике аяклап йөри.

Акбай гына күрмәмешкә

Салынган була юри.

Әллә маэмайның тотышы

Аңа бер дә ошамый,

Әллә артист-маэмайның

Этлегенә ышанмый.

Барыбер Акбай түзмәде,

Күргәч аның биюен.

Шыңшып куйды.

Бу — мине дә

Шулай өйрәт, диюе.

Әнә бит ничек ялварып

Утыра ул теземдә.

Бик өйрәтер идем, Акбай,

Бии белмим үзем дә!

4. Бегемот

Бегемот чыкты да безгә

Аптырап карап тора.

Янәсе, басып торсаң да,

Әлеге ярап тора.

Курыкма син, Акбай, аннан,

Ялкау бит ул — тешләми.

Үзең усаллык кылмасаң,

Бернәрсә дә эшләми.

Бигрәк иренчәк тә инде —

Ашыкмас ул һичкайчан.

Әнә бит — баядан бирле

Селкенми дә, ичмасам!

Әйтерсең лә береккән ул

Басып торган җиренә —

Шул басып торган җиренә

Ятарга да иренә.

Акбайның гаҗәпләнүе

Чыккан хәтта йөзенә.

Мин андый ялкау түгел дип,

Карап тора күземә.

Диңгез төбендә

Диңгезгә килгән көнне үк
Чумдым диңгез төбенә.
Һәм юлыктым... акуланың
Иң усал бер төренә!

Шундый очлы тешләре!
Шундый шома түшләре!

Койрыгын болгап тора!
Су астын болгаттыра!

Күзәтә мине үзе,
Гел миндә генә күзе!

Вәт акула! Рәсемдәге
Акулалар чүп кенә.
Ул акула мине ялгыш
Тешләмәде чүт кенә.

Күргәне булмагач, башта

Танымагандыр инде.

Шәп малай булганга гына

Кагылмагандыр инде.

Мин дә аны су астында

Ныклап таный алмадым.

Дөресен генә әйткәндә,

Ныклап карый алмадым.

Миңа калса, ул акула

Бик көчле түгел иде.

Миңа калса, тешләре дә

Бик очлы түгел иде.

Ахрысы, ул суда гына

Зур булып күренгәндер.

Ахрысы, ул юри генә

Тешләргә үрелгәндер.

Мөгаен, ул койрыгын да

Шаяртып болгагандыр.

Бәлки әле, ул бөтенләй

Акула булмагандыр?

Булмагандыр...

Түгел лә мин

Акула күргән кеше.

Мин бит беренче мәртәбә

Диңгезгә кергән кеше!

Өркетмәгез!

Өркетмәгез,

Өркетмә!

Өрекмим мин

Бөртек тә!

Курыкмагач

Курыкмыйм

Ул әтәч

Пыр тузса да,

Кәефемне

Бозса да,

Кызса да,

Тузынса да,

Аз гына

Узынса да...

Курыкмагач
Курыкмыйм
Бар көчкә
Чаптырса да,
Чалбардан
Каптырса да,

Өскә килеп
Кунса да,
Артык усал
Булса да,

Хәтта куып
Тотса да,
Аз гына
Куркытса да...

Курыкмыйм ул
Әтәчтән!

Эт миңа тел күрсәтә

Үчеклиме эт мине?
Әллә: «Эссе бик!» — диме?

Күрсәтә миңа телен,
Аңлый алмыйм тел төбен.

Ә-ә-ә, салкынны сагынган,
Теле шуңа салынган!

Журнал укучы жираф

Журнал, китап укырга
Жираф бик тә яраткан.

Ләкин укый алмаган
Югарыдан, ерактан.

Башын иеп караган,
Күзлек киеп караган.

Тик берни дә күрмәгән —

Нишләргә дә белмәгән.

Кайгыга баткан жираф,

Уйланып яткан жираф.

Һәм укуның әмәлен

Барыбер тапкан жираф.

Утыра хәзер жираф

Гел журнал укып кына —

Укый жираф кулына

Бинокль тотып кына!

Сөзәргә өйрәнә

Бәрәнебез,

Күрегез —

И бәргәли

Койманы,

Койманымы

Кыйнавы?

Әллә инде

Уйнавы?

Юк, өйрәнә

Сөзәргә,

Мөгезләрен

Төзәргә.

Маңгае бик тә

Сызлый,

Сызлавы һич тә

Узмый.

Туры килә

Түзәргә

Өйрәнгәндә

Сөзәргә.

Шунсыз булмый

Өйрәнеп,

Китәр әле

Көйләнеп.

Өйрәнер ул
Күзләргә
Әйбәт итеп
Сөзәргә.

Сөзешсен әйдә,
Сөзсен,
Мөгезе генә
Түзсен!

Сакчылар

Бар бакчада кишер дә,
Бар бакчада кыяр да.

Тик тәмлетамакларны
Ничек кенә тыярга?

Кермәкче алар бик тә —
Капкасында юк бик тә.

Тик бакчадан аларның
Алына ла котлары.

Көннәр буе бакчаны
Саклый шул бал кортлары.

Белдерү

Баганада
Язу күреп,
Әле шыңшып,
Әле өреп,
Шул язуны
Укый бер эт.

Үзе укый,
Үзе уйлый —
Бу язуда ни икән?
Берәрсенә минем кебек
Көчек кирәкми микән?

Кро!ко!!дил!!!

Крокодил ул,
Белсәгез,
Крокодил ул,
Күрсәгез,

Бик әйбәт,
Юаш җанвар,
Юк андый
Юаш җаннар.

Сөйкемле ул,
Ягымлы,
Өстәвенә
Талымлы.

Койрыгына
Басмасаң
Йә йокысын
Ачмасаң,

Күзләрен

Йомган булса,

Корсагы

Тулган булса,

Сызламаса

Тешләре,

Авыртмаса

Эчләре,

Уйламый да

Тияргә,

Мөмкин хәтта

Сөяргә...

Әгәр дә

Көчле булсаң!

Крокодилның

Нәкъ үзе

Төсле булсаң...

Тик... ни...

Бик үк ышанып

Бетмәгез лә

Сүземә.

Иң яхшысы —

Күренмәү

Кро! ко!! дил!!!ның

Күзенә.

Черки, чабак,

чуртан һәм чиләк

Черкине

Чабак

Тоткан,

Чабакны

Чуртан

Йоткан.

Чиләккә

Чумган

Чуртан —

Тотар

Идем дә...

Куркам!

Ачыгавыз

Күр,

Ак куян —

Куркак

Куян

Ята

Йоклап,

Куәт

Туплап.

Уян,

Куян,

Уйлан,

Куян —

Сиңа

Кыям

Капкын

Куйган!

Капкын —

Усал,

Капкын —

Явыз.

Каба

Күрмә,

Ачык

Авыз!

Көнгерә

Көнгер-көнгер

Көнгерә

Әй йөгерә,

Элдерә.

Көнгерәгә

Өлгерәдер

Кемнәр генә,

Кем генә?

Көнгер-көнгер

Көнгерә

Бөтенесен

Көлдерә:

Олы кесә

Тектергән,

Кесәсен зур

Иттергән.

Кесәдән кем

Күренә?

Кесәдән кем

Үрелә?

Ул кесәдә

Көн күрә

Кечкенә бер

Көнгерә,

Аңа шунда

Үсәсе.

Килми бугай

Төшәсе.

Монда үсәргә

Мөмкин:

Бигрәк иркен,

Бигрәк киң,

Бик тә җылы,

Бик җайлы,

Бигрәкләр дә

Уңайлы

Әнисенең

Кесәсе,

Килми шуңа

Төшәсе...

Күнгер-күнгер

Күнгерә...

## Төклетура

Бар микән ул берәр урман

Төклетурасыз? —

Әйтми-нитми чагып китте,

Вәт культурасыз!

Бытбылдык

Балалар
Чыккач та,
Биеккә
Очкач та,
Сөенгән
Быт-был-дык:
— Күп бул-дык!
Күп бул-дык!

Сыйланып
Туйгачтын,
Туйганын
Тойгачтын,
Җырлаган
Быт-был-дык:
— Тук бул-дык!
Тук бул-дык!

Очрагач

Каршыга

Тилгән йә

Карчыга,

Кычкырган

Быт-был-дык:

— Юк бул-дык!

Юк бул-дык!

## Елан белән камчы

Минем елан күргәнем бар —

Ул нәкъ камчы төслерәк.

Ләкин абыйның камчысы

Еланнан да көчлерәк.

Елан шикелле уйнаклый

Камчы абый кулында.

Чыннан да, котың алыныр,

Очраса ул юлыңда.

— Кулга ияләштерелгән

Елан ул, — ди абыем. —

Шуңа күрә озын, усал,

Елдам ул, — ди абыем.

Еланнан курыккан кебек

Курка аннан атлар да.

Еландыр дип уйлап куям

Мин дә андый чакларда.

Уйласам да, шикләнсәм дә,

Курыкмыйм ла тамчы да...

Сүзлектән үзем карадым —

Чын елан бит камчы да!

## Аю

Аю килгән Казанга,

Кереп чыккан базарга.

Килгән аю бал өчен —

Сизгән булган бал исен.

Тик юлы уңмаган, ди —

Акчасы булмаган, ди.

## Дөя

Өстенә йөк

Өя-өя,

«Йөгем авыр!» —

Дия-дия,

Шуның өчен

Көя-көя,

Кояшта да

Көя-көя,

Башын аска

Ия-ия,

Аннан өскә

Чөя-чөя

Чүлдән бара

Көяз дөя.

Дөя — чыдам,

Дөя — чая!

Бара икән

Дөя кая?

Эт

Көн буе

Йөргән эт,

Төн буе

Өргән эт.

Йөргән эт

Тешләшеп,

Йөргән эт

Этләшеп.

Сизми дә

Калган эт —

Эт булып

Арган эт!

Үрдәк

Бака кебек бак та бак,

Бак та бак килә үрдәк.

Менә шулай була ул

Бакадан алсаң үрнәк.

Ташбака

Таш урамда

Таш ята.

Таш түгел лә,

Ташбака.

Бар бакага

Баш бака.

«Нигә соң мин

Таш бака?» —

Дип, ташбака

Баш вата.

Ә кешеләр

Шакката —

Берәүләре

Ашата,

Берәүләре

Таш ата.

«Ярый әле

Таш бака

Булганмын!» — ди

Ташбака.

Йомран

Йомшак йонлы йомранның

Йомры башы күренде.

Йомрыланган үзе дә,

Нәкъ йон йомгак, күр инде!

## Карлыгач

Өй түбәсендә —

Карлыгач,

Яр буенда —

Ярлыгач.

Сөн буена күчеп киткән,

Өй түбәсе тар булгач.

Яр буен да ташлап киткән,

Яр буйлары кар булгач.

Булса да үзе

Карлыгач,

Кар яратмый

Карлыгач.

Тилгән

Тилгән
Килгән!
Тилгән
Килгән!

Чеби эзләп,
Чеби күзләп
Килгән
Тилгән
Ерак илдән.

Чебиләрнең
Күп икәнен
Каян белгән
Икән тилгән?

Тилгән
Килгән!
Тилгән

Килгән!

Антилопа

Чаба гына
Антилопа...

Африкада —
Андыйлопа.

Үзен тыя
Алмыйлопа,

Болыннарны
Таптыйлопа.

Чәчәкләрдән
Атлыйлопа.

Нишли инде
Сантыйлопа?

Тик кенә ник

Ятмыйлопа?

Шуны аңлый

Алмыйлопа.

Менә шундый

Антилопа.

Дер-дер куян

Куян ак туннан,

Ә үзе туңган.

Ул ап-ак булган.

Әллә туңганга?

Ә-ә-ә... курыкканга.

Дерелди дер-дер...

Өшегәнгәдер,

Дерелди дер-дер...

Өреккәнгәдер.

Дер-дер киләдер

Шуңа күрәдер —

Дер-дер...

Әй лә,

Белмим лә.

Ник дерелдәвен

Үзе беләдер —

Дер-дер...

Мияу!

Песи, песи, пескәем,

Соры синең төскәең.

Йомшак синең йоннарың,

Җылы синең туннарың.

«Мияу, мияу!» бар сүзең,

Ялкау да әле үзең.

Белмим инде, ни өчен

Бернигә китми исең?

Кызыксындырмый ни ау,

Кызыктырмый ни уйнау.

Мияулау бөтен эшең.

«Мин сине мияу!» — дисең.

Нигә инде күз буяу? —

Үзем дә сине «мияу!».

Безнең як крокодиллары

Булат бүген берүзе

Сөндә су кереп калган,

Таллык төбендә

Ике

Крокодил күреп калган!

Һәм чабарга

Тотынган,

Көчкә качып

Котылган!

Чапкан чакта, җитмәсә,

Ул бер талга абынган.

Икенче тал Булатның

Аягына кагылган.

Крокодил дип, Булатның

Тагын коты алынган.

Куркуыннан, ахрысы,

Тагын бер кат абынган.

Шул хәлдән соң Булатның

Бер генә сүз телендә:

— Ул усал крокодиллар

Әнә... әнә тегендә,

Әнә теге таллыкның

Әнә теге төбендә!

Ә малайлар көләләр,

Чөнки алар Булатның

Ни күргәнен беләләр.

Ләкин Булат сер бирми:

— Сез юкка көләсез, — ди, —

Белмисез бит сез берни!

Барыгыз да карагыз —

Таллыкта ята алар.

Бездәге крокодиллар

Кәлтә дип аталалар,

Белдегезме?!

Сандугач белән малай

— Кунгансың

Куакка,

Кайттыңмы

Кунакка?

— Кайттым

Бөтенләйгә.

Әй лә...

Бөтен җәйгә!

## Урманда

Биредә кошлар, җәнлекләр

Читлеккә ябылмаган.

Урманы да койма белән

Уратып алынмаган.

Ул куяннар, ул пошилар,

Ул керпеләр, тилгәннәр

Казандагы зоопарктан,

Ахры, качып килгәннәр!

Алар безне күргәчтен,

Без урманга кергәчтен,

Тизрәк качып китәләр,

Тизрәк очып китәләр!

Юкса без ул җәнлекләргә,
Кошларга тиябезме?
Алар бит матурлый гына
Әйләнә-тирәбезне!

Без бит яратабыз гына
Аларны — белдегезме?!
«Курыкмагыз!» — дияр идем,
Белсәләр телебезне.

Белмиләр шул!
Алар шулай
Гел качарга торалар.
Зоопаркка ябарлар дип,
Куркып качадыр алар!

Чикерткә

Зур бер чикерткә тоттым —

Бөтенесен куркыттым!

Чикерткә күргәч, кызлар

Авызларын ачтылар,

Чыр-чу килеп качтылар...

Менә инде бу табыш!

Чикерткәсе нигәдер

Миңа бик-бик-бик таныш.

Кайда күрдем әле дип

Уйлыйм эчемнән генә.

Күрдем инде мин аны —

Чыккан исемнән генә...

Ә-ә-ә...

Бу бит теге чикерткә —

Әкияттәге чикерткә!

Эшләми көн күрүче,

Сикергәләп йөрүче,

Болыннар буйлап кына,

Скрипка уйнап кына!

Җәй буена җырлаучы,

Көз җиткәчтен елаучы.

Төшеп калгандыр инде
Әкият китабыннан...

Тик сизми дә калынган:

Сикергән дә учымнан,
Юкка чыккан чикерткәм!
Тагын тотсам, чикерткә,
Сине болай сикертмәм.

Тик чикерткәм югалды:
Яңадан табылмады,
Күземә чалынмады.

Үзенең әкиятенә
Качкандыр әле кереп...

Ачкан идем китапны,
Шаккаттым аны күреп.

Тоттырмадым дигәндәй,
Тора ул миңа карап.
Ну, чикерткә, бер тотсам,
Җибәрмәм сине кабат.

Бахбай

Карап тора миңа бахбай
Абзарның капкасыннан.

Миңа нидер әйткән сыман,
Миңа баш каккан сыман.

Капканы ачыйк, ди, микән,
Бергә качыйк, ди, микән?

Их, чыгар идем, ди, микән,
Чабар идем, ди, микән?

Бераз карап торыйм микән,
Әллә карак булыйм микән?

Атны тизрәк урлыйм микән,
Бераз куркып торыйм микән?

Атны чыгарыйм микән,

Әллә чыгармыйм микән?..

Белмим инде, нишлим икән?

Ә ул бахбай тешли микән?!

## Оча торган чәчәк

Чәчәкләрне бик яратам,

Белмим, әллә нигә мин?!

Чәчәкләрнең матурларын

Җыеп кайттым өйгә мин.

Хуш ис белән тулды бүлмә!

Ләкин шунда, кем күрсен! —

Кагынды да очып китте

Чәчәкләремнең берсе!

Әллә бер гөл, чәчәк түгел,

Күбәләк аткан микән?

Юк ла, болыннан күбәләк

Ияреп кайткан икән!

Кеше кебек

Уйныйбыз Пират белән.

Мавыгып китәмен дә,

Онытамын мин аның

Хәтта эт икәнен дә!

Эт шикелле өрә үзе,

Эт шикелле улый ул.

Елаганда гынаниктер

Кеше кебек елый ул!

Кайтыгыз, кошкайлар!

Кайтыгыз инде, кошкайлар!
Сагындык үзегезне.
Кайтырлар дип, зәңгәр күктән
Алмыйбыз күзебезне.

Каеннар көтә зарыгып,
Зәңгәр яз көтә сезне.
Үзегез дә очрашуны
Көздән үк көтәсезме?

Туган якның бизәге сез,
Туган якның җаны сез.
Туган якка сез бик кирәк,
Онытмагыз аны сез!

Ярый әле киткән чакта
Бөтенләйгә китмисез.
Яз быел да бигрәк гүзәл —
Тик сез генә җитмисез!

Көтү кайта авылга

Авылда кич җитүгә,

Кайтып җитә көтү дә!

Көтүче бер сызгырса,

Чыбыркысын сыздырса,

Сыерлар һәм сарыклар

Чаба тузан туздырып,

Берсен-берсе уздырып!

Көтү кайта, шау-шу кайта,

Шатлык кайта авылга.

Әбиләр дә, бабайлар да,

Апалар да, абыйлар да,

Кызлар белән малайлар да

Чыга каршы алырга!

Сыерларын, сарыкларын

Бар да табып алалар, —

Бар да танып алалар —

Кайсысы колагыннан,

Кайсысы аягыннан,

Кайсысы муеныннан,

Кайсысы койрыгыннан,

Тамгасыннан, төсеннән

Яки башка төшеннән...

Үзенекен тиз таный,

Тиз таба бөтен кеше.

Югыйсә ул сарыклар,

Югыйсә ул сыерлар

Бер төсле бөтенесе...

Авылның иң кызык чагы,

Авыл җырга күмелде.

Бәйрәм булып кайтты көтү,

Авылда кич күңелле!

Ә ничегрәк була икән

Көтү киткән чагында?

У-у-у... ул чакта күңеллерәк

Була диләр тагын да!

Тик көтү киткәнен күргән

Малайлар алар сирәк.

Аның өчен, әни кебек,

Иртүк торырга кирәк!

Сигез песи

Яшиләр, ди, сигез песи,

Сигезе дә симез песи,

Сигезе дә игез песи,

Буйлары да тигез песи,

Сигез песи...

Иң шаяны — Мияубикә,

Ошый аңа уйнау бик тә!

(Гөлшат кебек!)

Иң наяны — Мырауҗан,

Туймый мыр-мыр җырлаудан!

(Илшат кебек!)

Иң ялкавы — Мырмырмыр,

Яратканы — йокыдыр!

(Хәлил кебек!)

Иң ялкавы — Мырау да,

Зур эш аңа мырлау да!

(Хәлим кебек!)

Иң комсызы — Мияумияу,

Бар белгәне: «Миңа-у, миңа-у!»

(Хәниф кебек!)

Тагын берсе — карак Мырый,

Көне-төне каймак урлый!

(Хәмит кебек!)

Иң батыры — Мыраулла,

Эттән куркадыр ла ул да!

(Фәнис кебек!)

Мыргали — иң көчлесе!

Ә үзе — иң кечесе!

(Фәнил кебек!)

Яшиләр, ди, сигез песи...

Сигез песи?..

Көчек өрергә тиеш!

Капка астыннан көчек

Малайларга өрмәкче.

Кирәкләрен бирмәкче,

Батыр булып йөрмәкче!

Өрер иде ничек тә,

Көч юк әле көчектә!

Кыюлык та чамалы —

Куркыта алмый әле

Хәтта бала-чаганы.

Өримме-юкмы диеп,

Ул үзе миңа карый.

Өр, көчек, өр, өрекмә,

Миңа өрсәң дә ярый!

Өрсәң дә тимәм сиңа,

«Усал син!» — димәм сиңа.

Син бит белергә тиеш:

Көчек өрергә тиеш!

## Мырык-мырык

Бар белгәне

«Мырык-мырык»,

Әй чаба ул

Тырык-тырык.

Тыкрыктан ул

Көнгә кырык

Чыгып чаба

Түбән очка —

Үзе дуңгыз,

Үзе чучка!

Сыер

Безнең сыер

Бигрәк сөзгәк —

Ул шаянрак,

Тәртипсезрәк

Малайларны

Йөри күзләп,

Сөзәргә дип

Йөри эзләп...

Аптырарсың —

Үзе сөзә,

Сөт эчертә

Үзе безгә —

Һәммәбезгә!

## Чебиләр

Чи-чи килә чебиләр,

Чи-чи көлә чебиләр.

Чи-чи елый чебиләр,

Чи-чи җырлый чебиләр...

Чи-чи-чи, дип, чебиләр

Туктаусыз сөйләнәләр.

Алар бит «Чи-чи» дигән

Яңа җыр өйрәнәләр.

Каз бәбкәләре

Барыбызга да елмаеп
Карауга яз кояшы,
Каз бәбкәсе белән тулды
Олы бер каз оясы!

Күз җитүгә бәбкә белән
Бер ишегалды тулган —
Бер оя каз бәбкәләре
Бер ишегалды булган!

Ата каз

Ата каз
Мине күрсә,
Янымда

Әгәр йөрсә:

— Тешлим сине,
Ыс-с-с! — ди. —
Тизрәк кереп
Пос-с-с! — ди.

Ә мин әйтәм:
— Посмыйм!
Мин бит синең
Дус-с-с! — дим.

Каз да: — Әйе,
Дус-с-сым! — ди...
Үзе һаман
Ысылдый!

Күркә

Малайларны
Һәм кызларны

Әй йөгертә

Усал күркә —

Урам буйлап

Куып йөртә,

Өйләренә

Куып кертә!

Аннан хәтта

Акбай өркә.

Курыкмасаң,

Син дә үртә!

Күрсәтер ул

Сиңа күркә!

## Бозау белән «КамАЗ»

«КамАЗ»ны күргәч урамда,

Бозау бик аптыраган:

— Бу нинди җанвар тагын? — дип,

Әнисеннән сораган.

Жираф

Жирафка җирдә
Яшәве кыен —
Кая куярга
Белми ул буен.

Гел комачаулый
Шул озын муен.
Жирафка — авыр,
Ә сезгә — уен.

Шуңа кино да
Күрә алмый ул,
Хәтта трамвайга
Керә алмый ул.

Бара алмый ул
Хәтта кунакка,

Кача алмый ул

Хәтта куакка.

Башкалар сөйли,

Ә ул ишетми.

Дуслары аны

Бер дә иш итми...

Жираф булганга

Йөргән оялып,

Нишләргә белми

Йөргән уйланып.

Һәм жираф килгән

Шундый карарга

(Мин үзем бардым

Аны карарга):

Жирафлыгын ул

Инде ташлаган

Һәм кран булып

Эшли башлаган.

«Шираматан»

Әни миңа: «Матур итеп

Йөре атаң төсле, — ди, —
Югыйсә йөрисең, улым,
Шираматан төсле», — ди.

Нәрсә соң ул Шираматан?
Сүзлекләрне актардым,
Сораштырып та карадым,
Тик барыбер тапмадым.

Кошмы, җанвармы соң ул?
Дөньяда бармы соң ул?

Әни аны әбисеннән
Ишетеп калган булган.
Ул, минемчә, булмаган да,
Булса да ялган булган.

Шираматан дип ул кадәр
Ник баш ватамдыр инде?
Шираматан булгачтын ул
Шираматандыр инде.

Тоттым да «Шираматан» дип
Мин этемне атадым.
Шираматан булып йөри
Хәзер Шираматаным.

— Шираматан!

Шираматан!

Маһ-маһ...

Атказанган сандугач

Ул сандугач — дус сандугач!
Көн дә бездә кунакта.
Минем өчен җырлар җырлый
Бакчабызда — куакта.

Сайрагач ул матур итеп,
Бик күңелле миңа да.
«Атказанган сандугач» дип
Исем бирдем мин аңа.

Аның ничек сайраганын
Тыңлатыр идем сезгә.
Сез үзегез дә ышаныр

Идегез минем сүзгә.

Ләкин җырчы сандугачым
Өйдә түгел — ул әле
Җылы якка гастрольләргә
Китеп барды шул әле!

## Рррр белән Мррр

Яши безнең өйдә мәче.
Өй — мәченең биләмәсе.

Маэмай — ишегалдында.
Үз куышы аның да.

Маэмае Рррр исемле,
Ә мәче Мррр исемле.

Тик алар яши һаман

Эт белән мәче сыман.

Очратсалар бер-берсен,

Тотыналар, кем күрсен,

Туктаусыз ырылдарга,

Туктаусыз мырылдарга.

Алар бер эш кырмыйлар:

Көн дә шулай ырлыйлар,

Көн дә шулай мырлыйлар,

Кеше бар дип тормыйлар,

Әллә инде җырлыйлар,

Әллә инде

Берсен-берсе хурлыйлар.

Әрләшәләр, күр, ничек?!

Тыеп булмый берничек.

Тордым да уйлап кына,

Шаяртып, уйнап кына:

«Мин бит рррр, — дигән идем, —

Сезне мррр», — дигән идем,

Тегеләр шыпырт кына

Шунда ук сыпырттылар!

Тиз аңлыйлар үзләре

Үзләренең сүзләрен.

Рррр да мррр дигән булып,

Ай-һай кызык иттердем.

Рәхәт икән белгәчтен

Мәче белән эт телен!

Колын

Бөтерелә бөтерчектәй

Ул әнисе янында.

Әнисенә сыенасы

Киләдер шул аның да.

Әле бигрәк бәләкәй ул —

Чаба-чаба йөрисе

Бик килсә дә, үз янында

Җибәрмидер әнисе...

Кечкенә, тик атландырмый:

Тешли,

Кешни,

Тибешә!

Аңа әле тешләшсә дә,

Тибешсә дә килешә!

Беркөнне мин ул колынга

Атланам дип мактандым.

Һәм сизми дә калды колын...

Сикердем дә атландым!

Атландым да очтым гына...

Яшел чирәм өстенә.

Менә сиңа нәни колын,

Менә сиңа кечкенә!

Ятам мин чирәм өстендә,

Булмый хәтта кузгалып.

Ә колыным: «Гафу ит!» — дип,

Тора мине кызганып.

Нәни поши

Хәзер поши бездә яши —
Нәни генә поши ул.
Шундый әйбәт, шундый йомшак,
Акбайга да ошый ул.

Ул поши баласын әти
Карурманнан тапкан бит.
Әнисен... усал абыйлар —
Браконьерлар аткан бит.

Мин теләмим бу турыда
Пошиемның белүен.
Шуңа әйтми йөрим әле
Әнисенең үлүен.

Еламасын, кайгырмасын,
Кайгырмасын — кирәкми...
Ә теге усал абыйлар

Калмас әле эләкми.

Көтү әйбәт көтелгән

Дөньяда иң кирәк эш
Авылның һәрбер эше.
Шуңа безнең авылда
Көтүче — һәрбер кеше!

Җәй җиттеме, өлкәннәр
Көн дә көтү көтәләр:
Берәм-берәм көтәләр,
Чират белән көтәләр.

Агрономнар, фельдшерлар,
Машина йөртүчеләр,
Бригадирлар, мөдирләр
Һәммәсе көтүчеләр!

Хәтта мин дә көтүче!
Беркемнән ким түгел мин:

Әти белән көнозын

Көтү көттем бүген мин.

Йөз ун сыер тугайда

Туйганчы ашадылар.

Йөз ун сыер туйгачтын

Чабыша башладылар.

Туйганчы чапты алар

Көндезгә чаклы алар!

Йөз ун сыер аннары

Туйганчы сөзештеләр.

Елгага төшеп аннан

Туйганчы су эчтеләр.

Туйгачтын да эчтеләр,

Мин бик оста сызгыргач.

Аннан суда тордылар

Кояш бик нык кыздыргач.

Һәм койрыклары белән

Черки кудылар алар.

Без көткәннән канәгать,

Риза булдылар алар.

Ә кайткач, әни безгә

Җылы сөт савып бирде,

Иң олы чынаякка

Тутырып салып бирде.

Эчкән юк иде бер дә

Мондый сөтне гомердә!

Өлкәннәрнең чиратлап

Нигә көтү көткәнен

Белдем инде — алар да

Беләикән сөт тәмен!

Ә сөте бигрәк тәмле:

Изрәтте бөтен тәнне!

Әллә инде сөтеннән,

Шундук йоклап кителгән...

Көтү әйбәт көтелгән!

Тирәк

Тирәк,

Тирәк,

Син дәү

Бигрәк!

Синең кебек

Олы булу

Минем теләк.

Ничек үсим,

Әйтче, тирәк?

Дәү буласым

Килә тизрәк!

Имән

«Тамырларым

Тирән,

Түбәм

Күккә

Тигән!

Давылларга

Башны

Имәм!» —

Дигән

Имән.

Чыршы

Канатларын

Сыгылдыра,

Ылысларын

Салындыра.

Җырлап тора

Сабыр гына —

Яңа еллар

Сагындыра!

Нарат

Нарат —

Харап! —

Бигрэк

Биек,

Болытларга

Тора тиеп!

Биектәге

Ябалдашын

Торам яшел

Болыт диеп!

Төнбоек

Үз матурлыгын

Тоеп,

Кояш нурында

Оеп,

Яфрагына

Баш куеп

Үсә күлдә

Төнбоек.

Төнбоек ул,

Көнбоек.

Өзмәкчедер

Малайлар —

Төнбоек

Шуңа боек.

**Кечкенәкиятләр**

Шүрәлеләр турында, тылсынчы бабай

турында һәм малайлар турында,

тагын шүрәлеләр турында кечкенәкият

Хөрмәтле аксакалыбыз — сынчы

Бакый бабай Урманчега багышлыйм

Кырлай урманнарында

Яшәгән, ди... булган, ди...

Булган, ди, шул...

Булган, ди...

Ул шүрәлеләр белән

Бөтен урман тулган, ди.

Шүрәлеләрдән урман

Шаулап-гөрләп торган, ди.

Яшәгәннәр, ди, алар

Шаярып-уйнап-көлеп.

Юк шул, бүген түгел шул —

Моннан күп еллар элек.

Йөз елдыр инде минем дә

Шүрәле күргәнем юк.

Шүрәле кытыкламагач,

Туйганчы көлгәнем юк.

Кырлай урманнарында да

Шүрәлеләр беткән, ди.

Ул шүрәлеләр беткәнгә

Күптән инде, күптән, ди.

Шулай... урманны иң соңгы
Шүрәле дә ташлаган.
Малайларга да урманда
Кызык булмый башлаган.

## Шәһәр шүрәлеләре

Киңәшкәннәр малайлар —
Килешкәннәр малайлар.

Шүрәлеләр артыннан
Килгәннәр, ди, шәһәргә.
Шүрәлеләр табылса,
Үзләренә дәшәргә.

Кергәннәр алар музейга,
Күргәзмә залларына,
Килеп чыкканнар мәйданга,
Театр алларына.

Актарып чыккан малайлар
Тукай китапларын да,
Халык әкиятләрен дә...

Ничаклы бар — барын да.

Вәт әкәмәт —
Күр әле:
Казан тулы
Шүрәле!

Тик аларның берсе дә
Урманны өнәмәгән,
Кырлай урманнарына
Кайтырга теләмәгән.

Китап, сәхнә тормышына
Күнеккән инде алар.
Нәкъ шәһәр шүрәлеләре
Кебекләр инде алар.

Үгетләп тә караганнар —
Файда юк, ди, үгеттән.
Беләм инде — шүрләгәннәр
Былтыр дигән егеттән...

Яшәгән, ди, Тылсынчы

Ә Казанда яшәгән

Аксакал бер Тылсымчы.

Тылсымчы гына түгел,

Дөньяда бер Тылсынчы!

Карап кына ала да

Агачка җан кертә, ди.

Бик теләсә, шунда ук

Тимерне терелтә, ди.

Теләсә кайсы ташны

Терелтә дә ташлый, ди.

Нәрсәгә кагылса да,

Җырлый, бии башлый, ди.

Малайлар нәкъ әнә шул

Тылсынчыга килгәннәр.

Казанда яшәгәнен,

Белмим, каян белгәннәр?

— Коткарсагыз сез генә

Коткарырсыз! — дигәннәр. —

Бу афәттән сез генә

Аткарырсыз! — дигәннәр.

— Ярар! — дигән Тылсынчы. —

Уйлап карармын, — дигән. —

Борчылмагыз, малайлар,

Җаен табармын! — дигән.

Өр-яңа шүрәлеләр

Бераз уйланган Тылсынчы,

Ахырдан килешкән, ди.

Җиң сызганып, шүрәлеләр

Эшләргә керешкән, ди.

Шүрәлеләрне көн саен

Куя, ди, коеп кына.

Агачның артык урынын

Ала, ди, уеп кына.

Озын иттерә койрыгын,

Ясый мөгез аннары,

Кәкре-бөкре озын борын...

Тиз ясала калганы.

Бастыра, ди, әзер сынны

Һәм аңа җан өрә, ди.

Нindидер сүзләр әйткәчтен,

Агачка җан керә, ди.

Шуннан соң әверелә, ди,

Агач сын шүрәлегә...

Тылсынчы йөзләп шүрәле

Эшләгәндер... әлегә.

Тик шүрәлеләр нигәдер

Калмаганнар янында.

Чөнки аларны урманнар

Көткән Кырлай ягында.

Берсе койрыксыз килеш

Урманга качкан, имеш.

Ә берсенең мөгезен

Өлгермәгән ясарга.

Тик барыбер җай гына

Көткән алар качарга...

Тылсынчы ясап торган,

Тегеләр качып торган.

Качсыннар дип, Тылсынчы

Ишеген ачып торган...

Былтырга да әйтегез!

Сез дә барыгыз әле

Кырлай урманнарына.

Урманнарның шүрәле

Яши торганнарына.

Тик курка күрмәсеннәр —

Сез анда кычкырмагыз!

Бармакларын агачка,

Зинһар, дим, кыстырмагыз!

Былтырга да әйтегез —

Йөрмәсен ул урманда.

Шүрәлеләр шүрләрләр

Ул урманда булганда.

Югыйсә алар урманнан

Тагын качып китәрләр.

Кырлайдагы урманнарын

Тагын ятим итәрләр.

Әкиятнең ахыры

Хәер, хәзер Тылсынчыны

Сез дә беләсез инде.

Шүрәлеләр кирәк булса...

Нигә көләсез инде?

Беләм инде

Мин сезне —

Ялганлый бу,

Дисезме?

Яшермим, моңа чаклы

Язганмындыр төрлесен.

Ә бу юлы, чынлап әйтәм,

Яздым мин чын дөресен!

Ялганлап торырга

Бала-чага түгел лә мин.

Үз күзләрем белән күрдем

Мин ул шүрәлеләрне.

Ышанмасагыз,

Үзегез барыгыз да карагыз!

**Җәяү йөрүче машина**

**турында кечкенәкият**

Булган, ди, бер машина

Булган, ди, бер машина —

Җитез, өлгер машина,

Бик тә елгыр машина.

Зур түгел һич кенә дә,

Түгел, ди, кечкенә дә —

Гадәти бер машина,

Гади тимер машина.

Яраткан ул йөрергә,

Ерак юллар кичәргә.

Машина булса да ул

Яраткан, ди, эчәргә.

Юк, аракы эчмәгән —

Килмәгән башына да.

Курыкмый кем утырсын

Исерек машинага?

Лимонад та,

Компот та

Эчмәгән ул

Бер кат та.

Кесәл эчәр иде дә,

Кесәлдән көче беткән.

Сөт тә эчәр иде дә,

Сөттән дә төсе киткән.

Чәй дә эчәр иде дә,

Чәйдән ни... эче киткән.

Сок эчсәң дә чәчәгән...

Шуңа күрә машина

Бензин эчеп яшәгән.

Әй йөри, ди, машина

Бензинны ул яраткан:

Китмәгән, ди, төсе дә,

Бетмәгән, ди, көче дә,

Авыртмаган эче дә,

Теше дә —

Бер төше дә!

Хәтта җырлаган икән,

Җырлаганын, сокланып,

Үзе тыңлаган икән:

«Бензины да бензины!

Бигрәкләр тәмле икән.

Әллә бензин эчкәнгә

Дөньялар ямьле микән?»

Бензинын эчеп куйгач,

Бик тәмләп эчеп туйгач,

Әй йөри, ди, машина

Шәһәр урамнарыннан,

Шәһәр бульварларыннан,

Урам араларыннан.

Йөри, ди, әй типтереп,

Бөтен шартын китереп,

Төтен исе сиптереп.

Зәп-зәңгәр булган урам
Ул выжылдап узганда.
Тик сүз әйтүче юк, ди,
Саф һаваны бозганга.

Шәһәрнең кешеләре
Инде өйрәнгән икән,
Аларның борыннары
Шуңа көйләнгән икән.

Китеп барган урманга

Шуннан бер ял көнне ул,
Уйлап-уйлап торган да,
Бензин эчеп алган да,
Буш вакыты булганда
Китеп барган урманга.
Әй ашыга-ашыга,
Әй бара, ди, машина —
Төтен исен таратып,
Урман эчен каралтып.
Шушы төтен исендә,
Шушы төтен эчендә

Күбәләкләр,

Үләннәр

Авырганнар,

Үлгәннәр.

Кошлар да

Очмас булган,

Күзләрен

Ачмас булган.

Бөҗәкләр дә

Исергән

Шул машина

Исеннән...

Тик машина

Кинәттән

Тиз тизлеген

Киметкән.

Авыр сулап

Алган ул,

Тукталып ук

Калган ул.

Кашып куйган

Башын да —

Гүзәл бер чәчәксылу

Тора икән каршында.

Гашыйк булган машина

Гашыйк булган машина,

Ул чәчәкне күргәч тә —

Елмаеп бер көлгәч тә!

Ә чәчәккә сулавы

Авыр була башлаган —

Машина төтененнән

Кинәт сула башлаган.

Чәчәк көлмәс булган, ди,

Чәчәк йөрмәс булган, ди,

Күзе күрмәс булган, ди...

Эшнең нидә икәнен

Машина да аңлаган.

Үзе чәчәксылудан

Күзләрен дә алмаган.

Ул чәчәксылуны бик тә,

Бик тә, бик тә кызганган.

Чәчәк үлмәсен диеп,

Үлә күрмәсен диеп,

Урыныннан кузгалган.

Бик тә оялган икән ул,

Бу хәлләрне күргән дә.

Һәм җәяүләп китеп барган,

Моторын сүндергән дә...

Әкиятнең ахыры

Ул машина, әле булса

(чын микән, юри микән?),

Чәчәк искә төшкән саен,

Җәяүләп йөри икән.

Нигә? Андый машинаны

бер дә күргәнегез юкмыни

сезнең? Бар ул, бар

андый машина.

Игътибар беләнрәк карагыз әле,

бәлки, сез дә күрерсез.

Күрсәгез, миңа да әйтерсез, яме?!

**Батыр куянның ничек итеп куркак куянга**

**әйләнүе турында кечкенәкият**

Яшәгән, ди, бер куян

Яшәгән, ди,
Бер куян —
Эре куян,
Көр куян!

Туса да ул
Урманда,
Торса да ул
Гел анда,

Ахры, туган
Көненнән
Куагының
Төбеннән

Ерак китмәгән булган.
Ерак китәр иде дә,
Йөрәк җитмәгән булган...

Ә инде үсеп җиткәч,
Йөрәкләнеп тә киткәч,
Гайрәтләнеп тә җиткәч,

Уйлаган ул беркөнне,

Тыңламыйча беркемне,

Азрак уйнап килергә,

Зур урманда йөрергә,

Бераз дөнья күрергә...

Әнкәсе күргәнче дип,

Әткәсе белгәнче дип,

Чапкан урман эченә,

Чапкан бөтен көченә.

Рәхәтләнгән

Иркендә.

Тыймаган, ди,

Беркем дә.

Урман шундый

Олы, ди.

Киек-кошлар

Тулы, ди.

Шаклар катып

Йөргән ул,

Әлләниләр

Күргән ул...

Кайтып килә, ди, куян...

Кайтып килә, ди, куян

Әллә каян —

Ерактан.

Шул чагында

Каршында

Зур бер җанвар

Очраткан!

Нишләргә

Бу очракта?

Тукталып калган куян —

Арыган-талган куян.

Бик дәү икән җанвары —

Җилферди, ди, яллары.

Караңгыланып киткән

Куянның күз аллары.

Ә җанвар
Юлга баскан.
Бер япкан да
Бер ачкан
Галәмәт зур
Авызын —
Тешләре, ди,
Әй озын!

Моның, ахры, исәбе
Куянны куркытырга,
Йә аны котыртырга,
Яки тотып йотырга!

Куянның кәефе киткән,
Тегеләй-болай иткән.

Акылга утыртырга
Моны кичек иттереп?
Һәм тормаган көттереп...

Ят җанварга куянның
Ачуы нык чыккан, ди —
Яңагына нык кына
Китереп тә суккан, ди.

Теге аңга килгәнче

Салган да

Еккан да, ди.

Ә аннары бөтенләй

Капкан да

Йоткан да, ди.

Бик ачыккан куянга

Бу бик тә ярап куйган.

Эчен сыпырган куян,

Иренен ялап куйган,

Тагын бер

Ялмап куйган.

Күренеп тора инде —

Куянның тамак туйган!

Каян белсен, ди, куян...

Моны күргән

Җәнлекләр

(Әй өркәкләр-

гарьлекләр!)

Нишләргә

Белмәгәннәр,

Нишләптер

Көлмәгәннәр,

Кыскасы,

Куркышканнар —

Койрыкларын

Кысканнар,

Өннәренә

Посканнар,

Өйләренә

Качканнар...

Аннары көчкә-көчкә

Тынычлангачтын кичкә,

Куян янына алар

Җыелышып килгәннәр:

— И куян, йоттың бит син

Арысланны! — дигәннәр.

Белгәч кемне йотканын,

Куян киткән дерт итеп.

Караган ул аларга

Ике күзен дүрт итеп.

Нишләргә дә белмичә,

Чак-чак калган үлмичә.

Ул бик нык аптыраган,

Белмәдем, дип акланган.

Бик нык үкенгән куян,

Гафу үтенгән куян.

— Әгәр белсәм, мин аңа

Ташланмас идем, — дигән —

Әгәр белсәм, мин аны

Ашамас идем, — дигән.

Аның чын арысланны

Күргәне булмаган шул,

Арыслан тирәсендә

Йөргәне булмаган шул.

Аның көчле икәнен,

Казык тешле икәнен

Белсен, ди, куян

Каян?

Ай-яй, куян!

Ай наян!

Куркак куян

Шуннан бирле урманда
Куян күренми икән,
Урманда барлыгы да
Хәтта беленми икән.

Утыра, ди, арыслан
Ул куянның эчендә.
Кайчак батырлана, ди,
Менә шуның өчен дә.

Бик батыр булыр иде дә,
Куркаклыгы җиңә, ди.
Куркаклыгы аркасында
Куян җәфа чигә, ди.

Шушы хәлдән соң куян
Калган, ди, куркак булып.
Калган, ди, куркуыннан
Агарып, ап-ак булып...

«Куркак куян» дигән булып
Бөтен дөнья көлешә.
Ә шулай да,
Минемчә,

Арыслан йоткан куянга

Куркаклык та килешә!

Әкиятнең ахыры

Ә сез, дуслар, җанварларга

Бәйләнмәгез, тимәгез.

Арыслан булуы мөмкин —

Берүк якын килмәгез!

Сез — кыюдыр.

Бәйләнүен

Анысы бәйләнерсез...

Тик арыслан

Тотарсыз да,

Куян кебек

Йотарсыз да

Куркакка әйләнерсез!

Ә мин сезнең бары тик

Батыр гына булуыгызны телим!

Чынлап әйтәм.

Соң нишләп инде көлим,

Бер дә көлмим.

Куян йөрәкле бүре

турында кечкенәкият

1

Ә бит бүре куянны

Һаман тота алмый, ди,

Инде тоттым дигәндә,

Куян тагын алдый, ди.

Елмаймый,

Көлми бүре,

Нишләргә

Белми бүре!

Беркөнне ул куянның

Кайдалыгын

Белешә

Һәм хәйләгә

Керешә.

Уйлый-

Уйлый-

Уйлый да

Хат җибәрә

Кылыйга.

2

«Куянкаем,

Исәнме!

Бәләкәчләр

Үсәме?

Сиңа мәгълүм

Бүре мин,

Бүренең шәп

Төре мин.

Мин бик юаш.

Йөрим мин

Койрыкны

Кысып кына,

Качып та

Посып кына.

Килсәң әгәр кунакка,

Йөртермен

Кочып кына!

Бүреләрчә

Сүз бирәм:

Мин моннан соң

Үзгәрәм,

Бүгеннән үк

Төзәләм.

Телисеңме,

Тезләнәм.

Куянкаем,

Дускаем,

Кунакка кил

Үземә —

Матур булып,

Тәмле булып

Күренәсең,

Күземә!»

3

Бүре хатын укыгач,

Кеткелдәп көлә куян.

Бүренең бу хәйләсен

Шунда ук белә куян.

Уйлый-

Уйлый-

Уйлый да

Җавап яза

Кылый да.

4

«Исәнме,

Иптәш бүре!

Симез һәм итләч бүре!

Куян гына булсам да,

Бик гайрәтле куян мин!

Бүренең кайдалыгын

Мең чакрымнан тоям мин!

Күп ашарга яратмыйм —

Бер бүредән туям мин,

Бүрене бер утырып

Ялт иттереп куям мин!

Аннан ятып йоклыймын, —

Бер атнасыз уянмыйм...

Менә шундый

Куян мин!

Мине куян дигәч тә,

Әллә куркак дисеңме?

Оят куян булуы —

Алыштырам исемне.

Исемемне арыслан,

Юлбарыс дип куштырам.

Бүрене үз янымнан

Мең чакрымга постырам.

Бүре энем,

Кил үзең —

Минем сиңа

Шул сүзем!

Абзаңның кем икәнен

Шунда белерсең әле,

Менә күрерсең әле!

Ух, мин сине!..»

5

Бүре шушы

Хаттан соң

Ник бер генә

Мактансын.

Кылый хәзер бүренең

Төшләренә керә, ди,

Куянны ул төшендә

Ерткыч итеп күрә, ди...

Их бүре, бүре, бүре,

Бүренең

Куркак төре,

Куян йөрәкле

Бүре!

Бик масаеп

Йөрмә син,

Куян күрә

Күрмәсен,

Эләктерә

Күрмәсен!

Һайт!..

6

Бу хәл, бәлки,

Булгандыр,

Бу хәл, бәлки,

Ялгандыр —

Мин аны

Каян белим?

Мин бары берәүнең дә

Усал булмавын

Телим!

Бозау белән көчекнең дуслашуы

турында кечкенәкият

Ел ярым элек моннан

Бик яшь бер бозау

Булган.

Тик дуслары

Булмаган,

Булганыннан —

Уңмаган.

Ләкин бозау

Түзмәгән —

Үзенә дус

Эзләгән.

Беркөнне ул урамда

Көчек янына килгән,

Килгән дә ул:

— Му-у-у! — дигән.

Көчек бик

Аптыраган,

Әнисеннән

Сораган:

— Нинди телсез бу? — дигән. —

Нигә мулый бу? — дигән. —

Әнием, бу бозауны

Моннан тизрәк ку! — дигән.

Әнисе болай дигән:

— Әйбәт бозау бу! — дигән,

Ул бит сиңа: «Му-у-у! — дигән. —

Дус булабызмы-у-у?» — дигән.

Соңыннанмы?

Соңыннан

Көчек бик нык

Оялган,

Көчек бик нык

Уйланган!

Бозауны

Эзләп чапкан,

Бозауны

Эзләп тапкан,

Анын

Янына килгән,

Бар көченә:

— Һау-у-у!— дигән.

Тик бозау аңламаган

Көчекнең ни дигәнен.

Әйткән ул әнисенә:

— Мин бит аңа тимәдем!

Шулай булгач,

Ул көчек

Нигә миңа

«Һау-у-у!» ди ул,

Миннән нәрсә

Даулый ул?

Ул миңа

Һауламасын!

Юк-барга

Шауламасын!

Ә әнисе аңлаткан:

— Көчек бит сиңа: «Һау-у-у!» — ди.

Дус булырга риза-а-у-у-у!»— ди.

Бозау бик нык

Оялган,

Бозау бик нык

Уйланган!

Бозау белән ул көчек

Ахырда

Аңлашканнар,

Хәтта

Кочаклашканнар,

Кыскасы —

Дуслашканнар!

Ишегалды гөр килгән:

— Һау да һау да,

Му да му!..

Бумы?

Бу —

Һәм бозау турындагы,

Һәм көчек турындагы

Чын әкият була

Бу!

Кечкенә көчек

турында кечкенәкият

Үсәр өчен

Сөт эчеп,

Яшәгән, ди,

Бер көчек!

Ул тәртипсез

Булмаган,

Ул әнисен

Тыңлаган.

Вакытында

Йоклаган,

Йоклаган —

Көч туплаган!

Юып йөргән

Ул көн дә

Битләрен,

Колакларын,

Колагының

Артларын...

Ни генә

Эшләмәгән,

Ә барыбер

Үсмәгән.

Башка

Көчекләр исә

Зур булган

Үсә-үсә!

Тик менә

Көчек кенә,

Үсим дип

Ничек кенә,

Эчә икән

Көн дә сөт,

Көчекләрдән

Көнләшеп!

Күпме генә

Эчмәгән,

Юк, барыбер

Үсмәгән...

Чөнки көчек

Үзе шундый

Үсми торган

Эт булган!

## Туп тибәргә яратучы малай турында кечкенәкият

Бер малай

Туп уйнаган,

Туп белән

Күп уйнаган!

Әй уйнаган,

Туймаган!

Үскәчтен

Чын футболчы

Булам, диеп

Уйлаган.

Ул көн буе уйнаган:

Әнисенең сүзләрен

Колагына

Элмәгән,

Өйгә кайтып

Кермәгән.

Дәрес

Әзерләнмәгән,

Өйгә эш

Эшләнмәгән,

Мисаллар

Чишелмәгән...

Ә дәрестә ул малай

Берни дә төшенмәгән...

Ошамаган бу

Тупка:

— Яхшы түгел бу,

Тукта!

Бу хәлләргә

Түзем юк,

Типсен иде,

Сүзем юк,

Үпкәләмәс тә идем,

Яхшы малай типкәнгә,

Ачу килә, «икеле»

Алып мыскыл иткәнгә.

Син, малай,

Ялкау бигрәк,

Син, әйдә,

Төзәл тизрәк! —

Дигән ул туп малайга.

Ә малай

Тыңламаган,

Әйткәнне

Аңламаган,

Ул һаман да

Туп типкән.

Тик беркөнне туп аның

Үзен дә кызык иткән:

Теге малай тибүгә,

Бөтенләй очып киткән...

Икенче туп алганнар —

Ансы да очып киткән,

Өченче туп алганнар —

Ансы да очып киткән.

Барсы да

Очып киткән!

Барсы да

Очып беткән!

Малай

Килеп тибүгә,

Хәтта

Якын килүгә,

Туплар,

Сүз берләшкәндәй,

Оча да

Китә икән,

Ә малай

Көтә икән.

Белмим, хәзер ул малай

Бераз

Үзгәрде микән?

Бераз

Төзәлде микән?

Ләкин ул шул хәлдән соң

Туп тибүдән туктаган.

Хәзер инде күрсә дә

Курка, ди, ул туплардан!

Койрыксыз куян турында кечкенәкият

Элегрәк шәһәргә дә

Көн саен килгән куян.

Килгәч «Яшелчә» дигән

Кибеткә кергән куян.

Кергәчтен дә чиратка

Баскан, ди, ул кишергә.

Икешәр пот алган, ди,

Калдырмыйча кешегә.

Өстәвенә, берәр пот

Кәбестә ала икән.

Әле ике шалканлык

Акчасы кала икән.

Куян шулай көн саен

Ишәк кебек төянгән,

Шул төянгән килеш ул

Урманына юнәлгән.

Ә урамда трамвайлар,

Машиналар — меңләгән!

Ләкин куян урамда

Бер дә йөри белмәгән.

Каян белсен — куянны

Берәү дә өйрәтмәгән.

Аннары, ул кагыйдә

Куянга кирәкмәгән.

Куян шулай уйлаган —

Өйрәнеп вакланмаган.

Моңа чаклы бит әле

Машина таптамаган...

Тик беркөн

Кинәт чаттан

Зур трамвай

Килеп чыккан!

Куян трамвай юлыннан

Тиз генә чыга алган.

Ләкин менә койрыгы —

Озын мамык койрыгы —

Аз гына соңга калган! —

Трамвай астында калган,

Бөтенләй шунда калган!

Куян шундый каушаган,

Куян шундый курыккан,

Куркуыннан койрыгын,

Кәбестәсен, кишерен

Алырга да оныткан.

Койрыгы да

Булмагач,

Комачаулап

Тормагач,

Әй шундый тиз чаба, ди,

Урманына таба, ди.

Койрыгы

Өзелгәнгә
Ул хәтта
Сөенгән дә!

Озын койрык заманы
Узды инде,
Ә аны
Йөртсен лә
Төлке генә —
Хәзер ул
Көлке генә!

Вәт хәзер була инде
Бакчага керергә дә!
Болай булгач, хәзер мин
Тоттырмыйм бүрегә дә!

Җайлы хәзер
Чапканда,
Бүреләрдән
Качканда!

Ә инде ул шәһәрдә
Куянсыз да кеше күп.
Аннан куян абзаңның
Урманда да эше күп!

Шуннан бирле шәһәргә

Йөрүен ул ташлаган.

Шуннан

Куян

Койрыксыз

Яңа тормыш башлаган!

Шуннан соңмы?

Шуннан соң...

Ансын инде менә сез

Үзегез дә беләсез!

Кояш буласы килгән кызыл шар

турында кечкенәкият

Яшәгән, ди,

Кызыл шар,

Яшәгән, ди,

Кызык шар...

Шарны элеп

Куйгач та

Өскәрәк, биеккәрәк,

Охшаган, ди, кояшка!

«Син нәкъ кояш шикелле!» —

Дигәннәр, ди, ул шарга.

Шар үзе дә тырышкан

Шул кояшка охшарга.

Аңа ул сүз

Ошаган,

Ул сүзгә ул

Ышанган.

Минем кебекләр

Сирәк!

Миңа һич кичекмәстән

Кояш булырга кирәк!

Килер ул эш

Көчемнән,

Дип уйлаган

Эченнән.

Әйткән әнисенә дә:

— Мин кояш булам! — дигән. —

Биеккә кунам! — дигән.

Ләкин әйткән әнисе:

— Син кояш булма! — дигән. —

Биеккә кунма! — дигән, —

Кайбер юньсез малайлар

Сине күргәч шаккатыр

Һәм шунда ук

Шартлатыр!

Йә булмаса сине җил

Очыртып китәр! — дигән. —

Аннары бөтен җирне

Кояшсыз итәр! — дигән. —

Без кояшсыз

Калырбыз,

Аннан каян

Алырбыз?!

...Уйга калган

Шар шунда

Һәм аңлаган

Барсын да!

Ул әнисен

Тыңлаган —

Кояш булып

Тормаган.

Ул бик дөрес

Эшләгән,

Әйбәт бер эш

Эшләгән!..

Сез дә, дусларым, берүк,

Әйтсәләр дә,

Күнмәгез —

Кояш була

Күрмәгез!

Хәтерсез балыклар

турында кечкенәкият

Су асты

Дөньясында,

Балыклар

Оясында

Беркөн барлык

Балыклар

Шауларга

Керешкәннәр,

Кычкырып

Сөйләшкәннәр,

Кычкырып

Киңәшкәннәр,

Кычкырып

Тиргәшкәннәр,

Кычкырып

Көлешкәннәр!

Су җанварлары

Башта,

Бәла килде, дип,

Башка,

Куркуга ук

Төшкәннәр.

Су астын

Шау-шу баскан.

Җанварларның

Күбесе

Су астын

Ташлап качкан.

Ә калганнар бу хәлне

Куркышып тыңлаган, ди.

Су астында моңарчы

Мондый хәл булмаган, ди.

Шулчак диңгез

Түреннән

Дельфин бабай

Күренгән!

Һәм ул әдәпле генә

Үтенгән, ди, алардан,

Ягъни шул

Балыклардан,

Сөйләшеп

Йөрмәүләрен,

Тиргәшеп

Йөрмәүләрен,

Кычкырып

Көлмәүләрен,

Су астында халыкның

Йокысын бүлмәүләрен!

Балыкларның барсы да

Дельфинны тыңлаганнар,

Барсы да тынган алар —

Сөйләшә белмәүләрен

Оныткан булган алар!

## Бүренең кешеләр белән дуслашуы турында кечкенәкият

1

Кешеләр белән бүре

Яши гел

Дошманлашып,

Талашып,

Тарткалашып!

Бүре бер дә төшенми

Дошманлыкның сәбәбен.

Нигә алмый кешеләр

Бүреләрнең сәламен?

Нигә яратмый икән

Кешеләр бүреләрне?

Әллә инде бүреләр

Бик ямьсез күренәме?

Баласын: «Бүре килә!» —

Дип куркыта әнисе.

«Бүрегә илтеп бирәм!» —

Дип куркыта әбисе.

Көлә-көлә бүредән

«Ну, погоди!» карыйлар.

Ә этләр бүреләргә

Урамда теш кайрыйлар.

Малайлар шигырь укый

Усал бүре турында.

Корулы мылтык тора

Әтиләре кулында...

2

Авыл янына бүре

Килеп тә карый икән,

Тик бүрене кешеләр

Шунда ук таный икән.

Кешеләр, тану белән,

Куып җибәрә икән,

Сугып җибәрә икән,

Таш белән ата икән,

Мылтык шартлата икән.

3

Уйлый торгач, ахырда

Бүре бер җаен тапкан:

Зоопаркка килгән дә

Читлеккә кереп яткан!

Утыра, ди, ул хәзер

Кешеләргә күз атып,

Малайларны күзәтеп.

Үзе бик аптырый, ди,

Бу чаклы күп кешегә

Гаҗәпләнеп карый, ди.

Зоопаркка килә, ди,

Бар да бүре күрергә.

Балалар да, зурлар да

Елмая, ди, бүрегә.

«Бу — әйбәт бүре!» — диеп

Мактый башлыйлар икән,

Сыйлансын әле, диеп,

Кәнфит ташлыйлар икән.

Бүре белән кешеләр

Нинди дуслар, күрегез!

Кешеләр әйбәт икән,

Дип уйлый, ди, бүребез.

Чөнки ул бу хөрмәтне

Күрмәгән төшендә дә.

...Бүре тик шул чагында,

Читлектә булса гына

Ошый шул кешегә дә!

Зур кабак турында кечкенәкият

Ташлаган да бар эшен,

Бик тә зур булыр өчен,

Зур булып торыр өчен

Бакчада үскән кабак.

Зур үсәсе килгәнгә,

Зур үсәсен белгәнгә,

Көн дә су эчкән кабак.

Әмма шулай булса да,

Гел су эчеп торса да,

Кайгыга төшкән кабак!

Кабакның эше харап —

Койма аша бер карак

Кабакны йөргән карап,

Чыкмакчы булган талап!

Кара син әй каракны —

Урламакчы кабакны!

Тик ошаса да кабак,

Кире уйлаган карак.

Ул каракның башына

Фикер килгән... яңарак:

«Үссен кабак — зур булсын,

Урлармын мин зурысын.

Килермен әле кабат», —

Диеп уйлаган карак.

Ә кабак җәй буена

Кабарынган, кабарган.

Көн саен, торган саен

Кабара гына барган.

Ул кукрайган, зурайган.

Күренгән әллә кайдан.

Әйтерсең лә ул зуррак

Зур кояштан, зур айдан.

Менә ичмасам кабак!

Бакчы, бак, кабакка бак!

Төрлечә, төрле яктан

Карак кабакка баккан.

Өскә таба караган,

Як-ягына каранган,

Башта йөзе агарган,

Аннан үзе каралган,

Колач җитмәле түгел,

Урлап китмәле түгел.

Карагыбыз алданган,
Ялгышканын аңлаган —
Кабат-кабат ябышса да,
Кузгата да алмаган.

Карак шундый үкергән,
Үрле-кырлы сикергән,
Җикеренгән, җикергән...
Башта урламаганга
Карак бик нык үкенгән.

Ләкин инде соң булган.
(Бу хәл чынлап чын булган!)

Урлый алмаган карак.
Бакчада калган кабак.
Нәфесен тыймаганга,
Нәфесе туймаганга
Алган карак шәп сабак!

Кызык иткән бит кабак,
Әй карак —
Туймас тамак!

Балыкчы булырга хыялланучы суалчан

турында кечкенәкият

Булган, ди, бер суалчан,

Булган, ди, ул оялчан.

Суалчанның

Балыкчы

Буласы бик килгән, ди.

Ул нишләргә белгән, ди —

Чөнки балыкчы абыйлар

Аларга еш килгән, ди...

Беркөнне

Таңынан диярлек

Балыкчыларга ияреп

Киткән, ди, ул балыкка...

Җиткәннәр, ди, барып та

Иң балыклы бер төшкә.

Һәм тотынганнар эшкә.

Утырганнар, утырганнар —

Чиләкләрен тутырганнар...

Өстерәлеп көчкә генә

Кайтканнар, ди, кичкә генә.

Суалчан гына менә

Кайтмаган, ди, өенә...

Кояш, жираф һәм төлке

турында кечкенәкият

Кояш беркөн төлкегә

Калач булып күренгән.

Кызыгып тора торгач,

Ул кояшка үрелгән.

Ничек кенә

Итмәгән —

Ләкин буе

Җитмәгән!

Тик югалып калмаган:

Ул жирафны котырткан.

Дөресрәге, ул аны

Төп башына утырткан!

Уйлый торгач, кояшны

Жираф кабарга булган.

Ни булса да булыр дип,

Кабып карарга булган.

Юк, юк, ашарга түгел —

Белергә

Тәмен генә,

Тидереп

Телен генә!

Тидерүен тидергән,

Ләкин телен пешергән.

Телен пешергәч кенә

Алдануын төшенгән.

**Ирекле тәрҗемәләр**

Агагельды Алланазаров

төрекмәнчәдән

## Дустымны эзлим

Дустым югалды бит әле!

Шундый әйбәт дус иде.

Иртән торып чыгуыма

Оясы буп-буш иде.

Кимергән сөяге калган,

Буш табагы яланган...

Эзләп карадым урманнан,

Урап кайттым яланнан.

Минем шул яхшы дустымны

Күрүче булмадымы?

Сезнең тирәдә һау-һаулап

Өрүче булмадымы?

Әгәр карлыкмаган булса,

Тавышы матур иде,

Үзе дүрт аяклы иде,

Үзе бик батыр иде!

Ятканда телен чыгара,

Ялтырап тора күзе.

Койрыгы пумала кебек,

Акбай исемле үзе.

Әгәр күрсәгез, сез аңа

Сөяк биреп китегез.

Әгәр сөяген яратса,

Миңа хәбәр итегез!

Кыш кайчан була?

Кышның кайчан җиткәнен

Белергә телисезме?

Кышны яздан, җәйдән, көздән

Аера белмисезме?

Җәйге сукмаклар күмелсә,

Кар яуса матур итеп,

Малайлар да, бабайлар да

Кисәләр киез итек,

Торбалардан төтен чыкса,

Тышта буран котырса,

Минем әби җылы мичнең

Янынарак утырса,

Абый арба урынына

Чанасын җиккән булыр —

Шунда кыш җиткән булыр.

## Көтү каршылаганда

Көтү кайтканда көн саен

Каршылыйм мин малларны.

Бармакларны бөгә-бөгә

Санап торам аларны.

Берәү, икәү, өчәү, дүртәү...

Бик җиңел унга кадәр.

Тик менә буталып бетәм,

Уннан да артса әгәр...

Тагын буталдым.

Малкайлар,

Бераз көтегез инде.

Әбиемнән сорап килим —

Сабыр итегез инде!

Елена Аксельрод

русчадан

Төн кая була?

Кояш чыккач, таң аткач,

Төн кая китә икән?

Әллә инде коега

Качып ял итә микән?

Карадым мин коега —

Бик куркыныч тоела.

Төн менә кайда икән —

Ул бит коеда икән!

Тик төнне чиләк белән

Алып чыга алмадым.

Төн коеда юк икән —

Әле генә аңладым.

Аннан өйгә кердем дә

Карадым базны ачып.

Менә кайда икән ул! —

Төн ята базда качып.

Төшеп киттем мин базга —

Куркып торыйм ди кемнән?

Һәм җырларга тотындым

Курыкмас өчен төннән.

Ә шулай да урамга

Чыгып киттем мин ятьрәк,

Чөнки анда яктырак,

Күңеллерәк, әйбәтрәк!

Агния Барто

русчадан

Өлкәннәргә ышансаң...

Мин өлкәннәр дөрес сөйли
Дип уйлый идем элек.
Бабай: «Хезмәт яратам», — ди...
Тик булмый әле белеп.

Мин аннан: «Сыбызгы ясап
Бир әле!» — дип үтендем.
Үтендем дә — үтенгәнгә
Үзем бераз үкендем.

«Кибеттән алыйк, — ди бабай, —
Бераз гына көт әле...»
Ә үзе: «Хезмәт яратам», —
Дигән була бит әле.

Фәрештә кирәк әнигә

— Син хиссез үсәсең! — диләр.

Белмим, хис нинди сүздер?

Мин хиссезме? Бәхәсләшмим.

Хиссез булгач хиссездер.

Урамнан кичә каршыга

Әни килә туп-туры.

Менә анда инде ул хис,

Аның хисе — туп-тулы!

Кочаклап алды ул мине

Бөтен кызлар каршында.

Ә мин шуңа кердем суга,

Коендырдым барсын да.

Кочаклашмыйлар бит инде,

Мин хисле дип, һәр төштә.

Хиссез, имеш. Кирәк аңа

Малай түгел, фәрештә.

Чыгып кына тора җай!

Бәхетем йолдызы миңа

Гел ярдәм итеп тора:

Әйбәт бер кыз белән көн дә

Очрашу көтеп тора.

Наташа ул. Кунакка дип

Барса апаларына,

Очраклы гына барам да

Басам капкаларына.

Очрашабыз тукталышта,

Кибеттә... ялгыш кына.

Очраклы очраштырадыр

Безне шул язмыш кына.

Тик ул җайны, ул очракны

Мин көннәр буе көтәм:

Урамнарыннан да үтәм,

Көтәм дип, туңып бетәм...

Урамда уза көннәрем

Шул кызны көтеп кенә.

Тик ни... сөйләнә күрмәгез,

Әйтәм сер итеп кенә.

Эх, әгәр дә!..

Эш җитәрлек авылда

Кызларга, малайларга.

Яңгырый тавышлары

Әллә... әллә кайларга.

Тирә-якта кайный эш,

Кайный эшнең төрлесе.

Сашка да эшләр иде,

Тик җибәрми сеңлесе.

Балта, чүкеч тавышы...

Ачуы чыга анын.

Вакыт алыштырырга

Биләүләрен Танькаңың.

Иртәдән кичкә кадәр,

Җепкә бәйләнгән сыман,

Сеңлесе белән көн дә

Утыра — ай-яй чыдам!

«Эх, китсәң иде

БАМга!

Сеңелсез, әниләрсез

Бик тә рәхәттер анда...»

Ялгызлык

Юк, китәм бөтенләйгә!

Кайтмаячакмын мәңге:

Юкса күп сорау бирәм

Һәм ашамыйм бәрәңге.

Зурларга тупас дәшәм

Һәм юкка бәхәсләшәм.

Әйбәт булыр урманда

Ялгыз башым яшәсәм.

Мин ялгызлык яратам —

Чыкмас монда талаш та.

Өемне дә сагынмам —

Рәхәт икән шалашта.

Берәр чытырманлыкта

Берәр күл дә табармын.

Бака белән бакача

Бәхәсләшеп карармын.

Кошлар җырын тыңлармын,

Төрле уйлар уйлармын.

Тик мин футбол яратам —

Кемнәр белән уйнармын?

Иң яхшысы: һәркемгә

Шалаш ясыйм мин көн дә.

Чакырам малайларны,

Чакырам да аларны

Берәр шалаш өләшәм.

Әтиләрне дә дәшәм.

Ләкин шуны белегез —

Бөтенләйгә килегез!

## Кызарам

Әллә нишләдем әле,

Шуңа янам, сызланам:

Чөнки мин бик еш кына

Бер сәбәпсез кызарам.

Пәке сорый күрше кыз,

Ә мин торам кызарып.

Юкса берни әйтмәде

Алай кәеф бозарлык.

Мин түкмәгән дә идем

Шул караны өстәлгә,

Тик сизәм — керә йөзем

Алсу, кызыл төсләргә.

Ә кичә Лена әйтә:

— Кызарасың юкка, — ди. —

Кызару модно түгел,

Кызарудан тукта! — ди...

Ә мин торам кызарып,

Китә алмыйм кузгалып.

## Җәнлекләр уйлый микән?

Җәнлекләр уйлый микән?

Төгәл белмим мин ансын.

Әйтик, песи уйлый микән

Соңыннан ни буласын?

Хәер, песи нигә әле

Ул турыда уйласын?

Койрыклары бар, уйлары
Бармы соң бозауларның?
Барын бардыр, каян белик
Уйларын без аларның.

Этләр дә уйлый беләдер,
Этләрне дә уй баса.
Колаклары шиңә этнең,
Сагышлы уй уйласа.

Кошлар турында да уйлыйм:
Уйлыйдыр кош халкы да.
Аларны да салкын өтә,
Өтеп ала ялкын да.

Уйлыйдыр алар иң элек
Кошчыклары хакында!

Җәнлекләр уйлый беләме?
Беләләрдер, белмичә...
Әби: «Юк!» — ди. Булмас әле
Тагын бер тикшермичә.

## Әтинең чыкты ачуы

Алып кайттым мин «икеле» —
Андый хәл сезгә таныш.
Әтинең чыкты ачуы,
Тик чыгармады тавыш.

Кычкырсын иде ул миңа,
Тәлинкә ватсын иде.
Ачуыннан көндәлекне
Идәнгә атсын иде.

Юк, ул миңа карамый да.
Имеш, аның күп эше.
Мин әйтерсең Павлик түгел,
Ниндидер бер чит кеше.

Ул миңа җавап кайтармый
Хәтта ашаганда да.
Юри карыйм сөйләштереп —
Җавап бирми анда да.

Уза берни булмагандай,

Карый да өстән генә.

Мин әйтерсең Павлик түгел,

Урындык, өстәл генә.

Бик борчый бу сөйләшмәү,

Юкка түгел бу дәшмәү!

Иван Беляков

русчадан

Походта

Эшләргә икән үзеңә

Походта бөтенесен:

Үз куллары белән эшли

Алик та бөтен эшен.

Учакны үзең ягасың,

Суны үзең ташыйсың,

Бәрәңгене үзең әрчеп

Һәм пешереп ашыйсың...

Шуңа күрә дә Аликка

Поход бер дә ошамый.

Походны яратучыга

Алик шуңа ышанмый.

Уйлый Алик:

«Поход шәп ул!» —

Диюләр ялган икән.

Бу походка әнине дә

Аласы калган икән».

Кара карлыган

— Кызлар, ашамадыгызмы

Сез кара карлыганны?

Яисә күрмәдегезме

Берәрсе кагылганны?

Әниләре соравына:

— Юк! — диделәр кызлары.

Бу сораудан ни өчендер

Валя гына кызарды.

Сеңелләре, моны сизеп,

Көләргә керештеләр,

Валяның кызаруыннан

Туйганчы көлештеләр.

Урлашкачтын, алдашкачтын,

Дуслар да көлә икән.

Хәтта кара карлыган да

Кызарта белә икән!

Читекле песи

Мин чиккән матур читекләр

Киеп кенә йөри ул.

Шуңа күрә уйнап кына,

Биеп кенә йөри ул.

«Җитәр инде сиңа, пескәй,

Гел мендәрдә аунама!»

Шулай дигәч, песи иртән

Китте тычкан ауларга...

Ята песи чоланда —

Тычкан аулый ул анда.

Әгәр тычкан да тотмаса,

Ул чын песи буламы?!

Килеп чыкса берәр тычкан,

Тотачак та ул аны...

Менә тычкан күренде,

Песи аңа үрелде...

Тик мескен тоталмады,

Тычканны йоталмады.

Тоталмады ул көндез дә,

Тоталмады кичен дә.

Тотар иде, тырнаклары

Калган читек эчендә!

Күп укысам...

Әни миңа туктаусыз:

— Укыйсың син сирәк, — ди. —

Синең кебек чакта, улым,

Күп укырга кирәк! — ди.

Күп укырга кирәклеген

Мин бит үзем дә беләм.

Ләкин берәр нәрсә булса

Әгәр дә минем белән?

Бертуктаусыз, берөзлексез

Көн саен укыганнан

Башым авырта башласа,

Авырып китсәм аннан?

Ул чагында әни үзе

Мине кызганыр иде,

Миңа караганда үзе

Ыграк сызланыр иде.

Теләсәм бит, уку миңа

Уен гына булачак!..

Тик чирләсәм, әниемә

Кыен гына булачак!

Леон Бриедис

латышчадан

Алмагачта ни үсә?

Ике малай бергәләп

Утыртты бер алмагач —

Бик тәмле, татлы алма

Бирә торган ул агач!

Малайлар бер көн көтте...

Алар ике көн көтте...

Өченче көн дигәндә...

Бер җимеш борын төртте.

Бу җимеш бик эредер,

Бик эре бер төредер!

Алмага да охшаган,

Хөрмәгә дә охшаган —

Мондый тәмле җимешне

Булмагандыр ашаган...

Тик җимеш дигәннәре

Агачтан очып чыкты...

Их, чыпчык булып чыкты!

Ояр Вациетис

латышчадан

Чынаяк ник ватыла?

Чынаяк ник ватыла?

Ник идәнгә атыла?

Ә чәй нигә түгелә?

Ашъяулыкка түгелә?

Ә?

Бирәсезме әйтеп сез?

Чынаякмы тәртипсез?

Чәйме шулай бик шаян?

Мин аны белим каян?!

Кем?

Минме шаян?..

Бер дә көлке түгел бу!

Нәрсә соң бу?

Аңлап булмый:

Бүре сайрый,

Үрдәк улый.

Крокодиллар

Зоопаркта

Мөгриләр, ди,

Бар халыкка.

Мәктәбенә

Бара Янцис

Һәм бакылдый...

Бигрәк ямьсез!

Ай-яй, бер дә

Килешми бит —

Тел бистәсе

Сөйләшми бит.

Эше хөрт

Бүтәннәрнең дә:

Өргәк этләр

Өрми бер дә.

Тешләми дә, ди,

Ул этләр...

Көлке түгел бу,

Егетләр!

Яңгыр

Яңгыр ява,

Ява яңгыр...

Хәтта яңгыр

Арыгандыр.

Шуңа да ул ял итәргә

Җиргә күчә.

Ә яңгырдан тәмле булып

Җиләк үсә.

Уйнатма!

Шырпыны син бер дә юкка

Уйнатма!

Гадәтләре начар аның —

Уятма!

Бишегендә тыныч кына

Йокласын!

Әтиең һәм әниең ут

Йотмасын!

Уеннан уймак чыгачак —

Күрерсең!

Соңыннан үзең үкенеп

Йөрерсең,

Кытыкласаң син шырпының

Табанын! —

Аңлатыр сиңа әниең

Калганын.

Биш

Тиздән биш — син бик дәү инде!
Бармаклар да биш.
Биш чатлы йолдыз нурларын
Сиңа сибә ич.

Әрәмәдәге биш каен
Уздырган барсын —
Әгәр әйбәт булып үссәң,
Биш дус табарсың.

Иң биек кар көртен биш кат
Ерып үткәчтен,
Син, әлбәттә, үсәчәксең —
Карлар беткәчтен.

Күтәртми үзең атларсың —
Авыр булса да.
Ямь-яшел май — бишенче ай —
Бишкә юл сала.

Әкәмәт әкәм-төкәм

Чыршы янында гына
Зур бер ал гөмбә үскән.
Гөмбә астына кичтән
Бер әкәм-төкәм күчкән.

Яңгыр койган өч атна.
Әкәм-төкәм җай тапкан —
Өч атна яңгыр чакта
Гөмбә астында яткан.

Яңгыр яумагач бүтән,
Сораган әкәм-төкәм:
— Бу гөмбә
Агулы түгел микән?

Яңгыр яумый башлаган.
Әкәмәт әкәм-төкәм,
Вәт мәзәк әкәм-төкәм —
Үз зонтигын ашаган!

Кем кемгә хезмәт итә?

Ул велосипедта түгел,

Ә мопедта җилдерә:

Бер җилдерә, ун җилдерә,

Ул җилдерә илле дә!

Янка бармакчы урманга,

Мопед чаба инешкә,

Җен шикелле ярсып тора

Хәтта сүнгән килеш тә.

Мопед булгач, дуслар белән

Ул хәзер уйнамый да.

Янка ашыга дәрескә,

Ә мопед уйламый да.

Янка, әлбәттә, алачак

Тагын «ике», тагын «бер».

Ул әйбәт укымакчы да,

Ә мопедка барыбер.

Кайтып керми Янка өйгә:

Ашамый ул, йокламый...

Кайтыр иде, йоклар иде,

Мопеды бит туктамый!

## Апельсин

Әнием әле эштә,

Әти дә әле эштә.

Бер әйбер бар бер төштә —

Шулкадәр сары төстә!

Бик тәмле, бик матур син —

Ник көләсең, апельсин?

Ятсын әни кайтканчы,

Ятсын әти кайтканчы,

Тик ничекләр түзәрмен?!

Апельсинда күзләрем!

Апельсин мине белә —

Апельсин шуңа көлә!

Үзем генә!

— Таганга мин килдем башта,

Атынам үзем генә! —

Атына Янцис! Калганнар

Көтәләр сүзсез генә.

«Үзем генә!» — ди туктаусыз,

Йоммый хәтта күзен дә.

Еллар узар, Янцис, шунда

Син аңларсың үзең дә:

«Үзем генә!» Футболны да

Берүзең уйныйсыңмы?

Үз капкаңа тупны үзең

Кертергә уйлыйсыңмы?

«Үзем генә!» Бокста да

Син рингка чыгарсың.

Үз-үзеңне тукмаганда,

Белмим, ничек чыдарсың.

Әбәкле уйнаганда да

Онытма шул сүзеңне:

Чөнки туры килер сиңа

Куарга үз-үзеңне!

Артык аяклар

Янцис, Янцис, урам аша

Ничек чыгарсың?

Бәлки әле, әниеңнән

Ярдәм сорарсың?

Кунакка ничекләр барып

Җитәрбез тизрәк —

Аякларың юл йөрергә

Хәлсез шул бигрәк.

Юл чокырлы да чакырлы —

Сине көтәбез.

Ике адым атлыйбыз да

Йоклап китәбез...

Әйдәгез, зоопарктан

Пони алабыз —

Лония апага юкса

Соңга калабыз.

Болай булгач, аякларың

Эштән арынды...

Ташлап калдыр, Янцис, син ул

Аякларыңны!

Трамвайлар трамвай түгел инде

Рәсем ясыйм.

Ә алар —

Чылтыр-чылтыр-чың-чың-чың,

Нәкъ Яңа ел чыршысында

Чылтыраган уенчык.

Әти әйтә:

— Тартма бусы.

Әни:

— Нинди тартма булсын?!

Бу бит без —

Икәү трамвай көтәбез.

Рәсем ясыйм.

Тик трамвайлар

Инде чылтырамыйлар —

Бер-берсенә карамыйлар,

Юлга гына карыйлар.

Мин бит беләм,

Сугышырга да мөмкин

Алар бер-берсе белән.

Койрыклы уйнау

Ике тычкан баласы
Уен уйлап ятканнар
Һәм бер уен тапканнар:
«Әйдә, без койрык бәйләш
Уйнап алыйк, энекәш!»

Тик әйткән әниләре:
«Андый уен ярамый!»
«Ә ни өчен ярамый?
Койрыкларны, энекәш,
Бәйлик, чөнки ярамый!»

Бу уен — гади уен!
Бик җиңел андый уен!
Уен чынга әйләнгән:
Ике койрык бәйләнгән!

Күренгән тагын берсе —

Койрыкның би-и-ик олысы!

Кемнеке дип уйлыйсыз?

Песинеке...

Монысы!

Кемнең эчендә ни бар?

Ак тузганаклар эчендә

Очырткыч бар:

Оча-оча туза алар!

Мотоцикллар эчендә

Кычкырткыч бар:

Тыр-тыр-тыр-тыр уза алар!

Ә сәгатьләрнең эчендә

Тизләткеч бар:

Келт-келт-келт-келт килә алар!

Ә менә кызлар эчендә

Көлдергеч бар:

Кет-кет-кет-кет көлә алар!

Ә кояш эчендә исә

Яктырткыч бар:

Дөнья якты-якты-якты!..

Ә менә синең эчеңдә

Елаткыч бар:

Яшьләрең бит акты... акты...

## Кесә

Әйтегез, кесәмдә ник

Йөри бик дәү подшипник,

Һәм бәләкәй подшипник,

Һәм болтларның төрлесе,

Ачкычы, өтергесе,

Җиз һәм бакыр алкалар,

Шөрепләр һәм гайкалар,

Һәм төрле тимерчыбык,

Һәртөрле тимер чыбык;

Кесәдән тора чыгып

Төрле тимер кисәге?

Юк аларның исәбе!

Ә???

Чөнки мин ни кисәм дә,

Трактор бөтен килеш

Сыялмый бит кесәмә!

Бәхәстәнме? Бәхәстән!

Бәхәстәнме?

Бәхәстән!

Тик барыбер

Бу бәхәстә мин отам!

Отар өчен ике кулга

Ике зу-ур имән тотам.

Күтәрәм — эһ тә итмим!

Тылсымчы төсле бит мин!

Ә хикмәтен кем белә?

Карап торыгыз менә:

Бер чикләвек —

Уң кулда!

Бер чикләвек —

Сул кулда!

Ә чикләвек...

Һәр чикләвек —

Болытларга кадәр тигән

Зу-у-у-у-ур бер имән!

Җиргә күмелсен генә...

Үскәч күрерсез менә!

Кояш тәме

— Нәрсә соң бу?

Сары күзме?

— Сөйләмә лә син юк сүзне!

Ул бит кояш.

Кайнар.

Әйбәт.

Мә, кабып кара кояшның

Иң тәмле төшен!

Ләкин төшен йота күрмә —

Төкер син төшен!

Тиз йөрүнең җае

Атлыйм ике аяклап,

Ә Дуксис — дүрт аяклап.

Ух, ул сыптырта гына!

Өстә бер кош кагына —

Җитезрәк ул тагы да!

Табигатьтән сорыйм әле,

Юри генә сыныйм әле:

Булсын иде минем дә

Җитез-җитез алты аяк

Һәм биш канат кимендә.

Җиләк турында җыр

— Кичә пешмәгән идең.

Бүген дә пешмәгәнсең.

Иртәгә дә пешмәссең —

Син әллә нишләгәнсең.

Һаман да кызармыйсың —

Халыкны кызганмыйсың...

Бар дисеңме ни эшем?

Ә тамагым ни өчен?

Тели тамак тәмлене.

Ә син менә тәмлеме?

Юк шул, бер дә мактана

Алмыйсың син бу яктан.

Беләсең килсә, бездә

Кызаралар ояттан.

Сиңа оят түгелме,

Яшь җиләк, яшел җиләк?

Яшь килеш, яшел килеш

Син, җиләк, кемгә кирәк?

— Син инде, Янцис, бигрәк, —

Дип көлә яшел җиләк. —

Әгәр дә мин кызарсам,

Синең бит күзең кызар.

Яшь малай, яшел малай,

Белдекле булгач алай,

Булмагач бер эшең дә,

Бөтенебез өчен дә

Син инде үзең кызар!

Диңгез бүресе

турында моңсу җыр

Диңгезгә ыргытсаң бүрене,

Ул диңгез бүресе булачак.

Ачудан, кайгыдан көн саен

Корабларны тотып буачак,

Һәм, диңгез бәрәне дип уйлап,

Дулкыннар көтүен куачак.

Бәрәннәр ярата печәнне,

Клеверны, кәлшәне — төрлесен.

Дулкыннар — ак бөдрә бәрәннәр

Куыша диңгездә бер-берсен.

...Тик аларны ашап булмый.

Бик тозлы бит.

Авырттырыр аның эчен.

Шуның өчен —

Уламасын өчен бүре кайгыдан,

Ташламагыз сез бүрене диңгезгә!

Шуны гына әйтә алам мин сезгә.

## Күлдәвек

Зәңгәр күлдәвек
Әллә магнитлы —
Көн дә үзенә
Тарта Янитны.

Әни тиккә тирги лә:
Әти бит сөйли белеп —
Диңгезләрнең барсы да
Күлдәвек булган элек.

Хәтта капитаннар да,
Вице-адмираллар да...
Күлдәвек яратканнар
Минем яшьтә алар да!

Өлеш тә төшкән! Ә мин

Шуны әйтә аламын:

Сайлап алыйк диңгезнең

Үзебезгә таманын.

Зәңгәр күлдәвек

Әллә магнитлы —

Көн дә үзенә

Тарта Янитны.

Кушу

Берне бергә кушсаң — ике

Була ич.

Ә икене бергә кушсаң —

Була өч.

Ә песине кушкан чакта

Көчеккә?

Булмас шул берничек тә.

Берсе дерелдәп утыра

Әнә агач

Түбәсендә,

Икенчесе

Саклап тора

Тирәсендә.

Йокы

Почмакта нәрсә ул

Чыңлады?

Ни өчен тәрәзә

Зыңлады?

Әллә соң берәр кош

Тигәнме?

Кем анда селкетә

Идәнне?

Ята Янцис тавыш-тынсыз,

Күзен йомды инде ничә...

Килә, килә, йокы килә

Аңа шулай сиздермичә.

Җирнең тарту көче

Агач үсә өскә таба,

Өскә таба — үлән дә,

Ә яңгыр ява түбәнгә,

Алма да — һап! — түбәгә!

Ә берәр хәйлә корсаң?

Баштүбән әгәр торсаң?

Булыр дисезме тылсым?

Соң, әйдә шулай булсын:

Баштүбән торсам әгәр,

Алма өскә тәгәрәр!

Торам шулай.

Баштүбән.

Аяк — өстә.

Баш — түбән.

Булмый шул

Җирне алдап...

Һап! —

Алма түбәнгә төште.

Җитмәсә, авырттырды

Минем иң йомшак төшне.

Бигрәк күңелсез агач

Кара кәүсәгә

Күңелсез түгел.

Ап-ак карга да

Күңелсез түгел.

Ә шулай да барсы да

Бигрәк күңелсез бүген.

Күршеләрнең чирли эте,

Әни елый нигәдер.

Дус кызым тапкан яңа дус.

Гаеп, бәлки, миндәдер?

Бүген кояш булмас кебек.

Булмас, ахры, күрерсез.

Ә кояш озак булмаса,

Агачка да күңелсез.

Григоре Виеру

молдаванчадан

Аю

— Кая юл тоттың, аю?

— Калага — чыршыларга.

— Чыршылар сиңа нигә?

— Яңа ел каршыларга.

— Ә соң кая куярсың?

— Урын булыр анысы.

— Урманда чыршы юкмы?

— Жәл шул урмандагысы.

## Туган тел

Җырламый бүген җырчы кош.

Бәлки, бик аргандыр ул.

Юк ла, безнең сөйләшкәнне

Тыңлап тын калгандыр ул.

Әгәр дә бик кирәк булса

Иң моңлы сүз, матур сүз,

Безнең туган телебездән

Алсын ул кош, әйтерсез!

Кызый

Бар бер кызның толымы.

Алсу тасмасы — яңа.

Бар бер малай — тасмасын

Тартырга булсын аңа.

Бар малайның әтисе.

Каеш аның кулында.

Ләкин кызый нигәдер

Ләм-мим малай турында.

Болыт белән салават күпере

Шаян кыз булып

Очасың, болыт,

Толымнарың таралган,

Матур булып кабарган,

Тылсымлы болыт!

Шаян кыз булып

Очасың, болыт,

Бездән китеп баргансың,

Толымнарың кая соң,

Тылсымлы болыт?

Шаян кыз булып

Очасың, болыт,

Син инде башка төштә,

Тик тасмаң калган өстә —

Нәкъ җиде төстә!

## Әйтче, кояш!

— Әйтче, кояш, синең нурлар

Һәммәсе ничәү икән?

— Нурларымның һәммәсен дә

Мин сезгә бүләк итәм!

— Әйтче, кояш, нурларыңда

Җылына ничә кешең?

— Санарга минем вакыт юк,

Иркәләү минем эшем!

## Йон

Балконга чыккан әни:

«Тизрәк кер, Йон, өйгә!» — ди.

Чакыргачтын ул болай —

Минем эшләр хөрт бугай...

Ул мине сагынса бик,

Чакыра Йоница дип!

## Доктор

Малайлар, юкка сез

Доктордан куркасыз.

Бик әйбәт ул, димен:

Әни бит ул минем!

## Туп

Сикерә минем алда

Акыллы туп, яңа туп —

Аның әле бер кат та

Тәрәзә ватканы юк!

## Дуңгыз баласы

Ул көзгегә караган —

У-у-у... йөзләре каралган!

Юынырга дип, аннан

Сазлыкка китеп барган.

Василий Давыдов-Анатри

чуашчадан

## Ак теплоход

Ап-ак теплоход
Кузгалып китте,
Ул мине бик нык
Кызганып китте.

Аккош шикелле
Бара ул йөзеп.
Артыннан чапмый
Торам чак түзеп.

Теплоход белән
Бик китәр идем,
Алмыйлар матрос
Итеп тә мине.

Көчегем миннән
Карашын алмый —
Ул гына минем

Хәлемне аңлый.

Нодар Думбадзе

грузинчадан

Энә

Кайчаннан бирле менә
Әбием саплый энә.

Энәгә ул җеп саплый,
Ә үзе
Энәнең күзен тапмый.

Күзе бигрәк кечкенә,
Җебе керми һич кенә.

Карап торам тын алмый:
Әллә энә тыңламый,
Әллә җебе тыңламый,

Әллә кулы тыңламый?!

...Әбинең күзе күрми,

Энәнең күзен күрми,

Җеп, ахры, шуңа керми.

Әбием шуны белми.

Энәне миңа бирми.

Сильва Капутикян

әрмәнчәдән

Рәсем

Ясадым мин нәни тычкан.

Ул почмакка кереп поскан.

Почмакка ул юкка поскан —

Янамый бит аңа дошман.

Әмма сизсәм урлашканын,

Мин аны тиз тыячакмын —

Каршысына ук олы бер

Песи ясап куячакмын!

Рөстәм Кутуй

русчадан

Ачыгавызлар

Безнең зоокибеттә

Көннәр буе, әлбәттә,

Кесәләрен капшыйлар,

Тиеннәрен кашыйлар

Ачыгавыз малайлар, —

Күрәсең, бик бай алар!

Була шул ул андыйлар...

Юк, берни дә алмыйлар —

Бирмәсләрме дип бушка,

Карыйлар тутый кошка.

Сатучы да түзмәде,
Тезде мондый сүзләрне:

— Сез нигә таптанасыз?
Сез соң нәрсә аласыз?
Кызык әйбер юк монда,
Ә менә гастрономда
Саталар тәмле сагыз,
Йөгерегез алсагыз!

Малайлар торып чапты
Шул гастрономга чаклы...

Атлый-атлый лас та лос,
Сагыз чәйнәп лач та лоч,
Тагын килеп бастылар,
Авызларын ачтылар.

Ә сатучы пыр туза,
Бер суына, бер кыза:
— Алмыйсыз берни сатып,
Торасыз эшсез басып.
Нигә шулай шаулыйсыз? —
Эшкә комачаулыйсыз.

Малайлар тыңладылар.

Ә шулай да

Җавапсыз калмадылар:

— Өч атна көттек-көттек,

Үзебез арып беттек.

Сөйләшә белми икән

Бу тутый кошларыгыз,

Тутый-йолкышларыгыз.

Сөйләшмәгән тутый кошлар

Бушка да кирәк түгел.

Шуларны сатып алырга

Без әле дурак түгел...

Соң, әлбәттә, алдыйлар.

Нигә дисәң, шул кошлардан

Күзләрен дә алмыйлар.

Шәрык базары

Базар гөр килә,
Базарда — халык.
Алма да хөрмә...
Йөрим таң калып!

Мондагы төп эш —
Этеш тә төртеш,
Төртеш тә этеш,
Чиратта көтеш...

Безнең бакчада
Кавын — галәмәт!
Минем баш кадәр!
Белдегезме? Вәт!

Ә карбызлармы?
Самавыр чаклы!
Шикәрдән татлы,
Балдан да татлы!

Базардагысын
Ашыйсы килми,
Өйгә кадәрле
Ташыйсы килми...

Базарда бүген

И мәзәк, и шәп!

Өйгә кайтасы

Килмидер нишләп?!

Озын муенлы жираф

Җылы шарфым — муенда,

Ә күзләрем — урамда.

Чыгармыйлар уйнарга,

Авыргалап торганга.

Авырдым шул тагын да...

Озын муен буладыр

Озын жирафта гына.

Пингвин ул — алпан-тилпән,

Ябалак күрми иртән.

Куркыныч, бик куркыныч

Арысланның яллары...

Ә минем әни генә бар!

Мин бар инде аннары...

Тәрәзәдә — кып-кызылтүш,

Тышта рәхәт һәм салкын.

Миңа гына рәхәт түгел —

Бер салкын да бер ялкын.

Өченче көн шулай инде:

Гел тышта гына уем.

...Жирафныкыннан да озын

Булмыйдыр озын муен.

Су карты

Су карты бар коеда.

Коеда ул коена.

Сакалы менә мондый!

Су карты андый булмый?!

Була икән шул менә —

Әбием барсын белә.

Суыкта ул дерелди,

Үзе безгә күренми.

Ишетми ул берни дә,

Ишетми дә, күрми дә.

Күрә бары үз көнен,

Мескенем...

Исемдә әле әл дә —

Сөйләгән иде әби

Бияләй бәйләгәндә.

Бау

Күзләрем төште бауга,
Исем китте карауга.

Аптыратты ул мине:
Урап алган туфлине.

Күзне дә алмыйм аннан,
Аякны урап алган,

Елан төсле уралган,
Аерылмый еланнан...

Йөрәк куйды җилкенеп —
Бавым куйды селкенеп.

Күтәрде дә ул башын...
Кинәт тешләп куймасын!

Абау!..
Белдем нишләргә! —
Сикердем мин өстәлгә.

Өлгермәде тешләргә...

Тагын нәрсә өстәргә?

Әни кайтты кичләргә.

Сергей Михалков

русчадан

## Кызылтүш

Мәктәптән соң мин бүген

Соңгарак калып кайттым —

Мин кошлар базарыннан

Кызылтүш алып кайттым!

Кызылтүш — шундый матур,

Тавышы — шундый көчле:

Сайрап җибәрде кошым

Нәкъ урмандагы төсле!

Сайрар әле кызылтүш

Күзләрен-кышларын да.

Сайраганын күрергә

Килделәр дусларым да.

Туйдырды ла кызылтүш

Ике атна дигәндә.

Тыңлыйм хәзер мин аны

Бары вакыт тигәндә.

Ә бервакыт шәһәрдән

Китеп тордым өч көнгә.

Ялгызына калырга

Туры килде мескенгә.

Мин югында кызылтүш

Чак-чак кына үлмәгән:

Ашарына беткәчтен,

Ни ашарга белмәгән.

Сыйладым бөртек белән,

Сыйладым җим биреп тә.

Туйганчы су эчердем

Һәм очырдым иреккә!

Тынычлык

Җыела өйгә кунаклар:
Женяның туган көне.
Женяның зур юбилее —
Сигез яшь тулган көне!

Алып килгәннәр бүләккә
Пистолет һәм автомат,
Кылыч, мылтык һәм пулемет —
Теләгәнчә ат та ат!

Көтә дә малай бүлмәдән
Кунакларның чыкканын,
Ыргыта сүтеп, ботарлап
Бөтен уенчыкларын.

Ә кунаклар кала телсез,
Йөзләрендә — сызлану.
Женя көлә: «Борчылмагыз!
Бу бит коралсызлану!»

Булдыксыз

«Бик булдыклы булалар
Тик талантлы балалар:
Концертта катнашалар,
Җырлый-бии алалар.

Әгәр дә матур сурәт
Ясасалар балалар,
Журналда бастыралар,
Күргәзмәгә алалар.

Турнирга йә конкурска
Чит илләргә баралар,
Күпме бүләк алалар
Тик талантлы балалар!

Лисичкина Наташа —
Җиңүче һәр ярышта!
Гарик исә — лауреат!
Җиңелми бит ялгыш та.

Булдыксызларга гына
Бөтен юллар ябылган...»
Шундый сүзләр сибелә

Миңа әни ягыннан.

Каршы килмим — сөйләшмим,
Иң әйбәте — эндәшмим.
Бу күңелсез темага
Мин бер дә бәхәсләшмим.

Әйдә, башка балалар
Түгәрәккә йөрсеннәр,
Рәсемнәр төшерсеннәр,
Хәтта җырлый белсеннәр.

Скрипка уйнасыннар,
Кинода уйнасыннар,
Үзләрен бик талантлы
Кеше дип уйласыннар.

Мин беләм кем булырга!
Мин югалмам кайда да:
Үсеп җиткәч, беркөнне
Китәчәкмен тайгага.

Әле дусларымны да
Тайгага алачакмын.
Алар белән бергәләп
Тимер юл салачакмын.

Рельс буйлап поездлар

Кош кебек очар әле.

Мин төзегән тимер юл

Әнигә ошар әле!

Мине бик оялтса да,

Әнидә — әйбәт теләк.

Тик төзүче җырчыдан

Барыбер кирәклерәк!

Юозас Некрошюс

литвачадан

Сугыш чукмарлары

У-у-у... узыша-узыша,

Әй тузыша-тузыша,

И кызыша-кызыша

Ике әтәч сугыша.

Калдырып бар эшләрен,

Сынашалар көчләрен.

Ни өчен?

Бер кабым ипи өчен!

Әтәчләнеп алгачтын,

Арыгачтын-талгачтын,

Бераздан киңәшкәннәр,

Үзара килешкәннәр.

Икесе дә, суырып,

Берәр каурый алганнар,

Әйбәт яза торганын

Карый-карый алганнар.

Сугышып алар туйган —

Ике як та кул куйган

Солыхка, тынычлыкка!

Сугышканнар ла юкка!

Куяннар төш күрә

Үзе тын, үзе салкын —
Туңдыра куян халкын.

Алар йоклый, төш күрә:
Төшкә кәбестә керә.

Кәбестә татлы-татлы,
Чөнки ул катлы-катлы.

Күчәне татлы бигрәк,
Тизрәк ашарга кирәк!

Ялтыратып куйганнар
Кәбестәне куяннар!

Чү!
Нәкъ авыл ягында
Этләр өрә тагын да!

Яңа йортка күчкәндә

Күченәбез яңа йортка,
Күчәбез биек йортка.
Тик курчаклар киреләнә:
— Күченәбез лә юкка!

Иске фатирыбызда да
Яши идек күңелле.
Барыбыз да сыя идек,
Әллә шулай түгелме?

Арысланның коты очты,
Лифтка килеп кергәч.
Читлек дип уйлаган икән —
Чак тынычланды белгәч...

Мәче мырлый:
— Яңа йортта
Йокларга да йокларга.
Яшәми икән тычканнар
Мондый биек йортларда.

Аю гына эчен уа:

— Яши алам кайда да.

Балы булса...

Тагы булса...

Яшәп була Айда да!

## Скрипкачы чикерткә

Чикерткә базардан

Скрипка алган.

Иң матур көйләрне

Уйнаган ул аннан.

Шул көйләрне тыңлап,

Грушалар да пешкән,

Кортлар да бал җыйган,

Ашлык та җитешкән.

Алмалар алланган,

Җиләкләр кызарган.

Көз килгән бераздан.

Кызыккан көзге җил,
Көнләшкән көнче җил,
Әйбәтрәк, матуррак
Уйнагач үзеннән...

Их, шаян скрипканың
Кыллары өзелгән.

Карга бичара

Тормаган бер дә аяп,
Ыргыткан кемдер таяк.

Хәтта таш белән аткан,
Канатларын канаткан.

Яраларын карадым

Яраланган карганың.

Су эчердем, ашаттым.

Ә син аңа таш аттың.

Әй усал уйлы малай,

Ник иттең инде алай?

Бар иде нинди үчең?

Оялам синең өчен!

Ни өчен?

Балаларга ник колак? —

Үсәргәдер иң матур

Сүзләрне генә тыңлап.

Ә күзләребез нигә? —

Җирдәге гүзәллекнең

Һәммәсен дә күрергә.

Аякларыбыз нигә? —

Гомер буе җирдәге

Юллар буйлап йөрергә.

Ә кулларыбыз нигә? —

Безгә тиеш эшләрнең

Барысын да җиңәргә.

Ә башларыбыз нигә? —

Эшләпәләр, башлыклар

Һәм бүрекләр кияргә.

Шаяртмагыз, беләсез,

Юри генә көләсез...

Кирәк ул иртә-кичен

Әйбәтләп уйлар өчен!

Геннадий Паушкин

русчадан

## Кыш

Кыш. Тагын кыш. Тагын ап-ак.
Ап-ак дөнья. Кич — тынган.
Юк ла, әнә җилләр килә!
Җилләр бәйдән ычкынган.

Карларга бәйләнеп, җилләр
Басу-кыр буйлап йөри.
Әллә буран чыгарырга
Кар белән уйнап йөри?

Авыр сулап куя имән,
Тездән көрткә чумган да.
Кар эчендә басып тору
Читендер шул чыннан да.

Кар — ак дәфтәр.
Ә кошлардан
Тылсымлы эзләр кала.
Без белмәгән, аңламаган
Ниндидер сүзләр кала.

Кичкә суык батырлана —

Өтеп ала яңакны.

Өтсен — без бит котыпчылар

Булырга да яраклы.

Ай-яй суык! Тик шулай да

Түзмәслек түгел бер дә.

Мондый көнне көньякта да

Бик эссе түгелдер лә!

Яз

Узган елдан, бер хатирә булып,

Яңгырыймы дисәм кайтаваз,

Сайрый-сайрый кайта, кошлар булып,

Гөрләвекләр булып кайта яз.

Ераклардан — чит-ят төбәкләрдән —

Очар кошлар кайта тезелеп.

И сайрыйлар! Туган илкәйләрен

Сагынган шул алар өзелеп.

Урман тулы, болын тулы кошлар:

Җыр яңгырый һәрбер ояда.

Кайткан алар үз җырлары белән

Күңелләргә канат куярга!

## Көз

Көз бүләкли һәммәбезне:

Игенчегә — алтын бодай,

Балыкчыга — симез чуртан,

Ә зурлыгы менә бола-ай!

Тырыш бакчачыларгамы? —

Тулып пешкән кызыл алма.

Көтүче һәм умартачы

Йөзәр хәзер майда-балда.

Кемнәр көзгә сөеп карар —

Шулар шигырь эзләп табар!

Владимир романов

удмуртчадан

Дуслашасым килә!

«Ул малай бик тәртипсез,
Сугыш чукмары!» — дисез.
Димәк, әле сез аны
Бөтенләй дә белмисез.

Беләм әйтмәсәгез дә,
Бар аның сугышканы.
Дөресрәге, кызларга
Бар аның булышканы.

Бәйләнде бер әзмәвер
Күрше кызына беркөн.
Әмма кызны якларга
Якын килмәде беркем.

Ә малайлар — гарьлекләр
Курыктылар якларга.
Курыктылар... качтылар...

Аларны ник якларга?

Ә ул менә килде дә
Яклашты күрше кызын.
Гарьлектән йодрыкларын
Төйнәде теге озын.

Көлгән булды әзмәвер:
— Яле, сыздыр тиз генә!
Әһә, курыкмыйсыңмы?
Ул чагында түз генә!

Качып китмәде малай,
Бик китмәде исе дә.
Үзенең, минсиңайтим,
Бар икән, әй, көче дә!

Егып салды тегене
Шундый җилле иттереп —
Чын көрәшче шикелле
Бөтен шартын китереп.

Ә шуннан соң әзмәвер...
Сөйләп тормыйм барысын.
Шундый хәл булган иде,
Бик хәтерлим анысын.

Ә сез: «Сугыша!» — дисез.

Сугышканын да беләм.

Тик дуслашасым килә

Нәкъ шундый малай белән!

Киребеткән утын агачы

Утыннар киребеткән —

Интегәм инде күптән.

Ярылмый берничек тә!

Менә хәзер күлмәкне

Элеп куям ишеккә.

Бик каты булсагыз да,

Карышып торсагыз да,

Үткен балтамны тотып,

Бер селтәнсәм ныгытып,

Әйләндерәм мин сезне

Йомычкага, тузанга.

Күпме әле сез анда?

Йә, чиратта кайсыгыз?
Әйдә, рәхим итегез!
Сез бит ялгыз, без менә
Балта белән икебез!
Бу Васяга иярсәң...

Вася гел кул күтәрә,
Никтер гел ул күтәрә.
Чыгып такта янына
Сөйләмәкче тагы да!

Ләкин аны күрмиләр,
Теләгәнен белмиләр.
Миннән генә сорыйлар,
Мине генә сыныйлар.

Гел тактага дәшәләр.
Беләм лә: көнләшәләр!

Велосипеды булса,
Вася да «икеле»ләр,
«Өчле»ләр алыр иде,

Гел артта барыр иде,

Койрыкта калыр иде...

Ә мин велосипедта
Көн буе йөрдем кичә,
Егылдым әллә ничә.

Барыбер туктамадым —
Әй җилдем җил шикелле.
Шуңа да көндәлектә
Бүген тагын «икеле».

Үзе кул күтәрсә дә,
Васядан сорамыйлар,
Тактага чыгармыйлар.

Шулай да нигә икән?
Сәбәбе нидә икән?

Әллә инде миңа да
Шулай итәргә микән?
Кул күтәрергә микән?

Йә, ярый, шулай итәм!

Икенче көнне иртән,
Беренче дәрестә үк,

Кулымны мин дә суздым.

Сузуын суздым, ләкин
Бөтен эшемне боздым:

Чакырдылар тактага,
Түгел инде мактарга,
Такта төбе таптарга...

Берни дә аңлый алмыйм,
Әллә ни булды башка.
Шунсы хак — велосипед
Тәтемәс миңа башка!

Кояш белән сөйләшү

Кояшым, ник ашыгасың? —
Бераз гына көт инде.
Безнең өстән үткән чакта
Акрын гына үт инде.

Юкса безне, кояш баткач,
Йоклыйлар дип балалар,
Әниләр тышта уйнатмый,

Өйгә дәшеп алалар.

Тукта инде!
Нигә инде
Тыңларга теләмисең?
Качарга җыенган кебек,
Түбәнгә тәгәрисең?

Ачуландырсаң, мин сине
Шундый тыярмын әле:
Нурларыңны торбабызга
Бәйләп куярмын әле!

Кузгалаклар

Әтисе кич арып-талып
Кайтты эштән — урманнан.
Миткәгә дип кузгалаклар
Алып кайткан ул аннан.

Малайларны кызыктырып
Ашармын, дип, иртәгә,
Миткә ул кузгалакларны
Яшергән, ди, киртәгә.

Ә күршеләрнең кәҗәсе,

Шунда уйнап йөргәндә,

Миткә кузгалакны кайда

Яшергәнне күргән дә,

Миткә киткәч, тәмләп кенә,

Ялт кына ашап куйган.

Иреннәрен ялап куйган —

Кәҗәнең тамак туйган...

Хәлдән тайган ул, кәҗәне

Урамга куа-куа.

Үзе куа, үзе елый,

Күзләрен уа-уа.

Ела, ела! Андый чакта

Күңел тула инде ул.

Иптәшләреңне онытсаң,

Шулай була инде ул!

Гөмбәгә баргач

Гөмбә җыйдым мин көн буе,
Кәрзинем дә туп-тулы.
Сукмак буйлап, җырлый-җырлый,
Өйгә кайттым туп-туры.

Караңгы иде урманда,
Кичә кайттым кич кенә.
Тулы кәрзин күтәреп тә
Ардырмады һич кенә...

Ә бүген көн якты иде,
Кояш иде бүлмәдә,
Тик урманда, үч иткәндәй,
Тапмадым бер гөмбә дә.

Кайтып киттем шул сукмактан
Бер гөмбәсез көемә.
Шундый ардым. Көч-хәл белән
Кайтып җиттем өемә.

Раиса Сарби

чуашчадан

## Тәүге яфрак

Дөп тә дөп килә бөре —
Күренми берни эчтә.
Тизрәк чыгарга кирәк —
Түзеп тора ул көчкә.

Аннары кинәт кенә
Карады да үрелеп,
Язның тәүге яфрагы
Калды күктә эленеп.

Рәхәт икән яз көне,
Яфрак шуңа көләдер —
Язгы җилдә яфракның
Йә кытыгы киләдер.

Ләкин шушы шатлыкны
Кем белән бүлешергә?
Аңа дуслары кирәк
Бергәләп көлешергә.

Ә яфракның дуслары
Әле бөре эчендә.
Моңсурак берүзенә
Менә шуның өчен дә.

Дусларсыз бу дөньяда
Түгел бер дә күңелле.
Җитмәсә, кояшы да
Болытларга күмелде.

Яфрак елап җибәрде
Сөртә-сөртә яшьләрен.
Тамдырды бугай яңгыр
Тамчыларның яшьләрен.

Уятты язны яңгыр —
Төртеп чыкты бөреләр.
Берәү, икәү, өчәү, дүрт... —
Һәммәсе бертөрлеләр.

Тотындылар бөреләр
Биергә, кул чабарга!
Елмайды тәүге яфрак
Һәм кушылды аларга.

## Мин җырларга яратам!

Мин җырларга яратам,
Тыңларга да яратам.
Җырларымны яңгыратам,
Бар дөньяга таратам.

Җырлыйм кояш турында да,
Тургайларга кушылып.
Җырларым канат кага да
Очып китә кош булып!

Җырларымда Туган илне,
Туган җирне зурлыйм мин.
Без бу җирдә дус һәм туган —
Рәхәтләнеп җырлыйм мин!

Рус малае, татар кызы —
Дусларымның барчасы
Кушыла миңа... Гөр килә
Безнең дуслык бакчасы!

Бүләк

Кызып-кызып нидер эшли,
Энем мине күрми дә.
Читтән генә күзәтәм, тик
Аңлый алмыйм берни дә...

Такталарга кадак какты,
Капкач урынын уйды.
Гади генә такталардан
Сандык булды да куйды.

Аннан энем карады да
Күзләремә туп-туры:
«Туган көнеңә бүләк!» — дип,
Шул сандыкны тоттырды.

Тик шатлыгым бик тиз сүнде.
Ул хәйлә корган икән:
Әлеге сандык дигәнем
Кош тота торган икән.

Күз алдыма китердем дә,

Кошларым-чибәрләрем

Тар читлектә утыра дип,

Чак елап җибәрмәдем.

— Бу тартмадан җимлек ясап

Бир син, — дидем энемә. —

Ул җимлек зур бүләк булыр

Минем туган көнемә.

Каеннар – юртаклар

Юл буйлап чаба каеннар,

Әй чаба безгә табан.

Кая ашыга соң алар?

Арыганнардыр тәмам.

Алар, бәлки, чабалардыр

Куркып язгы ташудан.

Ул каеннар куркалардыр

Урманны су басудан.

Элдерә генә каеннар —
Әйтерсең лә юртаклар.
Кемнән куркып йөгерәсез,
Әй юртаклар-куркаклар?

Әһә, белдем — каеннарның
Булмагач оеклары,
Кыш буе салкында торып,
Туңгандыр аяклары.

Шуңа бара алар чабып,
Чабышып, уйнап, биеп,
Язны иң беренче булып
Каршы алырга диеп!

Рәсем

Өебезне ясадым —

Безгә рәхим итегез!

Бусы — елга,

Бусы — көймә,

Болары — без икебез.

Бусы — сукмак китеп бара,

Бусы — кыр,

Бусы — бодай,

Бусы — кәҗә, тик ишәккә

Бераз охшаган бугай.

Хәзер бакча ясап куям —

Кыяр ашарбыз кереп.

Аннан көймәдә йөзәрбез

Өч ай элекке кебек.

Яңадан балык сөзәрбез —

Балыклар күп ул анда.

Комачаулый алмас әле

Кар яуса да урамда.

Килеп чыкты җылы рәсем —

Җәй елмая каршыда.

Кояш. Рәхәт.

Нәкъ мин үзем

Теләгәнчә барсы да.

## Күлмәген юа тупыл

Суда торып туңган тупыл,

Күлмәге дә чыланган.

Торма инде суда, тупыл,

Торма инде, чык аннан!

Кояшлы булса да көннәр,

Язгы су суык бит ул.

Язгы кар суларыннан да

Суп-суык су юк бит ул.

Бигрәк шаян шул яшь тупыл —

Суга килеп кергән бит.

Рәхәт булгач, көннәр буе

Суда уйнап йөргән бит.

Уйнаганда ак күлмәге
Балчыкка буялган бит.
Буялган күлмәген күргәч,
Тупыл бик оялган бит...

Телидер ул шушы килеш
Әнисенең күрмәвен.
Шуңа күрә суда әнә
Юып тора күлмәген!

Халмурат Сапаров

каракалпакчадан

Вакыт уза

Кемнәр анда эшсез ята?
Вакыт көтеп торалмый.
Узып киткән вакытларны
Беркем кире боралмый.

Уен-көлке, күңел ачу
Ялкауны кызыктыра.
Без эшләрне эшләп калыйк —
Вакытлар узып тора.

Мәктәпләргә дәшә вакыт,
Шигырьләр ятлаттыра.
Вакыт көтеп тора белми —
Гел алга атлап тора.

Ялынсак та, китә вакыт
Киләчәккә туп-туры.
Китә ул хәлсез бабайга
Таягымны тоттырып.

Кояш көлә, нурлар уйный...
Маңгайга сырлар сызып,
Акрын гына, тып-тын гына
Вакытлар бара узып.

Гомер уза. Авыз ачып
Калабыз без еш кына:
Вакыт, алтын кош шикелле,
Кулыбыздан ычкына.

Абдиразак Сәетҗанов

каракалпакчадан

Кем буласыз?

— Син үскәчтен кем буласың? —

Дип сорыйбыз Ыкластан.

— Әлбәттә, очучы булам! —

Ди ул безгә ихластан.

Шулай дигәч, елышабыз

Ыкласның янына без.

— Самолетыңа безне дә

Утырт! — дип ялынабыз.

Сорау

Әтисе бик күпне белә.

Сорый улы аңардан:

— Укытучыбызның чәче

Ник шулкадәр агарган?

— Беләм, укытучыгызны

Һәммәгез яратасыз.

Ә шулай да ул чәчләрне

Күбрәк сез агартасыз!

Жолдас Сәетназаров

каракалпакчадан

## Яз һәм мин

Уянды яз. Уянды җир.

Дөнья язгы киемнән.

Яңа бакча утыртырга

Чыктым мин дә өемнән.

Уянды җир. Өстеннән ул

Алып атты юрганын.

Үсентеләр китердем мин,

Җимеш бирә торганын.

Язның ефәк җиле исә —

Җир инде иркен сулар.

Гөрләвекләр ага — җирне

Яшәртә торган сулар!

Беләм бит мин ул суларның

Шифаларын, җегәрен.

Шуңа күрә бакчабызга

Шул суларны җибәрдем.

Ботакларын күккә чөеп

Үрелер үсентеләр.

Яңгырны да күңел шушы

Үсенте өчен теләр!

Мин әлеге яшәешнең

Тылсымнарын аз беләм.

Шулай да гөлләр үстерәм

Теләктәшем яз белән!

Агачларда, гөлләрдә мин

Иксез-чиксез көч күрәм.

Шуңа күрә мин аларны

Кешеләргә үстерәм!

Юрий Семендер

чуашчадан

Яңгыр явар алдыннан

Түшәлде түшәм булып

Күктәге күпме болыт!

Күктә әллә нишлиләр,

Тик үзләре нишләптер

Егылып та төшмиләр.

Дөбер-дөбер

Дөберди —

Бөтен дөнья

Дерелди.

Түшәм ишелер кебек,

Түшәм тишелер кебек.

Ул түшәмдә, мөгаен,

Мичкә тәгәрәтәләр.

Мичкәләре авырдыр —

Көчкә тәгәрәтәләр.

Мичкәләре аларның

Яңгыр белән тулгандыр.

Яңгыр шул мичкәләрдән

Безгә ява торгандыр.

Анатолий Тимиркаев

маричадан

Галимнәр

— Беләсеңме, әнием,

Үскәч без кем булабыз?

Компьютер белән генә

Без дәрес уздырабыз!

Галим булырга уйлый

Классыбыз бөтен килеш.

Киләчәктә һәр кеше

Галим булырга тиеш!

— Булыр, булыр, шуны да

Белмибезме әллә без?

Тик сыерны кем савар,

Галим булгач һәммәгез?!

— Сөтсез тормабыз, әни,

Кемнәр генә булсак та.

Галимнәр генә савар

Сыерларны ул чакта!

Сөзгәк җил

Болытларга ук тигәннәр

Болыннарда кибәннәр.

Аларны безнең абыйлар

Шулай биек өйгәннәр.

Тик җил чыкты да аларга

Әй бәйләнә башлады.

Җил, ахры, белми торгандыр

Бәйләнүдән башканы.

Кибәннәрне тузгытты җил,

Җилтерәтте, туздырды.

Ул сөзәк җил әй тузынды —

Үгезне дә уздырды.

Куркак куян

Күз дә иярми куянга —

Әй чаба, әй сыздыра.

Ә озын колакларында

Усал җилләр сызгыра.

Чаба куян армый-талмый,

Җил дә калмый куяннан.

Ничек кенә тырышса да,

Кача алмый ул аннан.

Калтырана куян мескен

Салкын җил кочагында.

Ачы җил ач бүредән дә

Усал шул кайчагында.

Якшәмбе көн балыкта

Әле иртә, хәтта көн дә

Уйламый яктырырга.

Энем белән төшеп киттек

Без балык каптырырга.

И каптырдык, и каптырдык,

И утырдык шым гына...

Бер балык та каптыралмый

Кайтып киттек соң гына.

Болытлы иде көне дә,

Начар иде җиме дә.

Җитмәсә, көн буе исте

Салкын, усал җиле дә.

Балыксызы туры килде

Бүген таллыкларның да.

Ял көннәре булды бугай

Бүген балыкларның да.

Каюм Тәңрекулиев

төрекмәнчәдән

«Эшчән» Гельды

Гельды, сызганып җиңнәрен,

Таңнан эшкә кереште.

Болай булса, әнисенә

Калдырмас ул бер эшне...

Уйлады ул иң беренче
Дәресен хәстәрләргә.
Өйгә эшен эшлим диеп
Тотынды дәфтәрләргә.

Тик язмады, дәфтәренә
Күпме генә бакса да.
Шуннан торды да тиз генә
Чыгып чапты бакчага.

Баскан икән чүп үләне —
Вакыт түтәл утарга.
Утар иде, бәрәннәргә
Печән беткән утарда.

Капчыгын алып, ялт кына
Юнәлде ул аланга.
Тик уйлады: «Шәп буласы
Тәмләп ашап алганда!»

Үзе, никтер, балта алып
Китте утын ярырга.
Һәм шунда ук исәпләде
Бераз уйнап алырга.

Уйнарга уйлаган Гельды
Ташлады да утынны,
Ватылган велосипедын
Төзәтергә тотынды.

Ә тотынгач, хәтерләде:
Эшләнмәгән дәресе.
Әнә шулай ярты юлда
Калды аның һәр эше.

Тырышса да күпме генә,
Гельды эштән уңмады.
Ни генә эшләмәде бит,
Ә мактаучы булмады.

Михаил Яснов

русчадан

Вожатый Света

Дәрестән соң калып көтә

Света беренчеләрне,

Өйләренә алып китә

Света беренчеләрне...

Һәм өйдә уен башлана.

Нинди уен дисеңме?

Ә ул уенның исеме

«Җыештыру» исемле!

Чиләк ала Илюша!

Чүпрәк ала Валюша!

Җиң сызгана Варюша!

Су китерә Маруся!

Һәркемгә эш табыла:

Келәмнәр дә кагыла.

Савыт-саба юыла,

Юып тезеп куела.

Бер, ике, өч дигәндә,

Себерелә идән дә.

Өйнең эче ялт итә.

Светабыз... ял итә!

Әнисе кайтып керә,
Әнисе кайтып күрә:

Аптырашта калырлык!
Өйне түгел танырлык!

Әнисе әй шатлана,
Күршеләргә мактана:
«Вожатый булгач, кызым
Ярдәм итә көнозын.

Юа бөтен төшләрне,
Эшли бөтен эшләрне,
Тыңлый әйткән сүзләрне —
Кызым бик нык үзгәрде.

Минем кызым-тырышым
Менә бит нинди кеше!
Шулай шул ул, шулай шул
Авторитетның көче!..»

Ә кызы... әзерләгән дә
Чүпрәген һәм чиләген,
Дәрес бетүгә бүген дә
Көтә ярдәмчеләрен.

Кухняда. Әнигә булышканда

— Әйдәле, ит, турагычка!

Әйдәле, ит турагычка!

Туп-туры кит турагычка!

Туп-туры җит турагычка!

Туп-туры... марш!

— Әй, кем килә?

— Фарш!

Сөт теше

Сөйләшмим берсе белән,

Әйтерсең мин чит кеше:

Селкенә дә селкенә

Минем соңгы сөт теше.

Тупасландым, үзгәрдем.

Бу, ахрысы, сөт эше.

Селкенә дә селкенә

Минем соңгы сөт теше.

Ашый алмыйм сөт ашын.

Сезгә мәзәк, көлке дә,

Минем соңгы сөт тешем

Селкенә дә селкенә.

Ачылмый авызым да,

Чыкмый хәтта сүзем дә.

Селкенгән сөт тешемне

Селкетешәм үзем дә!

Ур-ра! Тәки төште бит!

Ни дишәң дә, көшле бит!

Төште, төште шөт теше —

Мин дә хәжер жур кеше!

Мозаффар Әлимбаев

казакъчадан

Рәхмәт

Ашап туйгач тәмләп,

Тәмлетамак Әхмәт

Кабатлый туктаусыз:

— Рәхмәт!

Рәхмәт!

Рәхмәт!

Ватылган әйберсен

Бирсәң аңа рәтләп,

Сибә генә Әхмәт:

— Рәхмәт!

Рәхмәт!

Рәхмәт!

Израп йоклый Әхмәт.

Рәхәт аңа, рәхәт.

Төштә дә кабатлый:

— Рәхмәт!
Рәхмәт!
Рәхмәт!

Шул сүзе белән ул
Тутыра бүлмәне.
Рәхмәт!
Рәхмәт!
Рәхмәт! —
Аның бар белгәне.

Көләләр малайлар.
Ни булган Әхмәткә?
Булмаган! Бары тик
Әйләнгән Рәхмәткә!

## Бәләкәй көчек

Бәләкәй генә
Соры бер көчек
Үз оясында

Утыра өшеп.

Чатнама суык!

Буран котыра!

Түзәрлек түгел!

Ә ул утыра.

Чапса, уйнаса,

Курыкмас кыштан.

Тик утырырга

Аңа кем кушкан?

Салават күпере

Тылсымлы, бизәкле ул!

Аның җиде төсен дә

Карыйсы килә алып

Менә шуның өчен дә.

Балкый җиде төсе дә

Ерактан ук күренеп.

Җидесе дә бик матур!

Эх, алырга үрелеп.

Чагылдыра күзләрне,

Югарыга бак кына.

Алыр идем үрелеп —

Буем җитми чак кына.

## Бер кадак

Бата язган зур бер кораб, —

Үзе яңа төзелгән.

Батмас иде дә, корабның

Бер кадагы өзелгән!

Авып төшкән бер урындык,

Яраксыз ул бүгеннән.

Булмас иде дә яраксыз,

Бер кадагы бөгелгән!

Өр-яңа бер күн итекнең

Төшеп калган табаны.

Төшмәс иде дә, табанның

Югалган бер кадагы.

Менә сиңа

Бер кадак! —

Бер кадаксыз

Эш харап!

**Баш мөхәррир сүзе**

**(«Яшь ленинчы» һәм «Сабантуй битләреннән»)**

Һәрбер өйгә килсен!

Белеп торам, сез барыгыз да «Яшь ленинчы»ны яратасыз, аның һәр санын көтеп аласыз, кызыксынып укып барасыз, аның белән киңәшәсез, кайвакытларда аннан ярдәм сораган чакларыгыз да буладыр. Якын дустыңны гына шулай көтеп аласың, газиз дустың белән генә шулай киңәш-табыш итәсең. Ә «Яшь ленинчы» нәкъ менә шундый дустыгыз. Ул сезнең генә түгел, әти-әниләрегезнең дә, хәтта әби-бабаларыгызның да дусты булган. Юри генә сорап карагыз әле, алар «Яшь ленинчы»ның элек ничек чыгуын, анда нинди хәбәрләр басылуын искә төшерерләр, аны ничек яратып укулары турында сөйләрләр. Сандык төпләрендә газетаның кайбер нөсхәләре дә сакланып калгандыр әле.

Чыннан да, «Яшь ленинчы»ны сез генә түгел, өлкәннәр дә ярата. Газетабызны ел саен алдырып баручы абый-апаларны, әби-бабайларны да очратканым бар минем. Балалар дөньясы белән алар да кызыксына. Үзләренең балачакларын эзлиләр алар «Яшь ленинчы»дан. Ә

менә сезнең арада, белүебезчә, безнең газетаны бөтенләй алдырмаучылар да бар икән әле. Бик кызганыч, билгеле. Күпме яңалыктан, кызыклы хәлләрдән мәхрүм булалар. Татарстандагы, күрше республикалардагы яшьтәшләренең нинди хыяллар белән яшәүләрен белми калалар. Гомумән, өйләрендә газета-журнал, китап булмаган балаларны бик җәллим мин. Газета-журналлар, төрле китаплар, шул исәптән, «Яшь ленинчы» да, һәрбер балалы өйдә булырга тиеш! Ул бала мәктәпкә йөриме әле, юкмы — барыбер. Чөнки «Яшь ленинчы» сезнең кечкенә туганнарыгызны да елаганда юата, көлдерә белә, матур итеп җырлый да белә, алар белән саф татарча сөйләшә дә белә.

Кайбер 8–10 класс укучылары да ни өчендер, без инде зурлар дип, «Яшь ленинчы»га теләмичә генә язылалар икән. Алар ялгышалар, әлбәттә. Безнең газета — мәктәп балаларыныкы. Яшүсмерләр тормышыннан мәкаләләрне, шигырь-хикәяләрне без моннан соң да еш биреп барачакбыз. Иң күренекле шагыйрьләребез, язучыларыбыз безгә үзләренең яңа әсәрләрен тәкъдим итәләр. Кемнәр соң алар, дисезме? Әлегә әйтми торабыз. Яңа елның беренче саныннан ук белерсез сез аларны. Туган тел дәресләре, икмәк турында сәхифәләр, сәнгать дөньясына сәяхәтләр дә оештырырга җыенабыз. Бөек Октябрьнең 70 еллыгын бәйрәм итәргә әзерләнгәндә, илебезнең данлы тарихыннан кызыклы әсәрләр дә көтә сезне, дуслар. Үзегезнең ниндирәк мәкаләләр, әсәрләр укыйсыгыз килә, нинди темалар кызыксындыра? Газета битләрендә нинди күренекле кешеләр белән очрашыр идегез? Хат языгыз. Сезнең теләкләрне, киңәшләрне, һичшиксез, искә алачакбыз. Чөнки «Яшь ленинчы» сезнең үз газетагыз!

30 август, 1986

Бәхетле бул, сабый!

Әле берничә көн элек кенә мин Мәскәүдән кайттым. В.И.Ленин исемендәге Совет балалар фондының оештыру конференциясеннән. Без анда профсоюзларның өлкә советы председателе, Социалистик Хезмәт Герое, КПСС Үзәк Комитеты члены Г.С.Баштанюк, «Камгэсэнергострой»ның маляр-штукатурлар бригадиры, РСФСР Верховный Советы депутаты Ю.С.Барсукова һәм Казаннан ат белән йөк ташучы Ә.Г.Галимҗанов белән дүртәү - катнаштык.

Кайберәүләр еш кына үпкәләргә, кимсенергә, мескенләнергә ярата. Берәүләр кроссовка таба алмый, кемгәдер джинсы чалбар алмыйлар, икенчеләренең «Жигули»лары юк... Кайбер малайлар-кызлар моны олы кимчелеккә саный. Матур киемне үскәч киярга дә соң түгел. Ә менә безнең арада әти-әнисез балалар, тумыштан гарип малайлар-кызлар да бар. Аларны язмыш болай да кыерсыткан, ә без ул хакта уйламыйбыз да. Ул гына да түгел, аларның ятимлекләреннән, гариплекләреннән көлүчеләр дә очрый. Янәсе, әтисез үсә. Янәсе, яклашыр кешесе юк. Янәсе, рәнҗетсәң дә ярый.

Үземнең малайчак искә төшә. Безнең урамда ятимә бер кыз бар иде. Аяклары да көчкәкөчкә генә хәрәкәтләнә. Кайбер бәләкәй малайлар, алар турыннан узып киткәндә, «аксак, аксак» дип кычкыралар да торып чабалар иде. Шуннан соң, мин ул малайлар өчен оялып, күрше кызына күренмәскә тырышып йөри идем.

Әтисез-әнисез балаларга кешелексез мөнәсәбәтне әле дә очратырга мөмкин. Күптән түгел генә сөйләделәр. Казан мәктәпләренең берсендә классташлары күзләре начар күргән бер

малайны һушыннан язганчы кыйнаганнар, аяклары белән типкәләгәннәр. Өч ай больницада яткан ул. Терелеп чыккан инде. Шул ук класста укый, шул ук кыйнаган малайлар белән бергә. Әйтерсең лә берни дә булмаган. Тегеләре аның күзенә ничек карыйлар икән?

Болары әле үзебезнең арада. Ә балалар йортлары, интернат-мәктәпләр ничек яши соң? Төрлесе бар. Начарлары да җитәрлек. Совет балалар фонды адресына бик күп хатлар килә.

«11 нче балалар йортында (Мәскәү) балаларга карата антипедагогик чаралар кулланыла. Тәрбияче Фомичева балаларны төнгә кадәр кер киптерү шкафына ябып тота. Балаларны сикергечләр белән кыйнау, башларына, табаннарына чыбык белән сугу очраклары булды. Балаларны ашатмыйча тоталар...» (Г.И.Рассадина хатыннан).

«Безнең туган йортыбыз «концлагерьга» әйләнде. Балаларны кыйныйлар. Ашамлыкларны урлыйлар, аннары милициядә учетта торган малайларга сылтыйлар. Мөмкин булса, коткарыгыз интернатны!» (Майский шәһәрендәге 6 нчы интернат-мәктәп турында Л.Г.Мамхегова хатыннан).

«Балалар кыш көннәрендә дә яланбаш, ертык ботинкадан. Өлкән тәрбияче Жугарова балаларны кыйный, сүгенә... Балалар кача, җинаять эшли. Җәйге лагерьдагы шартлар — коточкыч, павильон — элекке ат абзары, төнлә салкын, эчәргә су юк. Үлем очрагын яшереп калырга тырыштылар. Лагерьда врач та, дару да юк» (Ташкенттагы 105 нче ярдәмче интернат-мәктәп хезмәткәрләре хатыннан).

Кызганычка каршы, менә шундый авыр шартларда яшәүче ятим балалар да бар әле. Туган өй җылысыннан, әти-әни тәрбиясеннән мәхрүм малайлар-кызлар. 300 меңгә җыела бездә андый балалар. Иң элек шул ятимнәрнең язмышын җиңеләйтү өчен төзелде дә инде Совет балалар фонды. Ә фондның 707 нче счеты миңа ярдәмгә чакыручы SOS сигналын хәтерләтә. Ятимнәргә ярдәм кирәк! Ашыгыч ярдәм!

Конференциягә гомерләрен балалар тәрбияләүгә багышлаган, ятимнәргә ярдәм кулы сузарга һәрвакыт әзер торучы кешеләр җыелган иде. Шуларның иң күренеклесе, мөгаен, безнең якташыбыз Әсхәт абый Галимҗанов булгандыр. Ул С.Михалков, В.Терешкова, Ш.Амонашвили, Ю.Власов, Р.Паулс, Е.Чазов, С.Образцов кебек атаклы кешеләр белән бергә президиумның беренче рәтендә утырды. Докладчы Альберт Лихановны Ә.Галимҗанов турында сөйләгәндә залда утыручылар биш тапкыр кул чабып бүлдерделәр. Юри санап бардым. Соңыннан кемнәр генә кулын кысмады да, кемнәр генә килеп рәхмәт әйтмәде Әсхәт абыйга. Генерал-полковник Д.А.Волкогоновның килеп кочаклап алуы, аталарча рәхмәт әйтүе аеруча дулкынландыргыч булды. Рәхмәт әйтмәслек тә түгел шул. Әсхәт абый Балалар фондын моннан ун еллар элек үк үзе оештырып җибәргән иде инде. Хәләл көче белән эшләп тапкан меңләгән сум акчаны ничә еллар буе балалар йортына күчерә ул. Намусы кушканга, балаларны яратканга! Конференция делегатлары якташыбызның гражданлык батырлыгын югары бәяләделәр. Совет балалар фонды идарәсе членнары арасында язучылар, министрлар, академиклар, космонавтлар, Геройлар белән бергә ат белән йөк ташучы Әсхәт Галимҗанов та бар. Ул Мәскәүдән олы хыяллар белән кайтты. «Кайткач та Казан мех комбинатына 4 мең сум акча күчерәм», — диде. Ятим балаларга 60 тун тектерергә. Шулай да бер үкенече калды аның. «Ленин бабайны гына күреп булмады. Бик күрәсе килгән иде», — диде авыр сулап.

Конференциядә тагын бер якташыбыз телгә алынды. Академик Роальд Зиннурович Сәгъдиев Америкада үзенә бирелгән премиягә компьютерлар сатып алып яшь космонавтлар клубына бүләк иткән.

Ә Татарстан язучылары балалар йортына китаплар алыр өчен 1000 сум акча җыярга булдылар. Редакциягә балалар шагыйрәсе Мәрзия Фәйзуллина шалтыратты. Быел чыга торган балалар китабының бөтен гонорарын балалар фондына күчерергә тели. Шагыйрь Әхмәт Рәшитов Буадагы балалар йортына тапшыру өчен үзенең шәхси китапханәсеннән 100 данә китап әзерләп куйган. Совет балалар фондының бүгенге көндә 125 миллионнан күбрәк акчасы бар.

Безнең укучылар үзләре дә бу изге эштән читтә калмаслар дип уйлыйм. Алар болай да ярдәмгә ашыгырга гына торалар. Әле 1943 елда ук Татарстан комсомоллары һәм пионерлары матур башлангыч белән чыкканнар — фашистлардан җәфа күргән балаларга ярдәм фонды оештырганнар. Кыска вакыт эчендә фондка 300 мең сум акча һәм 12 мең төрле әйберләр җыела. 30 мең сум акча балалар ашханәләренә җибәрелә. Бүгенге пионерлар да, Тынычлык фондына булсын, Чернобыльдәге, Грузиядәге фаҗигаләр уңаеннан булсын, үзләре эшләп алган акчаларын берчакта да кызганмыйлар. Гомумән, пионер оешмасы Балалар фонды белән тыгыз элемтәдә торырга, бергә-бергә эшләргә тиеш. Чөнки алар икесе дә — балаларның үзләре өчен, икесе дә — В.И.Ленин исемендә.

Минем бер теләгем бар — балалар тирә-якларына игътибар беләнрәк карасыннар әле. Кемдер әбисе-бабасы белән яши. Үги әни, үги әти белән яшәүчеләр дә бар. Кайберәүләрнең әти-әниләре эчкече...

Аларга да ярдәм кирәктер. Алар да бер җылы сүзгә, бер җылы карашка мохтаҗдыр. Аларның да матур киенәселәре, тәмле ашыйсылары киләдер. Битараф булмыйк!

24 октябрь, 1987

Тынычлык балачактан башлана

«Без үз илебезнең рухыннан да, Америка халкы рухыннан да шуны күрәбез: алар — яхшы якка үзгәрү ягында. Алар инде үзләре эш итә башладылар, үзара элемтәләр урнаштыралар, аның төрле формаларын һәм ысулларын эзлиләр, гаҗәеп дәрәҗәдә осталык күрсәтәләр, балалар да, өлкәннәр дә конфронтациянең соңгы битләрен ябу, яңа этапны ачу өчен вакыт җитүен аңлыйлар».

М.С.Горбачев

Кешелек җиңел сулап куйды.

Дөнья җылынып киткәндәй булды.

Миллионнарның күз аллары ялтырып китте.

Сугыш коралларының туктаусыз артуыннан авырайган, менә-менә шартларга торган Җир шары, ничә еллар инде киеренкелектә яшәгән илләр һәм халыклар, өлкәннәр һәм сабыйлар ышаныч белән киләчәккә төбәлделәр.

Кешелек белән табигать арасында охшашлык, уртаклык, гармония бар, диләр, дөрес икән. КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре М.С.Горбачевның Вашингтонга визиты ва-

кытында көннәр кинәт кенә җылынып китте. Термометрлардагы нуль тирәсендә тирбәлгән терекөмеш өскә — 20 градуска сикерде. Озак еллар көтеп алынган җылылык иде бу. Илләр, кешеләр арасындагы җылылык, үзара мөнәсәбәтләр җылылыгы табигатькә — әйләнә-тирәгә дә күчте. Ниндидер символик мәгънә бар монда.

Ул көннәрдә без барыбыз да визит рухы белән яшәдек. Миллионнарча карашлар телевизор экраннарына текәлде. Өмет тулы күзләр телевизион тапшыруларны дулкынланып көтте. М.С.Горбачев белән Р.Рейган Договорга кул куйган чакны тыныч күңел белән генә караучы булды микән? Кешелекнең киләчәген хәл иткән тарихи акт, бөек мизгел иде ул.

М.С.Горбачевның чыгышларын тыңлаганнан соң мин үзем өчен мөһим бер ачыш ясадым. Партиябез җитәкчесе визит барышында еш кына яшьләргә һәм балаларга мөрәҗәгать итте, тынычлык өчен көрәш турында сүз барганда балаларны олылардан аерып карамады. АКШ һәм Советлар Союзы яшьләре арасындагы элемтәләрне киңәйтү өчен көрәшүче «Турыдан-туры элемтәләр» оешмасыннан бер группа студентлар һәм укучылар белән очрашканда, М.С.Горбачев болай диде: «Тиздән Совет һәм Америка балаларының иңнәренә үз илләренең мәшәкатьләре төшәчәк. Моңа әзер булырга кирәк. Сез — партнерлар, сез тынычлыкта һәм дуслыкта яши аласыз. Һәм яшәргә тиешсез дә. Мин халыкларыбызның һәм яшьләрнең бер-берсенә дошман булуына ышанмыйм. Әгәр нәрсә дә булса бар икән, ул фәкать информация җитмәүдән яисә бер-беребезне белмәүдән генә. Минем белән әңгәмәләр вакытында президент Рейган яшьләребезнең бер-берсе белән элемтәләрен ныгыту идеясен хуплады. Без кул куйган йомгаклау документында Совет һәм Америка халыклары, бигрәк тә яшьләр арасындагы элемтәләрне киңәйтү турында да сүз бара... Ишекне кем ныграк кага, аны шуңа ачалар».

Мин бу юлларны тыңлаганда балалар арасыннан иң беренче булып безнең илнең ишеген шакыган Саманта Смитны күз алдына китердем. Тынычлык илчесе иде бит Американың бу гүзәл кызы. Аңа алмашка Мәскәү кызы Катя Лычева басты. Саманта белән Катя кабызган дуслык факелын башка малайлар-кызлар күтәреп алды. Алар да тынычлык өчен көрәшә. Безнең укучылар да, Америкада яшәүче балалар да. Тынычлык барыбызга да кирәк. Ә Вашингтондагы очрашуга бөтен кешелек әзерләнде. Һәркем үзенчә. Шул исәптән балалар да. АКШның башкаласында, мәсәлән, ФРГдагы «Тынычлык кошы» исемле оешма инициативасы белән, тынычлык өчен көрәшүче балаларның беренче конференциясе узды. 5 декабрь көнне Ак йорт каршында балалар өлкәннәр белән бергәләп митинг үткәрделәр. Урта һәм кыска ераклыкка оча торган ракеталарны бетерү турындагы Договорны яклауларын белдерделәр. Бер төркем төрле милләт балалары роза чәчәкләре тотып Совет илчелеге урнашкан йортка килделәр. Аларны анда җаваплы Совет дипломаты кабул итте. Ул балаларны тәмле ризыклар белән сыйлады, аларның теләкләрен — Совет лидеры белән очрашу оештыру турындагы үтенечләрен тыңлады. Ә шул ук вакытта шундый ук миссия белән Ак йортка киткән балалар төркемен бөтенләй башкача каршылыйлар. Дөресрәге, аларны капкадан да кертмиләр, чәчәкләрен дә алмыйлар. Балалар чәчәкләрне сакчы будкасына куеп китәләр. Әмма бераздан дворник килә дә аларны чүп савытына ташлый... Соңыннан Ак йорт вәкиленә барыбер гафу үтенергә туры килә.

Шушы көннәрдә безнең илдә дә Тынычлыкны яклау комитеты янында «Дөнья балаларына — тынычлык» ассоциациясе оештырылды. Аның төп максаты — балаларны тынычлык өчен көрәшчеләр итеп тәрбияләү. Балаларның тынычлык өчен көрәше дәвам итә. Безнең редакциягә дә мәктәпләрдә тынычлык ярминкәләре үткәрүләре, Тынычлык фондына акча күчерүләре турында укучылардан хатлар килә тора. «Тынычлык китабы»ның яңа сәхифәләре языла.

М.С.Горбачевның Совет илчелегендә ясаган чыгышы да күңелгә уелып калган. Ул анда өлкәннәргә дә сабак булырлык бер мисал китерде: «Юлга чыгар алдыннан миңа быел бездә булган Америка балалары чыгарган «Күпер» исемле яшьләр газетасын күрсәттеләр. Мәскәү укучылары белән бергәләп алар Мәскәүдән ерак түгел борынгы рус шәһәрчеге Переславль-Залесскийда дуслык лагере оештырганнар.

Алар нәрсәгә сәләтле — барысы белән дә шөгыльләнгәннәр: компьютер һәм телекоммуникация, спорт һәм музыка, рус һәм инглиз телләре, уеннар һәм экскурсияләр... Һәм менә хәзер Америка балалары үзләренең тәэсирләре турында язалар.

Сезнең арадан кем дә булса ул газетаны кулларына тотып карагандыр дип уйламыйм. Ә ул иң җитди игътибарга лаек. Ул — мөһим вакыйга. Ул — кешеләр мөнәсәбәте мәктәбе. Безгә, өлкәннәргә, үзебезнең балалардан өйрәнергә кирәк. Балалар безгә хорафатлардан, тискәре мөнәсәбәтләрдән, эчпошыргыч стереотиплардан ничек итеп арынырга кирәклеген күрсәтәләр...»

Бу — киләчәк турында уйлап әйтелгән сүзләр, бу — балаларга карата ихтирам һәм ышаныч дигән сүз. Ә ышанычны акларга, ничек булса да акларга кирәк!

Мин тагын бер тапкыр шуңа ышандым: тынычлык балачактан, балалардан башлана. Әгәр дә илебезнең, җиребезнең киләчәге тыныч булсын дисәк, киләчәктә дә тыныч, бәхетле Җир шарында яшисебез килә икән, без тынычлыкны яклап бүгеннән үк көрәшергә тиешбез. Ләкин аерым-аерым түгел, ә бергәләп: күрше малайлары-кызлары белән дә, чит республикалардагы, чит илләрдәге балалар белән дә бергәләшеп, кулга-кул тотышып! Бөтендөнья балалары бергә булганда гына, дус һәм тату булганда гына Җир шарының киләчәге тыныч булачак.

Әйе, тынычлык өчен көрәшнең яңа этабы башланды. Ул көрәштә өлкәннәр дә, балалар да бер сафта!

19 декабрь, 1987

Игелекләр эшләп калыйк!

Кадерле укучылар!

Сезнең ятим яшьтәшләрегез турында уйланганыгыз бармы? Аларның язмышлары, тормышлары кызыксындырамы сезне? Аларның кайларда, нинди шартларда яшәүләрен беләсезме? Аларга ярдәм иткәнегез бармы? Булмаса, ярдәм кулыгызны сузарга җыенасызмы?

Ә бит ятим балалар саны безнең республикада меңнәр белән исәпләнә. Ярдәмгә мохтаҗ яшьтәшләрегез бәбиләр һәм балалар йортларында, интернат-мәктәпләрдә яши. Бик күпләре әби-бабаларында тәрбияләнә. Дөрес, аларны ашаталар, киендерәләр, укыталар. Хәтта киноларга, экскурсияләргә дә баргалыйлар... Ләкин аларның сөяргә, назларга әти-әниләре юк, кайтып керергә өйләре юк, гаиләләре юк. «Әти, әни» диюдән, «туган өем» диюдән мәхрүм алар. Әнисе пешергән ашны ашый алмый, әтисе алып кайткан күлмәкне кия алмый алар. Команда белән торалар, тезелешеп ашарга баралар... Сабый чаклары урланган, сабый чаксыз калган балалар алар.

Шуңа күрә дә В.И.Ленин исемендәге Совет балалар фонды ятимнәрнең тормышларын яхшырту өчен бөтенесен дә эшләргә тырыша. Шундый игелекле эшләрнең берсе — гаилә тибындагы балалар йортлары төзү. Бу хакта хөкүмәтебезнең карары булды инде. Алдагы берничә елда илебездә 30 балалар шәһәрчеге төзеләчәк. Шуларның берсе — безнең Чаллыда. Әлеге шәһәрчекләр берәр гаиләлек күп бүлмәле аерым йортлардан-коттеджлардан тора. Анда ата-ана, үз балалары белән бергә, тәрбиягә алган ятимнәрне да тәрбияләячәк. Ятимнәрнең, нигездә, бертуганнар яисә төрле яшьтәге малайлар һәм кызлар булуы шарт. Тәрбияче ата-аналарга хезмәт хакы түләнә. Ятимнәрне тәрбияләү өчен акчалата ярдәм күрсәтелә. Ата-аналар балаларны үзләре теләгәнчә киендерәләр, ашаталар. Балалар гадәти гаиләләрдә ничек тәрбияләнсә, биредә дә шулай тәрбияләнәчәк. 200 балага исәпләнгән шәһәрчектә урта мәктәп, балалар бакчасы, сәламәтлек комплексы, йөзү бассейны, яшелчә, җиләк-җимеш бакчасы да булачак. Кыскасы, ата-ана назыннан мәхрүм калган балалар биредә үзләрен өйләрендә, әти-әниләре янында итеп хис итәрләр дип өметләнәбез.

Мондый шәһәрчекләр, билгеле, кыйммәткә төшә, күп чыгымнар сорый. Шуны истә тотып, Совет балалар фонды 1, 3, 5, 10 һәм 25 сумлык билетлар чыгарды. Русча ул «Благотворительный билет» дип атала. Моңа кадәр андый билетларның бер дә чыгарылганы булмагач, татарча ничек әйтелгәнен дә белмим. Мөгаен, «Матди ярдәм билетлары» яки «Шәфкать билетлары» дип атаргадыр аларны. Аннан килгән акча фәкать гаилә тибындагы балалар йортларына һәм анда яшәүче ятимнәрне тәрбияләүгә генә тотылачак.

Күңелендә шәфкатьлелек хисләре булган игелекле җанлы һәркем сатып алырга мөмкин әлеге билетларны. Ятимлек газапларын бәләкәйдән татыган яшьтәшләрегезгә зур ярдәм булыр иде ул. Билетлар, сезнең шәфкатьле йөрәкле, ярдәмчел, киң күңелле кешеләр икәнегезне искә төшереп, гаиләгездә кадерле бер ядкарь булып озак еллар сакланыр.

11 февраль, 1989

Шәфкатьле кешеләр кирәк!

Һәрберебезнең бәхетле буласы килә. Синең дә, минем дә, аның да... Ләкин бәхетне һәркем үзенчә аңлый. Кайчагында яңа күлмәк тә — бәхет. «Бишле» дә — бәхет. Матур китап сатып алсаң да — бәхет. Ә минемчә, иң олы бәхет — сау-сәламәт булу, әти-әниле булу. Шуннан да олырак бәхетне мин күз алдына да китерә алмыйм. Кызганычыбызга каршы, без күбрәк үзебез турында гына кайгыртабыз, үз бәхетебез хакында гына уйлыйбыз. Бу — табигый халәттер, мөгаен. Әмма әйләнә-тирәбезгә игътибар белөнрәк карагыз әле. Барыбыз да бәхетле микән? Юк шул, юк! Бәхет дигәннәре һәркемгә дә тигез бирелмәгән.

Кемнеңдер физик кимчелеге бар — күзлек кия, начар ишетә, чатанлап йөри. Андыйлардан мыскыллап көлү безнең өчен берни түгел. «Сукыр», «чукрак», «аксак» дигән кушаматларны тагарга гына торабыз. Аларны бер җиргә дә ияртмибез, үзебез белән уйнатмыйбыз. Андый малайлар-кызлар акрынлап башкалардан читләшә, ерагая, үз-үзенә бикләнә, олы дөньядан аерыла.

Кемнедер әтисе ташлап киткән, әнисе белән генә яши. Әтисез үсүнең ни икәнен бик яхшы беләм мин. Җае чыккан саен кимсетергә генә торалар. Олырак, усалрак малайлар кыйнап китәргә дә күп сорап тормыйлар. Мыскылларга да, үчекләргә дә ярый ятимнәрне. Якларга барыбер әтиләре юк, янәсе. Әтисез үскән малайларның да, кызларның да матур итеп киенәселәре, тәмле итеп ашыйсылары килә. Ләкин бер әнинең хезмәт хакына гына әллә ни майтарып булмый шул. Шулай да әни белән үсү бик тә ярый әле ул. Иң кыен чакларда аңа килеп сыенасың, эч серләреңне аңа сөйлисең. Әтиле малайлар-кызлар кигәнне үскәчтен дә киеп булыр анысы...

Ә менә сезнең сабыйлар йорты (дом ребенка) турында ишеткәнегез бармы? Татарстанда да күп алар. Әти-әнисез балалар тәрбияләнә анда. Хәер, әти-әнисез дию бик үк дөрес тә булмас... Ничек килеп эләгә соң алар сабыйлар йортына? Һәр бала үзенчә, һәр баланың үз язмышы. Кайсыныңдыр, чыннан да, әти-әнисе үлгән, тома ятим калган. Икенчеләренең әти-әнисе ата-ана булу хокукыннан мәхрүм ителгән. Өченчеләренең әти-әнисе эчкече. Дүртенчеләрен әнисе бала табу йортында ук ташлап калдырган. Ул сабыйларның кайберләрен ишек, капка төбендә калдырып киткәннәр. Чүплеккә ташлап калдырылган сабыйлар да очрый хәтта. Әле дә ярый аларны изге күңелле кешеләр табып ала, сабыйлар йортына илтеп тапшыра. Болар хакында минем бер дә язасым килми. Әмма нишлим соң? Без болар хакында белергә тиешбез. Алар бит иң олы бәхеттән — гаилә бәхетеннән мәхрүмнәр. Аларның да телләре «әннә, әттә» дип ачыладыр, ләкин алар «әни, әти» дигән сүзләрне кемгә әйтергә кирәген дә белмиләр. «Әни» алар өчен няня, тәрбияче, медсестра... Алар әниләре ясаган хуш исле чәйнең дә, тәмле-тәмле өчпочмакларның да, бәлеш-гөбәдияләрнең дә нәрсә икәнен белмиләр.

Ләкин балалар йортларының да төрлесе бар, аларда да төрле балалар тәрбияләнә. Берсендә — сәламәт балалар, икенчесендә — акылга зәгыйфь балалар, өченчесендә — тумыштан гарип балалар. Соңгыларының нинди бәхетсез икәнлекләрен күз алдына китерә аласыз микән? Әти-әниләре дә юк, сәламәтлекләре дә. Берәүләре сөйләшә алмый, икенчеләре бөтенләй күрми, ишетми, өченчеләре урыннарыннан да кузгала алмый. Һәрберсенең үз фаҗигасе, үз бәхетсезлеге, үз газабы. Аларның күбесе гомерлеккә шул таш диварлар арасында яшәргә хөкем ителгән. Алар яшел болыннарда сезнең кебек күбәләкләр куып, чәчәкләрдән такыялар үреп йөрүдән мәхрүм. Кар, яңгыр яуганны да алар тәрәзәдән генә күрә алалар. Ләкин яңгырга учыңны куеп тормагач, карны үзең тотып карамагач, шул карда ятып аунамагач, аларның матурлыгын каян беләсең ди. Ул балаларның күбесе туп-туры итеп

атлап йөрүне дә, бер-берсе белән сөйләшүне-көлешүне дә, зәп-зәңгәр күктәге болытларга карап соклануны да олы бәхеткә санарлар иде. Кызганыч, ул сабыйлар андый хисләрне кичерә алмыйлар. Аларның сезнең кебек малайлар-кызлар белән дә аралашырга мөмкинлекләре юк. Алар яшәгән бүлмәләрдә фәкать үзләре кебек үк ятимнәр, үзләре кебек үк гариплар, үзләре кебек үк кимсетелгәннәр генә. Ә бит алар да — кеше, алар да бәхетле булыр өчен туган булганнар.

Миңа андый балалар янында еш булырга туры килә. Бүлмәләренә килеп керүгә сиңа тартылалар, килеп сарылалар, чөнки аларның ир-атларны бөтенләй диярлек күргәннәре юк. Нинди генә авыру балалар юк икән бу дөньяда. Алар атналар буена минем күз алдымнан китми, төшләремә керә. Менә шунда инде ул балаларны тудырган ата-аналарны уйлыйсың. Аларның күбесенең бер гаепләре дә юктыр, ышанам. Шуңа күрә аларны да кызганасың. Әмма эчкече, алкоголик ата-аналардан туган балалар да күп бит анда. Әниләре бер сәбәпсез ваз кичкән сабыйлар да үсә бит ул йортларда.

Их, өлкәннәр, өлкәннәр! Шушы да булдымы кешелеклелек, шәфкатьлелек?! Шушы да булдымы киләчәк алдындагы җаваплылык?! Ә үзебез «балалар — безнең киләчәгебез» дигән булабыз. Әгәр дә олы җаваплылык булса, әгәр дә без балаларны чыннан да яратсак, хөрмәт итсәк, безнең Татарстанда ятим, авыру балалар тәрбияләнүче 86 махсус учреждение булмас иде. Әгәр дә без балаларыбызның киләчәге турында уйласак, дәфтәрләрне, мәктәп формаларын талонга калдырмас идек. Балалар матур бер спорт костюмы, йә булмаса, шәп бер кроссовка кияр өчен зар булып йөрмәсләр иде. Әгәр дә без балаларыбызның язмышы турында өлкәннәрчә кайгыртсак, алар өчен больницалар, санаторийлар җитәрлек булыр иде, алар йөзәрләп тә, меңәрләп тә авырмаслар иде, суга батып та, юл фаҗигаләрендә дә, янгын вакытларында да күпләп үлмәсләр иде. СПИД дигән коточкыч авыру да иң элек аларга килеп тимәс иде.

Әлеге мисаллардан гыйбрәтләр алырлык югыйсә. Ә без балаларыбызның язмышы турында әле булса олыларча кайгыртмыйбыз әле. Татар АЭСы һаман да төзелеп ята. Иң элек сабыйлар гомеренә куркыныч янамыймыни ул? Олы шәһәрләребезнең һавасын суларлык түгел. Сабыйларның сәламәтлегенә зыян китермимени бу?

Боларның барысы да илебездә балаларның бернинди дә хокуклары булмауны дәлилли торган фактлар. Сүз уңаеннан шуны да әйтим, Берләшкән Милләтләр Оешмасының Генераль Ассамблеясе күптән түгел бала хокукы турында Конвенция кабул итте. Әлеге халыкара хокукый документны БМО члennары тавыш бирмичә генә кабул иттеләр. Балалар хакына. Балаларны һәртөрле кимсетүләрдән, авырулардан, үлемнән яклау максатыннан, В.И.Ленин исемендәге Совет балалар фонды бала хокуклары турында СССР Законы проектын әзерләде. Бу изге эшкә Балалар фондының алынуы бер дә юкка гына түгел, билгеле. Нәкъ менә әлеге фонд төзелү белән балаларга, бигрәк тә ятим һәм авыру балаларга мөнәсәбәт күзгә күренеп үзгәрә башлады. Җәмгыятебез балаларның, чыннан да, киләчәгебез булуына ышана инде хәзер. Шәфкатьлелек, игелек төшенчәләре яңа төсмер алды.

Без бүгенге белән генә яшәмибез. Һәрхәлдә, яшәмәскә тиешбез. Киләчәгебез нинди булыр? Балаларга мөнәсәбәт тагын да әйбәтрәк якка үзгәрерме? Бүгенге хаталарыбыз алда да кабатланмасмы? Шәфкатьлелек хисләре күңелләребезгә яңадан да әйләнеп кайтырмы? Монысы инде сездән дә тора, кадерле дуслар. Әгәр дә сез шәфкатьле булсагыз, тирә-юнегездәге ятимнәргә, авыруларга, көчсезләргә, кечкенәләргә игътибарлырак, ихтирамлырак булсагыз, аларга ярдәм кулыгызны сузарга ашыксагыз, күпме бәхетсезлек, күпме кайгыхәсрәт кимер иде. Дөньялар тагын да яктырыбрак китәр иде. Сез үзегез дә шәфкатьле булып үсәр идегез. Ә шәфкатьле кеше балаларга игътибарсыз була алмый ул. Безгә исә нәкъ менә Шәфкатьле Кешеләр кирәк тә!

1989

Хикмәт җисемдә дә... исемдә дә

Кадерле укучыларыбыз!

Уйладым-уйладым да сезгә мөрәҗәгать итәргә булдым әле. Ни өчен дисәгез, быел безнең газетага язылу бик тә начар бара. Болай булса, малайларның-кызларның шактые «Яшь ленинчы»сыз калачак. Дөрес, «Яшь ленинчы»сыз да яшәп була. Тәмле кәнфит тә, тәти күлмәк тә түгел ул. Кайберәүләр шулай яши дә. Казан урамнарында трай тибеп йөрүче сугыш чукмарлары, билгеле инде, безнең газетаны алдырмыйлар да, укымыйлар да. Беренчедән, алар туган телләрен онытткан «телсез» малайлар-кызлар. Икенчедән, аларның бөтен кызыкканы — урам, рок, «варенка» һ.б. Авыл җирендә укымаучылар да бардыр әле безне. Нишлисең, һәркем үзенчә яши: үзе теләгәнчә, үзе белгәнчә. Ә быелгы хәлнең төп сәбәбе — газеталарның бәясе күтәрелү. Күтәрелде шул. «Яшь ленинчы»ның да бер данәсе моннан соң 1 тиен урынына 3 тиен булачак. Шулай да өлкәннәр үзләренең газиз балаларыннан шул 3 тиеннәрен дә кызганмаслар дип өметләнәм. Аннары, авыл баласы акчаны үзе дә эшләп ала бит әле.

Соңгы вакытта бик күп яңа газеталар чыга башлады, әмма аларның һәммәсе дә өлкәннәр өчен. «Яшь ленинчы» һаман да ялгызы. Кояш — берәү, җир — берәү, әти дә, әни дә — берәү, «Яшь ленинчы» да берәү генә. Шуңа күрә без сезнең белән бергә яңарырга, үзгәрергә (әйбәт якка!) тиеш булабыз. Бездәге үзгәрешләрне сез, мөгаен, үзегез дә сизәсездер. Соңгы ике елда тышкы кыяфәтебез дә нык кына үзгәрде: офсет ысулы белән басыла башладык, сыйфаты яхшырды, фоторәсемнәре ачыграк чыга, дүрт битебез дә ике төсле хәзер. Илебездәге бер генә балалар газетасы да, хәтта «Пионерская правда» да алай чыкмый. Эчтәлек тә акрынлап үзгәрә. Балалар дөньясына күбрәк урын бирәбез, «Әйбәт буласым килә», «Пәйгамбәрләр тарихы», «Утырмага килегез» исемле яңа рубрикалар ачып җибәрдек. Киләсе ел — Тәкә елы. Шуңа күрә алдагы елда безнең дә сөзгәгрәк булырга исәбебез бар. Ягъни тәнкыйть мәкаләләре, фельетоннар күбрәк басылыр. Сезне усал малайлардан, битараф өлкәннәрдән яклашырга кирәк бит инде. Мөрәҗәгатемнең икенче сәбәбе газетабызның исеменә бәйле. Хәзер үзгәрешләр заманы. Без дә, озаклап киңәшкәннән соң, «Яшь ленинчы»ның исемен үзгәртергә кирәк таптык. Укучылар дөрес аңлар дип уйлыйм, бу — бөек Ленин исеменә ихтирамсызлык түгел. Без 66 ел ул исемгә турылыклы булдык, аның исеменә тап төшермәскә тырыштык. Исемебез киләчәктә нинди генә булмасын, безнең укучыларыбыз чын мәгънәсендә яшь ленинчылар булып калыр дигән өметебез бар. Ә газетаның исеме үзенең укучыларына якынрак булырга, аларның шатлык-кайгыларын, уйтеләкләрен ныграк чагылдырырга бурычлы. Безнең укучыларыбыз — татар малайларыкызлары. Төп максатыбыз да нәкъ менә татар баласын шәфкатьле, гадел, намуслы, эшчән итеп тәрбияләү. Ул туган телен, туган халкын, туган җирен хөрмәт итүче, үз тарихын, әдәбиятын, мәдәниятен яхшы белүче, башка халыкларга да ихтирамлы татар баласы булырга тиеш.

Башка балалар газеталары исемнәрен яңарта башладылар да инде. Украин балаларының «Юный ленинец» газетасы яңа елдан «Тәнәфес» булачак, чуваш телендәге «Пионер сасси» — «Танташ»ка, ягъни «Яшьтәш»кә әйләнде. «Башкортостан пионеры» да үзенә яңа исем эзли. Безгә дә яңа исем кирәк. Минем инде уйлап куйган исемем дә бар. Берәү генә дә түгел. Икәү! Берсен безнең хезмәткәрләребез дә белә. Икенчесен әле беркемгә дә әйткәнем юк. Әмма шуны белеп торыгыз: әлегә ике исем дә шушы мәкаләгә яшеренгән. Игътибар беләнрәк укысагыз, һичшиксез табарсыз. Шулай да мин сезгә яңа исемне үзегезгә уйларга

тәкъдим итәм. Әгәр минекеннән дә матуррак, эчтәлеклерәк исем уйлап тапсагыз, газетаның исеме шул булачак. Искитмәле яңа исем көтеп калабыз. Исем туена сезне дә чакырачакбыз!

Әлеге мөрәҗәгатьне өйдә әти-әниләрегез белән, мәктәптә классташларыгыз, укытучыларыгыз белән бергәләп укырсыз, сүзләремә колак салмый калмассыз дип уйлыйм.

27 октябрь, 1990

## Безнекеләр – үзебезнекеләр

Безнең «Сабантуй» редакциясе — нәкъ кош оясы төсле. Япь-яшь кенә егетләр-кызлар киләләр дә, канат чыгарып, каләм чарлап, чын журналистлар булып, олырак, «солиднийрак» газета-журналларга очып китәләр. Редакция аларга кул болгап, хәерле юл теләп кала. Яңа яшьләр килә, аларны тагын да яшьрәкләр алмаштыра. Тормыш шулай дәвам итә. Бездә үскән, бездә чыныгу алган журналистлар белән «Сабантуй» һәрвакыт горурланып яши, аларны сагынып искә ала. Андыйлар — күп, барысы да — талантлы. Әнә безнең Венера апа Ихсанова белән Роза Туфитуллова бер-бер артлы «Сөембикә» («Азат хатын») журналының баш мөхәррирләре булдылар. Ренат Харис — «Татарстан хәбәрләре» исемле яңа газетаның баш мөхәррире хәзер. «Мәгариф» журналының баш мөхәррир урынбасары — безнең Мәҗит Вәлиуллин. Шәех Зәбиров — «Шәһри Казан» газетасының җаваплы сәркатибе. Марс Шабаев — «Казан утлары» журналында, Камил Кәримов — «Чаян»да, Фирая Бәдретдинова — «Салават күпере»ндә җаваплы сәркатип. «Социалистик Татарстан»да — Нургали Булатов... Кайда да безнекеләр, үзебезнекеләр. Мин әле монда җаваплырак урында эшләүче журналистларны гына санап киттем. Юри, бераз мактаныр өчен. Ни дисәң дә, безнең балалар газетасы тәрбияләгән журналистлар бит.

«Сабантуй»ның тагын бер үзенчәлекле ягы бар. Ул — әдипләр газетасы да. Бер генә саныбыз да язучы, шагыйрь сүзеннән башка чыкмыйдыр, мөгаен, һәр санда — шигырь, хикәя, әкият, публицистика... Шулай булмас иде дә, гомер-гомергә журналистлар булып бездә язучылар, шагыйрьләр эшләгән шул: Фатих Кәрим, Абдулла Алиш, Нури Арслан, Ләбиб Гыйльми, Галимҗан Мөхәммәтшин, Ибраһим Салахов... Аннары Марс Шабаев, Ренат Харис, Рөстәм Мингалим, Саимә Ибраһимова, Рәшит Әхмәтҗанов, Хәкимҗан Халиков, Әхәт Гаффар, Рахмай Хисмәтуллин... Соңгырак елларда Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләмов, Камил Кәримов, Хәйдәр, Нияз Акмалов, Эльмира Шәрифуллина, Ркаил Зәйдулла, Ләбиб Лерон, Сәйдә Зыялы, Вакыйф Нуриев, Фирдәвес Бәширова, Фәйрүзә Мөслимова, Илсөяр Иксанова... Әле без Шәүкәт Галиев белән Галимҗан Гыйльмановны да үзебезнеке саныйбыз. Редколлегия әгъзалары алар безнең. Күрәсез, күпме шагыйрь, күпме язучы!

Традицияләр дәвам итә. Бүген дә бездә язучылар, шагыйрьләр эшли. Журналист һәм язучы, гомумән, бер-берсенә бик тә якын һөнәрләр. Шуңа күрә дә абый-апаларыгыз, һәм журналист, һәм әдип буларак, ничек тә үтемлерәк итеп язарга, газетабызны ничек тә кызыклырак, мавыктыргычрак итеп чыгарырга тырышалар. Сез аларны, әлбәттә инде, яхшы беләсез, язганнарын укып барасыз. Госман Садә — танылган шагыйребез. Өч китап авторы. «Әссәламегаләйкем» исемле популяр җырны да ул язды. Госман абыегыз газетада журналист буларак та, шагыйрь һәм публицист буларак та актив катнаша. Ләлә Гыймадиева — прозаик, «Кызыл алмалар» исемле хикәяләр китабы авторы. Бездә аның әхлак, тәрбия темасына язылган хикәяләре әледән-әле басылып тора. Йолдыз апагызның шигырьләре дә соңгы бер-ике елда «Сабантуй»да еш күренә. Ул үзенең беренче китабын әзерләде. Бу санда без аның шигырьләрен бирә алмадык инде, ачуланмассыз. Ялда әле ул, Сәйдәш исемле малай үстереп ята. Күптән түгел бездә тагын ике егет эшли башлады. Мөхәррәм Каюмовның исеме әдәбият сөючеләргә яхшы таныш. Аның әсәрләре татар матбугатында хәтсездән чыга килә. Шигырьләр җыентыгы төзеп нәшриятка тапшырды. Алмаз Сабиров — бөтенләй яшь егет әле, студент кына. Игътибар итсәгез, соңгы вакытта балалар тормышыннан кыска-кыска парчалар, юморескалар, шаян хикәяләр күренә башлады. Алмаз яза инде аларны. Әгәр дә тырышса, эзләнсә, авырлыкларга бирешмәсә, чын балалар журналисты, балалар язучысы чыгар дигән өметем бар. Гомумән, бездә шигырь, хикәя язмаган кеше эшләми. Атлас Гафиятов та гомер буе шигырьләр яза. Кешегә генә күрсәтми. Әллә спорт белән күбрәк шөгыльләнгәнгә, әллә газета мәшәкатьләре күмеп китә, сирәк бастыра ул аларны. Шулай да бу санга берничә шигырен бирергә булды. Рәзинә Исмәгыйлева да әнә, «Яшь егетләр, яшь кызлар» рубрикасын алып баргач, үзе дә мәхәббәт шигырьләрен яза башлаган...

Әмма күпме генә мактанмыйк, безнең төп авторларыбыз — сез үзегез, кадерле балалар! Сез — шагыйрь дә, язучы да, журналист та. Сез язышмасагыз, безнең «Сабантуй» бик тә күңелсез, төссез чыгар иде. Шуны истә тотып, бүген әдәби санybызны сезнең белән бергәләп чыгарырга булдык. Сез дә безнекеләр, үзебезнекеләр бит!

20 ноябрь, 1991

## Таң ата да кич була...

Таң ата да кич була, таң ата да кич була... Менә тагын бер елны озатабыз. Уйланыр, уяныр чак, кылган гамәлләребезгә бәя бирер чак. Эшләнгән эшләребезгә нәтиҗә ясарга, эшләнмәгәннәрен барлап чыгарга вакыт. Нинди уңышларыбыз, нинди ялгышларыбыз бар? Быелгы ел кайсы яклары белән хәтеребезгә уелып калды?

Шау-шулы, гаугалы, низаглы 1991 ел. Тарихи, революцион үзгәрешләр елы. Көтелмәгән яңалыкларга, фаҗигаләргә, социаль тетрәнүләргә бай булды ул. Сәяси киеренкелек соңгы чиккә җитте. Икътисади хәлебез начарланды. Яз көне генә Союз кирәк дип референдум уздырдык. Шуңа да карамастан Совет империясе җимерелеп төште. Элекке союздаш республикалар бәйсез дәүләтләргә әйләнде. СССР башта ССГ, аннары СНГга әверелде. Ягъни Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлеге. Аңа Балтыйк буе илләреннән һәм Грузия белән Молдовадан кала элеккеге союздаш республикалар кул куйды. СССР белән бергә данлы КПСС та юкка чыкты. Шунысы гаҗәп, аны Генераль секретарь үзе тараткан иде. Менә хәзер ул бөтенләй эшсез калды. СССР булмагач, Президентның да кирәге бетте.

Уйлансаң уйланырлык, моңлансаң моңланырлык хәлләр күп инде ул бездә. Элеккеге бөек Союз капиталистик илләрдән хәер сорарга мәҗбүр. Дәүләткүләм хәер сорашуга барып җиткәч, эшләребез ал да гөл була алмый шул. Газеталар чаң суга: ачлык булачак, салкын булачак! Мәскәү ачыга, Санкт-Петербург ачыга. Киштәләр — буш. Югыйсә ил яшәүдән туктамаган. Завод-фабрикалар эшләп тора, халык эшкә йөри шикелле. Әмма әйбер юк. Тәртип тә юк. Президентны малай-шалайга гына саныйлар. Кайбер республикаларда — гражданнар сугышы. Карабахта һаман кан коела. Грузиннар белән осетиннар, осетиннар белән ингушлар, молдаваннар белән гагаузлар, урыслар тыныша алмый. Танклар, ракеталар, вертолетлар белән сугышалар. Кырым татарларына һаман да көн юк, совет немецларына һаман да урын юк...

Безнең әти-әниләр үзләренең авыр балачаклары турында сөйләсәләр, ышанасы килми иде. Ничек ашарга булмасын инде, нишләп китап-дәфтәр, карандаш-каләм булмасын инде, янәсе. Хәзер инде үзебезнең балаларыбыз интегә. Дәфтәр, кием — талонга, май, шикәр — талонга, оекбаш — талонга. Башка кием-салым талонга да юк. Булганнарын яматтырып, тегештереп кияргә туры килә. Кәнфитләрне бәйрәмнәрдә дә күрә алмыйсың. Менә нинди хәлгә төштек. Тарих кабатланмый, диләр. Кабатлана икән шул, кызганычка каршы.

1991 ел безнең «Сабантуй» өчен дә җиңелдән булмады. Җәйге айларда бер тиенсез калдык. Теләсә кайсы вакытта ябылырга мөмкин идек. Озак кына журналистларыбыз хезмәт хакы ала алмаган чаклар да булды. Газетабызның кайбер саннары да тоткарланып чыкты. Кәгазь зур проблемага әйләнде — үзебезгә табарга туры килде. Укучыларыбыз саны да төрле сәбәпләр аркасында быел шактый кимеде. Быел без 30 мең чамасы чыктык. Декабрьнең соңгы көннәре исә безгә куанычлы хәбәр алып килде. Киләсе елда безнең укучылар саны ел башында 37240 булачак. Тиражыбыз да арта, дусларыбыз да. Бергә-бергә ничек тә җиңелрәк булыр дигән өметебез бар.

Татарстанның киләчәгенә дә зур өметләр белән карыйбыз без. Быелгы ел республикабыз өчен дә борчулы, катлаулы ел булды. Бәйсезлек өчен көрәш елы булды. Җиңүләр дә, җиңелүләр дә булды. Ничек кенә булса да, һаман да алга, бәйсезлеккә барган көнебез. Бу юнәлештә шактый гына уңышларга да ирешелде. РСФСР белән икътисади килешүләр төзелә, яңа законнар кабул ителә. Хәләл милкебез акрынлап үзебезгә кайта. Нефтебез дә азмы-күпме үзебезгә кала башлады. Иң мөһиме, безнең хәзер үзебезнең Дәүләт флагыбыз бар. Татарстан күгендә хәзер Россия флагы түгел, ә үзебезнең яшелле-аклы-кызыллы флагыбыз җилферди!

Иртәгебез нинди булыр? Ниләр көтә безне? Әйтүе кыен. Беркем берни белми. Астрологларга да ышаныч юк. Фәкать үзебезгә генә ышанырга кала! Үзебезнең көчебезгә, акылыбызга, булдыклылыгыбызга. Өметсез — шайтан, ди. Өметсезлеккә бирелеп, борын салындырып, балтаң суга төшкән кеше кебек йөрү егетләр эше түгел. Башны югары тотып, алга карап яшәргә кирәк! Шатлансаң, шатлыклар табыла ул.

28 декабрь, 1991

Россияннар түгел,

«барсианнар»!

Гафу итәсез, кадерле балалар, сезгә коммунизм кырларын күрсәтеп булмады. Социализм дигәннәре дә сүздә генә булып чыкты. Дөньяны дер селкетеп торган СССР таралды да бетте. Сагынып сөйләргә генә калды. Без хәзер «элекке Советлар Союзы»нда яшибез. Совет халкы да түгел инде без, СССР гражданнары да түгел. Совет иле дә юк, социалистик ил дә калмады. Безнең җөмһүриятебез дә Татарстан Совет Социалистик Республикасы булудан туктады. Ул моннан соң фәкать Татарстан Республикасы (Татарстан) гына булачак.

Баш очыбызда 74 ел буе җилфердәгән, изге саналган кызыл флаг та безнең өчен кызыл бер чүпрәк кенә хәзер, һәр иртәдә радиодан яңгыраган Советлар Союзы гимнын да телевидение тапшыруларындагы көлке кичәләрдә генә файдаланалар. Без күнеккән «Ватан» төшенчәсе дә юк инде. Ватандарлык хисләренең күңелләрдә сүрелә баруы шулай ук гаҗәп түгел. Моңа, чыннан да, бер дә гаҗәпләнәсе, аптырыйсы юк. Нигә әле Ватан иксез-чиксез булырга тиеш? Абстракт Ватан була алмый. Ватан ул — әти-әниең, туганнарың, туган нигезең, авылың, туган җирең, туган халкың, туган телең. Ватан ул Әти, Әни, Җир һәм Кояш кебек үк берәү генә була. Дөрес, моңа кадәр без СССРны да, Россияне дә, союздаш республикаларны да Ватаныбыз дип атадык атавын. Шулай да җир читендәге Курил утрауларын яисә Урта Азия чүлләрен, Магадан яисә Колыма якларын беребезнең дә үз Ватаны дип хис иткәне булмагандыр дип беләм.

Безнең туган илебез, Ватаныбыз — Татарстан. Читтә яшәүче милләттәшләрнең дә тарихи Ватаны. Аның әле мөстәкыйльлеккә, бәйсезлеккә омтылган, чылбырдагы арыслан шикелле бәргәләнгән чагы. Әмма чылбырлар, халык теләгенә каршы килә алмыйча, берәм-берәм өзелә бара. Хәтерлисездер, нәкъ ел ярым элек Татарстан Югары Советы суверенлык турында Декларация кабул итте. Үзебезнең Президентыбыз сайланды. Яңа Конституция проекты әзер. Күгебездә яшелле-аклы-кызыллы үз флагыбыз җилферди. Болай да күп яшәдек инде Россия флагы астында. Ә бит заманында Татарстанның үз дәүләте, үз флагы, үз гербы булган. Яңадан үз дәүләтчелегебезне кайтарып алырга вакыт җитте. Инде менә үзебезнең гербыбыз да бар! Кызыл кояш уртасында — ялкындай дөрләп торган канатлы, калканлы ап-ак изге Барс. Болгар бабаларыбыздан, ерак тарихыбыздан килгән ул Барс Татарстаныбызны, халкыбызны бәла-казадан, кайгы-афәтләрдән коткарыр, илбасарлардан, дошманнардан саклар. Барс дигәч, марсиан сүзе күңелгә килде. Бәй, «барсианнар» булып

чыгабыз түгелме соң без? Әйе шул, марсианнар да, россияннар да түгел, «барсианнар» без хәзер, ягъни Барс иле кешеләре...

Дөресен әйтим, моңа кадәр бездә, күпме генә күкрәк каксак та, патриотизм хисе булмады диярлек. Булган очракта да, ялган, ясалма иде ул. Мөгаен, империя үзе тудыргандыр бездәге битарафлыкны. Ләкин үзенең туган илен, халкын яраткан, хөрмәт иткән һәр кеше өчен Дәүләт флагы да, Дәүләт гербы да изге саналырга тиеш. Алар бит дәүләтнең асылын, олылыгын чагылдыра торган символлар. Ә Татарстан хәзер безнең бердәнбер үз Дәүләтебез!

Дәүләтебезнең яңа флагы һәм гербы белән ихластан тәбрик итәм сезне, мөхтәрәм «барсианнар»! Изге Барс безгә бәхет-шатлыклар, бәйрәмнәр, мул һәм имин дөнья, иң мөһиме, бәйсезлек алып килер. Бәйсезлек булса, бар да булачак! Ә баш очыбызда балкыган Татарстан флагы безне әнә шул бәйсезлеккә рухландырып җилферди.

19 февраль, 1992

«Бирсәңезче бер тиен тик,

тәңкә түгел бит, «тиен»!»

Бу мөрәҗәгатьне язасы килмичә берничә ай йөрдем. Кулым бармый, җан тартмый. Хәер сорашудан да авыр әйбер юк икән бу дөньяда. Әмма башка чарабыз калмады. Шуңа күрә ояла-ояла, кызара-кызара, эчемнән генә сездән гафу үтенә-үтенә язам бу юлларны.

Хәзер хәлебезне аңлатырга тырышып карыйм. Сез инде матбугатны күзәтеп барасыздыр, газеталар, журналлар ябылу алдында. Хәтта «Татарстан яшьләре», «Сөембикә» кебек өлкән һәм мәртәбәле басмалар да укучыларыннан ярдәм сорарга мәҗбүр булдылар. Аларга да рәхәт түгел, әмма безгә аларга караганда да авыррак. Зур басмаларның редакцияләре безгә караганда баерак та, иркенрәк тә яшиләр. Партия хакимлек иткәндә дә шулай булды. Әле дә шулай. Хезмәт хаклары да берничә тапкыр югарырак, реклама бастырып та акча эшли алар. Зарлансалар да, бик ышанып бетмәгез диюем. Безнең исә андый мөмкинлекләребез юк шул. Язылудан килгән акчабыз күптән инде бетте. Кәгазебез дә ярты елга гына җитәрлек. Безгә ел буена 2 млн. сумнан артыграк акча кирәк. Хөкүмәттән әлегә 100 мең сум керде — счетыбызда бөтенесе 200 сум акча калды. Кәгазьгә түләргә дә, типографиягә һәм «Союзпечать»кә бирергә дә сукыр бер тиенебез калмады. Хөкүмәт җитәкчеләре ярдәм дә итми, газетаны япмый да. Нишләргә дә белгән юк. Югыйсә өлкәннәр өчен туктаусыз

яңа газеталар, журналлар ачыла тора. Бөтен игътибар — аларга. Безнең генә берәүгә дә кирәгебез калмады.

Уйлаштык-уйлаштык та, сезгә мөрәҗәгать итәргә булдык. Кем күпме булыша ала, кем күпме өлеш чыгара ала? Бәлки, әти-әниләрегез ярдәм итәр? Бәлки, мәктәбегездә ярминкәләр, өмәләр оештырырсыз? Бәлки, колхоз-совхоз җитәкчеләре ярдәм кулы сузар? Бәлки, мәктәп җитәкчеләре бераз өлеш чыгарыр? Безгә 1 сум да, 10 сум да, 100 сум да зур ярдәм хәзер. Аннары, «Сабантуй»ның Балалар фонды газетасы булуын да онытмасагыз иде.

Үзем шушы юлларны язам, үзем Тукайның «Теләнче» шигырен кабатлыйм:

Кызганыч хәл, кызганыч хәл, бик кыен бит, бик кыен;

Бирсәңезче бер тиен тик, тәңкә түгел бит, «тиен»!

Менә шулай. Тукай шигырендәге сукыр карт хәлендә калдык. «Бирсәңезче бер тиен», — дип ялынырга туры килә.

Сезгә артык мәшәкать ясамас өчен газетада «почтовый перевод» кәгазен бастырабыз. Почтада хәзер 70 тиен тора ул. Әгәр дә акчалата ярдәм итәргә уйласагыз, шуны тутырыгыз, кисеп алыгыз һәм почтага илтеп тапшырыгыз. Исем-фамилиягезне, адресыгызны яки мәктәбегезне тутырып язарга онытмагыз. Безгә теләкләрегез булса, «для письма» дигән өлешенә яза аласыз. Ярдәм кулы сузучыларның исемнәрен газетада биреп барырга уйлыйбыз. Ярдәм итәргә теләк белдерүчеләр дә бар инде. Игътибар итсәгез, без газета битләрендә «Татарстан тарихы»н бирә башладык. Ул хикәяләрне Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты хезмәткәрләре — тарихчылар Гамирҗан Дәүләтшаһ-Болгари, Фаяз Хуҗин һәм Искәндәр Измайлов язды. Газетабызның авыр хәлен искә алып, алар үзләренә тиешле гонорарны редакция счетына күчереп баруыбызны сорадылар. Чын күңелдән рәхмәт аларга! Тарихчы абыйларыгызның әлеге игелекләре башкаларга да үрнәк булыр дип уйлыйбыз.

Тагын шуны онытмагыз, кадерле дуслар, «Сабантуй» сезнең өчен чыга. Шуңа күрә аны ябуга юл куймыйк. Төрле юлларын бергәләп эзлик. Өлкәннәр әнә забастовка белән дә куркыталар. Митингларга да чыгалар, пикетлар да оештыралар. Мин әлегә сезне ияртеп митингка чыгарга җыенмыйм. Шулай да сез укытучыларыгыз, әти-әниләрегез белән бергәләп Президентка да, премьер-министрга да, башка җитәкчеләргә дә «Сабантуй»ны яклап хатлар язсагыз, начар булмас иде. Белеп торсыннар. Чарасын күрсеннәр. Балаларның үзләрен тыңламый калмаслар алар. Кайберләрен газета битләрендә дә бирербез. Тик... ни... Роберт абый әйтте, мөхәррир абый котыртты, дия күрмәгез, яме.

Татарлар уйлана, татарлар уяна!

Татарлар Казанга җыелды. Ничә гасырлар буена үзара тарткалашып, таркалып яшәгән, үзара уртак тел таба алмаган, шуның аркасында дәүләтчелеген, мөстәкыйльлеген югалткан татар халкы, ниһаять, бергә туплана. Берләшергә, бергәләп яшәргә омтыла. «Татарның акылы төштән соң», — ди безнең халык. Димәк, төш вакыты җиткән. Кайлардан гына килмәгәннәр Казанга: Башкортстаннан, Себердән, Урта Азиядән, Румыниядән, Германиядән, Финляндиядән, АКШтан, Австралиядән, Япониядән, Кытайдан, Төркиядән... Ата-бабаларының туган җирләренә кайттылар алар. Күрешергә, танышырга, сәҗдә кылырга, рух яңартырга...

Конгресска җыелган залны күзәтәм. Кемнәр генә юк биредә. Үзебезнең якташлар да, чит ил кунаклары да; элекке коммунистлар да, гомерләре буе коммунизмга каршы көрәшүчеләр дә; халык депутатлары белән милли хәрәкәт җитәкчеләре дә, сәүдәгәрләр белән язучылар да... Төрекчеләп тә, үзбәкчеләп тә, казакъчалап та сөйләүче татарлар, урысча гына белүче татарлар... Казан татарлары, Себер татарлары, мишәрләр, типтәрләр, керәшеннәр. Әнә халык депутаты Азат Зыятдинов атаклы Фәрит Сәйфел-Мөлеков белән гәпләшә, әнә язучы Рафаэль Мостафин КПСС Үзәк Комитетының элекке секретаре Гомәр Усманов белән утыра, әнә элекке совет җөмһүриятенең «ата дошманнары» Али Акыш белән Фәрит Иделле, әнә Уфадан Нажар Нәҗми белән Фәридә Кудашева, әнә мөфти хәзрәтләре Тәлгать Таҗетдин һәм Нәүрүз гүзәле Гүзәл Сәләхова... Кемнәре генә юк бу татарның? Аларны күргәч, күзләр чагыла, күңелләр күтәрелә, өмет чаткылары уяна. Шушындый кешеләребез булганда нишләп кимсенеп яшәргә тиеш әле без?!

Чыгышларны тыңлыйм, һәр сүздә татарның ачы язмышы өчен тирән борчылу хисләре, киләчәккә өмет чаткылары, дәүләтчелекне торгызуның төрле юлларын эзләү... Тәкъдимнәр, киңәшләр, мөрәҗәгатьләр, үтенечләр, үпкә сүзләре, рәхмәт сүзләре... Татар уйлана! Татар үзенең үткәнен онытмый, бүгенге хәлен яхшы аңлый, киләчәккә ышаныч белән карый. Боларның һәммәсе дә конгресс кабул иткән карарда ачык чагыла. Мең еллык дәүләтчелеге булган, гасырлар дәвамында Болгар дәүләте, Алтын Урда, Казан ханлыгы булып яшәгән татар халкы, дәүләтчелеген озак вакытлар югалтып торганнан соң, үзенең дәүләтен яңадан аякка бастырырга омтыла. Татарларның шушы конгресска җыелуы бу омтылышны тагын да тизләтер, шәт. Дөнья халыкларына һәм дәүләтләренә, Берләшкән Милләтләр Оешмасына Бөтендөнья татар конгрессы мөрәҗәгать белән дә чыкты:

«Татарстанны Россия Федерациясе һәм башка республикалар, дәүләтләр белән мөнәсәбәтләрен тигез хокуклы договорлар нигезендә коруны суверен дәүләт, халыкара хокук субъекты дип игълан иткән шушы елның 21 мартында уздырылган референдум нәтиҗәләренә таянып, без барлык илләрдән, Берләшкән Милләтләр Оешмасыннан Татарстан Республикасының дәүләт суверенитетын, мөстәкыйльлеген тануны сорыйбыз». Бу сүзләрне дөнья җәмәгатьчелеге ишетми калмас дип уйлыйм.

Татарстан бәйсезлек яулый. Теләк булганда, олы максатлар булганда, татарлар да бергә була ала икән. Конгресс — шуның бер матур дәлиледер. Юк, татарлар тарих арбасыннан төшеп калган халык түгел. Ул башка олы халыклар белән бер сафта булырга тиеш. Шулай

булмаганда кемгә кирәк безнең мөстәкыйльлегебез, нигә безнең көрәшеп, җан атып йөрүләребез?!

Татар уйлана, татар уяна!

27 июнь, 1992

Республика бәйрәме

Татарстан.

Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы.

Дөнья буйлап сибелгән милләттәшләребезнең туган иле.

Бу көннәрдә без аның 70 еллыгын бәйрәм итәбез.

Гасырлар буе көткән, гасырлар буе өмет иткән республикабыз ул безнең. Әйбәтме-түгелме, дәрәҗәлеме-түгелме — үз дәүләтебез. Үзебезнеке!

«Әлеге бәйрәмне уздырмаска кирәк, ул безгә берни дә бирмәде», — дип сөрән салучылар да бар. «Хәзер бәйрәмнәр чоры түгел», — диючеләр дә очрый. Андыйлар белән берничек тә килешеп булмый. Татарга бәйрәмнәр болай да күп эләкми. Без бәйрәмнәргә мохтаҗ. Гасырлар буе көрәшеп яуланган республикабызның туган көнен нигә зурлап бәйрәм итмәскә тиеш әле без?!

Билгеле, газиз Татарстаныбыз — автономияле республикабыз — өметләребезнең бөтенесен дә аклый алмады. Көткәннәребезнең күбесе барып та чыкмады. Хыялларыбыз да күп очракта тормышка ашмыйча калды. Башка олы халыклар янында мескенлек хисләре дә кичереп яшәдек. Аларга тигән бәхетләр безгә тимәде. Алар кебек ил күләмендә дә, дөнья күләмендә дә юньләп чыга алмадык. Без аларга карап берчә сокландык та берчә көнләштек. Башкалар рәтендә яшәү бер дә рәхәт түгел шул.

«Әгәр дә Татарстан союздаш республика булса, без дә латышлар, казакълар, грузиннар... кебек үзебезне дөнья күләмендә танытыр идек», — дигән чаклар күп булды. Кайчакта үзебезнең әби-бабайларыбызга үпкәлисе дә килә. Күпме чорлар азатлык өчен көрәшкәннәр, башка халыклар белән бергәләшеп революция ясаганнар, гражданнар сугышында кан койганнар. Җиңгәннәр! Ә үзләре союздаш республика да яулап ала алмаганнар. Хәер, автоно-

мия белән союздашның аермасы турында уйлап та карамаганнардыр алар. Республика гына булсын! Союздаш республикаларның, чыннан да, зур хокуклар аласын, ә инде автономияләр 70 ел буе өлкә дәрәҗәсендә генә йөрисен кем белгән соң ул чакта.

Инде менә бабаларыбызның хатасын безгә — аларның оныкларына төзәтәсе. Оныкларыбыз безгә дә үпкәләмәсен дисәк, Татарстан союздаш республикасы булырга тиеш. Безнең инде автономия дигән күлмәгебез кечерәйде. Дөресрәге, үзебез үстек. Без аңа гына сыймыйбыз. Безнең яңа күлмәк — үзебезгә тап-таман итеп тегелгән күлмәк киясебез килә. Үзебезнең олылыгыбызга, талантыбызга, байлыгыбызга, көчебезгә лаек дәүләт статусы кирәк безгә! Кемдер җитәкләп йөргәнгә генә риза түгел инде без. Үз язмышыбызны, киләчәгебезне үзебез хәл итәсебез килә. Безгә бары тик туганнарча ярдәм генә кирәк. Йөзгә кызыллык китерә торган түгел татар халкы. Моны башкалар да — республикабызда яшәүче руслар да, чуашлар да, марилар да, удмуртлар да яхшы белә.

Татарстанда — Олы бәйрәм.

Республика бәйрәме!

Без аны башка олы халыклар кебек үк олылап бәйрәм итәргә тиеш!

23 июль, 1990

Кик-ри-күк!

Исәнмесез, саумысыз!

Әтәчегез күкәй салган,

Нигә чыгып алмыйсыз?

Юк ла инде, шаяртам гына. Нишләп әтәч күкәй салсын ди. Без бәләкәй чакта кабатлый торган такмаза гына ул. Әле менә искә төште дә... Чү! Чыннан да, әтәч кычкыра түгелме соң?!

— Кик-ри-күү-ү-үк!

Әнә, ишетәсезме, Яңа елны әтәч тавышы уята. Ниләр алып килер ул безгә? Нинди шатлыклар белән шатландырыр? Бәхетле итәрме? Көлдерерме, җылатырмы? Иминлек елы,

байлык-муллык елы, җиңүләр, уңышлар елы булырмы Әтәч елы? Булыр дип уйлыйм. Иң мөһиме, безне көн саен әтәч үзе уятачак. Ә инде беренче әтәчләр белән иртән-иртүк торган кеше һичшиксез бәхетле була. Әтәч тавышына кем уянмасын инде. Димәк, артка кояш төшкәнче йокламыйбыз дигән сүз. Димәк, эшкә дә, дәрескә дә соңга калмыйбыз дигән сүз. Димәк, әйбәт укыйбыз, начар билгеләр алмыйбыз дигән сүз. Югыйсә соңгы елларда дөньяның рәте китте. Күбрәк йокы симертәбез. Шул әтәч юклыгы аркасында инде.

Аннары, әтәч халкы үзебезнеке бит. Кайсы гына авылга барып керсәң дә, әтәчсез абзарын, йорт-җирен күрмәссең. Капканы ачуга сине әтәч каршы алыр. Койма башына кунаклаган ул горур әтәчкә исләрең китәрлек... Үзе кукрайган, күкрәкләре тырпайган, койрыклары кәкрәйгән. Әллә кем диярсең, билләһи! Менә кемнән горур булырга өйрәнергә кирәк безгә.

Хәер, әтәчсез җир бармыни инде ул. Әкияттә дә — әтәч, мәзәктә дә — әтәч, рәсемдә дә — әтәч. Күрәсеңме, әтәч тә әтәч... «Башы — тарак, койрыгы — урак. Кычкырта быргысын, уята барысын». Ул нәрсә? Дөрес, әтәч. Бер мәзәк сөйләп күрсәтимме соң? Тыңлагыз алайса: «Мокыт таң алдыннан юлга чыгарга дип яткан икән. Уянып китсә, таң аткан, кояш чыккан, олау киткән, юлга чыга алмый калган. Нишләргә? Йортка чыккан да әтәчне суйган. Җәмилә җиңги: «Нигә суйдың?» — дигәч, ул аңа: — Әтәч кычкырмый таң атмый, шул кычкырып аттырган! — дигән имеш».

Ярар, булгач булсын, мин сезгә сер итеп кенә берничә такмаза да өйрәтим әле. Тик ни — эти-әниләрегезгә, укытучыларыгызга укыта күрмәгез. Әйбәт түгел дип йә ачуланырлар. Беләсез бит инде аларны. Менә тыңлагыз.

Әтәч менгән читәнгә,

«Кикрикүк» итәргә.

Әтәчкә хәбәр килгән

Армиягә китәргә.

Әтәч әйтә: «Бармыйм», — ди.

Чебеш әйтә: «Калмыйм, — ди. —

Син армиягә китсәң,

Бер күкәй дә салмыйм», — ди.

Әтәч армиягә китте,

Чабатага утырып.

Чебеш мескен карап калды,

Күзкәйләрен тутырып.

Бәтәч, этәч тә этәч дип, Яңа ел турында онытып җибәрә язганмын. Быел Әтәч елы бит әле. Билгеле инде, сабантуйлар да этәчсез була алмый. Мәйдан уртасында озын колга, колга очында зур кәрзин, кәрзиндә — этәч. Сабантуй этәче. Кем җитез, кем елгыр, рәхим итсен, менсен дә алсын. Безнең үзебезнең «Сабантуй»ның да быел үз этәче булачак. Газетабызның һәр санына менеп кунаклаган этәч «Кикрикүк» дип татар малайларын, татар кызларын уятачак. Югыйсә туган телебезне, җыр-моңнарыбызны, гомумән, халкыбызны санга сукмаган, милли аңы йоклаган балалар да җитәрлек әле. Күпләребезгә татар булып уянасы бар.

Арада, әлбәттә, этәчтән дә курыккан кызлар белән калай этәч малайлар да очрый. Андыйларга киңәшем шул. Әтәч елы дигәч тә бик этәчләнмәгез, яме. Әти-әниләрегездән эләксә, «икеле»-мазар алсагыз, кикригегез тиз шиңәр, Әтәч елы этәчләнү өчен, пыр тузып сугышу өчен түгел ул. Әтәч кебек горур, мәгърур, этәч кебек эшлекле булырга өйрәнегез. Шунсыз булмый хәзер.

Тагын нәрсә языйм икән, шайтан алгыры. Сүз юктан сүз булсын, этәчегез күкәй саламы, дигән кебегрәк булды инде бу мәкалә, ачуланмассыз. Әтәч каурые белән генә язарга туры килде.

P.S.

— Кикрикүк!

Әй, малайлар, әй, кызлар! Уяныгыз, торыгыз! Бәхетегездән колак кага күрмәгез. Җир өстенә Яңа ел — 1993 ел килде. Әтәч елы!

— Кикрикү-ү-үк!

1 гыйнвар, 1993

Корылтай – съезд дигән сүз

Боз кузгала. Халкыбыз кузгала. Күңелләргә, әкрен-әкрен генә булса да, иман кайта, милли рух кайта. Татарча сөйләшергә оялып йөрүче шәһәр малайлары-кызлары да үзебезчә сөй-

ләшүдән тартынып тормыйлар. Татар концертларында да яшүсмерләр, балалар ешрак күренә. «Кеше итәбез» дип балаларын рус классларына, рус мәктәпләренә генә бирүче ата-аналарның да кайберләре татарча укытуны хәзер инде табигый хәлгә саныйлар. Мәктәпләрдә татар теле һәм әдәбиятына ихтыяҗ да, игътибар да арта башлады. Бу — чит җирләрдә гомер итүче милләттәшләребезгә дә кагыла. Аларның бөтен өметләре — шәһри Казанда, татарларның Төп Йортында. Ә сибелгән, чәчелгән татар илебезнең кайсы төбәгендә генә яшәми?! Батуллача әйтсәк, әй бу күпмилләтле татар халкы!

Татар иҗтимагый үзәгенең II корылтае таралган, таркалган татарларны җыйды да инде үзенә. Әнә Башкортстан, Әстерхан татарлары, ерак Себердән, Уралдан, Урта Азиядән, Балтыйк буйларыннан килгән татарлар... Әнә үзебезнең аксакалларыбыз — Әмирхан ага Еники, Гомәр ага Бәширов, Әбрар абзый Кәримуллин, Мәскәүнең атаклы галимнәре Роберт Нигъмәтуллин, Әгъдәс Борһанов... Әнә иҗтимагый үзәк лидерлары: Марат Мөлеков, Рафаэль Хәкимов, Фәүзия Бәйрәмова... Әнә дин әһелләре, зыялылар, авыл кешеләре, студентлар... Әнә «Азатлык», «Ватан», «Иттифак», «Суверенитет» оешмалары вәкилләре...

Аларны Казанга корылтай җыйган. Туган халкыбызга хезмәт итү теләге, аның киләчәгенкайгырту хисләре алып килгән бу татарларны. Элегрәк бу чаклы татарны берьюлы сабантуйлар гына җыя ала иде. Хәер, бу корылтай үзе дә бераз гына сабантуйны хәтерләтте. Бәйрәм рухы. Күтәренкелек. Җыр-моңнар. Өр-яңа милли газеталар. Ирексездән, 1905 елгы революциядән соңгы Яңарыш еллары, Тукайлар чоры күз алдына килде. Тарих та кабатлана микән әллә?

Корылтайда сүз, нигездә, татар халкының язмышы, Татарстанның бәйсезлеген яклау, татар мәктәпләре, читтәге халкыбызга һәртөрле ярдәм турында барды. Нәкъ менә шушыларны истә тотып, Бөтенсоюз татар иҗтимагый үзәге төзелде дә инде. Аның президенты итеп Марат ага Мөлеков сайланды. Татарлар яңадан ил буйлап таралдылар. Үзләренең туган җирләренә. Яңа дәрт белән, матур уй-хыяллар белән. Сүнеп, сүрелеп барган татар учакларын яңадан тергезергә. Корылтай аларның күңелләрендә яңа ышаныч, өмет чаткылары кабызгандыр дип ышанам. Ә корылтай — съезд дигән сүз.

2 март, 1991

Балаларга бәйрәм кирәк!

21 март көнне Академия театрына Казан балалары җыелды. Балалар фонды оештырган бу бәйрәмгә интернатлардан, гимназияләрдән, күп балалы гаиләләрдән килгәннәр иде. Ял итәргә, күңел ачарга, тамаша карарга...

Бәйрәмне ачып җибәргәндә мин сүземне болай дип башладым: «Кешеләргә бәйрәм кирәк, балаларга бигрәк тә! Гаҗәп бер көн бүген. Бәйрәмнәргә бай көн. Игътибар иттегез микән, урамда — яз, кояш, яп-якты. Күптән булганы юк иде инде мондый матур көннең. Кояш та безнең яклы икән. Бүген Нәүрүз бәйрәме бит. Бүгеннән чын яз башлана. Бабаларыбыз элек нәкъ шушы көнне Яңа елны каршылый торган булганнар. Аннары, бүген көн белән төн тигезләшкән мизгел. Моннан соң безнең көннәребез тагын да яктырачак, тагын да озыначак. Бүген — референдум көне дә. Аның уңай нәтиҗәсе безнең көннәребезне тагын да яктыртыбрак җибәрәчәк. Балалар фонды бүген сезгә әлеге бәйрәмнәргә өстәп тагын бер бәйрәм ясарга булды. Хәзер сез әле беркем дә күрмәгән, беркем дә белмәгән өр-яңа бер әкият карарсыз. Соңыннан күңелегез булганчы җырларсыз, биерсез, уйнарсыз».

Балаларга спектакль бик тә ошады. «Кара пута серләре» исемле ул әкият аларны көлдерде дә, дулкынландырды да, уйландырды да. Залда рус балалары да бар иде. Тәрҗемә булгач, алар да барысын да аңлап утырдылар. Малайлар бигрәк тә Омоссу белән Хейтоконың японча сугышуларына мөкиббән киттеләр. Менә сугышчылар ичмасам! Ямамба исемле ямьсез кызны Рәшит Шамкаев та бигрәк килештереп уйнады. «Аждаhа, аша мине!» — дип аждаhа янында йөргәндә, зал көлде дә, елады да. Усал аждаhаның башын кисеп төшергәч, малайлар-кызлар башта бик курыкканнар иде, соңыннан аны уйнаган артист Г.Шәрәфи баш ияргә чыккач кына җиңел сулап куйдылар. Юри генә киселгән икән лә ул баш.

Аждаhаны күмәк көч белән җиңгәч, балалар җиңүчеләр кыяфәтендә фойега чыктылар. Анда аларны зу-ур концерт көтә иде. Туйганчы биеделәр, җырладылар, шигырьләр сөйләделәр. Кыскасы, үзләренең һөнәрләрен күрсәттеләр. Остаракларына бүләкләр дә эләкте. Ә урамда — театр алдында — аларны җигүле ат каршы алды. Кыюрак малайлар-кызлар шул атта да әйләнеп килделәр. Аннары автобусларга, трамвайларга, троллейбусларга төялешеп өйләренә таралыштылар.

Һичшиксез истә калачак бу бәйрәм, Татарстаныбызның язмышы хәл ителгән көн. Безнең бәйрәмнәр башлана гына әле!

8 апрель, 1992

Вәгъдә – иман

Газета-журналларга язылу вакыты җитте. Редакция хезмәткәрләре тыз-быз чабыша башлый, мәктәпләргә чыгып китә, очрашулар уздыра. Җитмәсә, иң мәшәкатьле чор: балалар басуларда бәрәңге, чөгендер алалар, өлкәннәргә булышалар. Күңелләргә борчулы бер сорау кереп оялый: «Сабантуй»га язылырлармы?» Күптән түгел таныш бер журналист белән бәхәсләшеп киттек. Ул үзе өлкәннәр газетасында эшли, шуңа күрә безнең балалар газетасына кимсетебрәк карарга ярата. «Быел сезнең «Сабантуй»га язылмаячаклар, — ди бу миңа, — чөнки алар үзләре акча эшләми, ә әти-әниләре үзләренә берәр зур газетага язылачаклар да вәссәлам. Балаларын онытачаклар, менә күрерсең. Эгоистлар бит алар». Мин дә җавапсыз калмадым, билгеле. «Андый ата-аналар да бардыр анысы. Тик алар бармак белән генә санарлык. Күпләре балаларын әйбәт, итагатьле, намуслы, үз халкын яратучы итеп тәрбияләргә тырыша. «Сабантуй»ның нәкъ менә шундый тәрбияче икәнен алар яхшы беләләр», — дидем. Ә аннары эчемнән генә шикләнеп тә куйдым: «Язылырлармы «Сабантуй»-га?»

Чыннан да, матбугатка язылу башланса, өлкәннәрнең күбесе аптырашта кала. Соңгы берничә елда бигрәк тә. Кайсы журналга, кайсы газетага язылырга? Чөнки сайланырга урыннары бар, «Ватаным Татарстан»га язылсалар, «Татарстан хәбәрләре» кала. Анысын алдырса, «Шәһри Казан» бар. «Татарстан яшьләре», «Татар иле»... Аннары әти-әниләр уйлаша-уйлаша да иң яраткан газеталарына язылып та куя. Кайсысына дисезме? Һәркем үзе яратканына инде, билгеле. Шулай булгач, сез дә, кадерле укучыларыбыз, яраткан газетагызга язылырга тиеш буласыз. Ә инде «Яраткан газетагыз нинди?» — дип сорасам, үпкәләячәксез. Шуңа күрә сорап та тормыйм. Андый газета берәү генә. Ул — «Сабантуй», татар балаларының бердәнбер газетасы. Башкасы юк. Булмас та төсле. Димәк, өлкәннәр кебек баш ватып, сайланып торасы да юк. «Сабантуй», фәкать «Сабантуй» гына килергә тиеш сезнең өйләрегезгә.

«Кыйммәт бит, сабантуйны без елга бер булса да бушлай гына күрәбез», — диярсез, бәлки. Юк шул менә, бушлай түгел. Соң, сабантуйга кем буш кесә белән бара инде. Акчасыз сабантуй — акчасыз өй кебек. Баргач та әти-әниегездән иң элек 7–10 сумга импорт сагызы алдыртасыз. 6 сумга пломбир. 10–15 сумлык лимонад, пепси-кола да эчми калмыйсыз. Тамак яна башласа, 10 сумлык сок булса да эчәсең. Берәр стакан көнбагышсыз да булмый. Анысы да 5 сум бардыр. Кызлар исә шоколадсыз сабантуйны күз алдына да китерә алмый. Ул исә 100 сум тора, диләр. Үземнең ашап караганым юк анысы. Прәннек-печеньеның да килосы 70–80 сумга җитә. Булка-мазар да ашыйсы килсә? Чикләвек та сатсалар? 50–60 сумлык берәр китап алсагыз? Ә инде сабантуйга дип яңа күлмәк тә тектерсәгез, бетте баш, калды муен тырпаен дигән сүз. Бер көнлек сабантуй күпмегә төшә булып чыга инде? Күп инде, күп. Безнең «Сабантуй»ның ярты еллык бәясе шалкан бәясе булып кына кала. Нишлисең, заманы шундый. Дөрес, сабантуйда җиңүчеләргә бүләкләр дә эләгә. Сөлге, яулык, хәтта тәкә дә эләгергә мөмкин.

Шулай булырга тиеш тә. Безнең «Сабантуй»да да җиңүчеләрне бүләкләр көтә. Сез инде бездә нинди уеннар, клублар, бәйгеләр барын беләсез. Киләсе елда алар тагын да артачак. Әгәр дә инде хатыгыз яисә мәкаләгез, әкиятегез һәм шигырегез дә басылып чыкса, аннан да зур бүләкнең булуы мөмкинмени?! Әти-әниегез, укытучыларыгыз өчен дә, авылдашларыгыз, дус-ишләрегез өчен дә олы бүләк булачак ул.

Мин сезгә ышанам, дусларым. Шулай да күңел борчыла, шикләндерә. Яраталар микән укучылар безнең «Сабантуй»ны? Шуңа күрә беркөнне бакчабыздагы ромашка чәчәген алдым да таҗ яфракларын берәм-берәм өзә башладым. «Ярата... яратмый... ярата... яратмый... ярата!» Ур-ра! Ярата безне укучы. Болай булгач, киләсе ел өчен дә язылачаклар алар, безне ташламаячаклар. Без дә үз чиратыбызда сезне ташламабыз. Якын дустыгыз, ярдәмчегез, киңәшчегез булырбыз. Вәгъдә — иман! Вәгъдәбездә һичшиксез торырбыз. Сез инде моны үзегез дә яхшы беләсез. Моңа чаклы һәрчак сүзебездә тордык. Иң авыр чакларда да, башка балалар газета-журналлары бөтенләй туктап торганда да («Пионерская правда» өч ай чыкмый торды, «Трамвай» журналы ябылды; үзебезнең республикада да шундый ук хәл: «Ялкын» җиде сан гына чыкты, «Салават күпере» дә күренми). Ә без вакытында чыгып килдек. Бер генә саныбыз да чыкмый калмады — «Сабантуй» сезгә тугрылыклы булып калды. Монда, билгеле, үзегезнең дә өлешегез зур. Әгәр дә иң кыен чакларыбызда сез ярдәмгә килмәсәгез, безнең эшләр харап иде. Үзегездән өзеп ярдәм күрсәттегез. Чын күңелдән рәхмәт сезгә, киң күңелле укучыларыбыз! Шулай булгач, ничек инде матур газета чыгармыйсың да, ничек инде сезнең өчен тырышмыйсың. Газета сезгә вакытында барып җитсен өчен, эчтәлекле һәм югары сыйфатлы булсын өчен без бөтен көчебезне, сәләтебезне биреп эшләячәкбез. Төп авторларыбыз сез булачаксыз, кадерле малайлар-кызлар. Әгәр дә сез безнең газетага язылсагыз, язышып торсагыз, мәкаләләр, әкиятләр, шигырьләр җибәрсәгез, «Сабантуй» укып туймаслык булачак. Менә күрерсез!

Рәхмәт сезгә!

Моннан биш ел элек В.И.Ленин исемендәге Совет Балалар фонды төзелгән иде. Аны оештыру конференциясендә миңа да катнашырга туры килде. Аннары үзебезнең Татарстанда да Балалар фондының республика бүлеген оештырдык. Илдәге иң беренче фондларның берсе булды ул. Фонд төзелгәнче газета-журналларда, радио-телевидение аша шәфкатьлелек, миһербанлылык турында сөйләү, ятим балаларның, гарип, авыру сабыйларның ачы язмышларына багышланган мәкаләләр язу, тапшырулар оештыру бөтенләй диярлек юк иде. Кешегә шәфкатьлелек күрсәтү, матди ярдәм күрсәтү буржуаз җәмгыяткә генә хас дип өйрәттеләр безне. Балалар йортларында тәрбияләнүчеләрнең авыр тормышларын,

авыру, инвалид балалар яшәгән интернатларны, санаторийларны җәмәгатьчелек күзеннән яшереп тоттылар. Әниләре ташлап калдырган сабыйлар, эчкече аналардан туган гарип балалар турында, аларның безнең республикада гына да меңәрләгән булулары турында ишетеп тә белми идек, белергә дә теләми идек. Янәсе, безнең илдә барысы да ал да гөл!

Безнең Фонд беренче булып чаң какты, беренче булып җәмәгатьчелекне ярдәмгә чакырды, үзе дә булышырга ашыкты. Турыдан-туры халыкка мөрәҗәгать итте. Күңелләребезгә акрынлап-акрынлап шәфкатьлелек хисләре кайта башлады. Өлкәннәр дә, малайлар-кызлар да ятимнәргә, авыруларга ярдәм кулы сузарга ашыктылар. Әле дә хәтеремдә, бөтен ил белән шәфкатьлелек акцияләре уздырылды. Бик күп өлкәннәр, үзләренең хезмәт хакларыннан өзеп, пенсионер әби-бабайлар пенсияләреннән өлеш чыгарып, безнең счетка хәл кадәри акча күчерде. Балалар шәфкатьлелек концертлары, өмәләр, ярминкәләр оештырды, балалар йортларындагы сабыйлар өчен оекбашлар, бияләйләр бәйләп җибәрде. Әле күптән түгел генә Апастан Миләүшә апагыз Вәлиуллина шундый йон оекбашлар, бияләйләр тулы ике капчык калдырып китте. Рәхмәт яусын Апас балаларына!

Биш ел эчендә безнең Фонд эшләгән игелекле эшләрне санап кына бетермәле түгел. Әтиләре Әфганстанда һәлак булган балаларны иң элек без шефлыкка алдык. Гаилә тибындагы балалар йортлары да безнең ярдәм белән оешты. Ел саен 2 меңнән артык балага чыршы бәйрәмен дә, яз саен Нәүрүз бәйрәмен дә, шулай ук 1 июнь көннәрен дә без уздырабыз. Сабыйларга бәйрәм кирәк! Аларның матур итеп киенәселәре, тәмле итеп ашыйсылары да килә. Шуңа күрә без үзебез дә сабыйлар һәм балалар йортларында, шифаханәләрдә, санаторийларда еш булабыз: күчтәнәчләр, бүләкләр, кием-салымнар илтәбез. Ул балаларның бер елмаюын күрү дә олы бер бәхет! Безнең Фондның ишекләре һәрвакыт ачык. Кемнәр генә килми безгә: оныгын тәрбияләүче әби дә, гарип баласын тоткан апа да, күп балалы аналар да, опекуннар да, директорлар да, төрле республикалардан кайткан качаклар да... Аз булса да ярдәм итәргә тырышабыз.

Әмма, дөресен әйтергә кирәк, бүгенге көндә үзебезнең дә хәлебез мактанырлык түгел. Җәмгыятебездәге начар якка үзгәрешләр безгә дә тәэсир итте. Ярдәм итүчеләр сирәгәйде, һәркемнең үз хәле, үз мәшәкате. Шулай булуга да карамастан эшебезне дәвам итәбез. Ярдәмгә мохтаҗ балалар һаман да бик күп әле. Алар бездән булышлык, якты чырай, җылы сүз көтә.

Форсаттан файдаланып, Балалар фондына ярдәм кулларын сузган өлкәннәргә һәм малайларга-кызларга үземнең чиксез рәхмәт хисләремне җиткерәм. Игелек җирдә ятмый, диләр безнең халыкта. Сез кылган игелекләр бише-уны белән яңадан үзегезгә әйләнеп кайтсын. Әгәр дә бәйрәмнәрдә өсләренә матур киемнәр кигән, шат чырайлы ятим балаларны очратсагыз, гарип балаларның йөзендә елмаю чаткылары күрсәгез, аларның шатлыгында үзегезнең дә өлешегез бар дип исәпләгез. Алар сезгә дә рәхмәтле! Аларның рәхмәтенә мин дә кушылам һәм сезнең һәрвакыт шушындый игелекле, матур күңелле булып үсүегезне телим!

3 март, 1993

Шәфкатьлелек сессиясе

Рәсәй болгана, кайный. Рәсәй ызгыша, тарткалаша. Рәсәй хакимият өчен көрәшә. Андагы җитәкчеләр халык турында түгел, үзләре турында гына уйлыйлар булса кирәк. Шуңа күрә дә халкы хәерчелектә, пычраклыкта, өметсезлектә көн күрә. Рәсәйдәге хәвефле шаукым безгә дә тәэсир итми калмый, билгеле. Моның сәбәпләре бик күп: акча берәмлеге уртак, икътисадыбыз бәйләнеп-чуалып беткән...

Әмма ни генә булмасын, бездә әлегә дөньялар чагыштырмача тынычрак, бәяләр чагыштырмача арзанрак, өметләребез чагыштырмача яктырак. Президентыбыз да, министрлар кабинеты белән Югары Совет та Татарстанның мөстәкыйльлеге өчен, халкыбызның тормыш-көнкүрешен яхшырту өчен мөмкинлекләрнең барысын да файдаланырга тырышалар.

Менә әле Югары Советның XV сессиясе үзенең эшен тәмамлады. Миңа калса, шактый тыныч һәм эшлекле төстә узды ул. Артык бәхәс-тарткалашлар да, бушка чүбек чәйнәүләр дә булмады диярлек. Мин аны шәфкатьлелек сессиясе дип атар идем. Чөнки анда сүз, нигездә, халыкны социаль яклау турында барды.

Республикада кереме аз булганнарның саны көннән-көн күбәя. Уйлап кына карагыз, бүгенге көндә халыкның 65 проценты шундый хәлдә яши. Аларга кичекмәстән ярдәм кирәк. Дәүләт күләмендәге ярдәм. Дәүләт җитәкчеләре бу хакта күптән борчылалар иде. Шуның нәтиҗәсе буларак, депутатлар сессиядә хөкүмәтнең адреслы социаль яклау программасын карадылар һәм аны яхшы дип таптылар. Билгеле инде, төзәтмәләр дә, өстәмәләр дә шактый керттеләр. Программада каралган чаралар Татарстанда яшәүче бик күп мохтаҗ кешеләрнең тормыш хәлләрен ярыйсы гына яхшыртыр дигән өметебез бар. Бу — балаларыбызга да турыдан-туры кагыла.

1 апрельдән минималь хезмәт хакы 2250 сумнан 4500 сумга күтәреләчәк. Азык-төлек товарларына компенсация рәвешендә балаларга өстәмә чеклар биреләчәк. 6 яшькәчә балаларга ай саен 1000 сум, 6 яшьтән 13 яшькә кадәрге балаларга 1500 сум, 13 яшьтән 16 яшькә кадәрге укучы балаларга 2000 сум... Аерым пенсионерларга, инвалид, авыру балаларны тәрбияләүче ата-аналарга һәм опекуннарга да шундый ук өстәмә түләүләр кертеләчәк.

Аннары, программада 2 яшькә кадәрге сабыйларны сөтле туклану ризыклары һәм катнашмалар белән тәэмин итү; инвалид һәм ятим балаларны, опекага алынган балаларны, ата-аналары I яисә II группа инвалид булган гаиләләрдәге балаларны санаторийларда, профилакторийларда, ял йортларында республика бюджеты хисабыннан түләүсез савыктыру каралган.

Әмма мохтаҗ кешеләр, мохтаҗ гаиләләр аерым бер кысага гына сыеп бетми. Шуны истә тотып, һәр шәһәрдә, һәр районда авыруларга, ярдәмчесез картларга, күп балалы гаиләләргә ярдәм күрсәтү максатыннан, социаль яклау фондлары оештырыла. Әлеге фондлар аеруча мохтаҗ кешеләргә, гаиләләргә ярдәм итәргә тиеш.

Югары Совет раслаган хөкүмәт программасында болардан тыш та халыкны төрле яклау чаралары каралган. Аларның һәммәсе дә халкыбызга хезмәт итәчәк. Хөкүмәтебез шәф-

катьле булганда гына, үз халкына ихтирамлы, игътибарлы булганда гына туган Татарстаныбызның киләчәге матур булыр!

3 апрель, 1993

Үзебезнең Конституциябез!

Беләсезме, 70 елдан артык без берьюлы өч конституция белән яшәдек. СССР, РСФСР һәм ТАССР конституцияләре иде алар. Әмма, ни гаҗәп, аңа карап кына безнең хокукларыбыз да артмады, тормышыбыз да җиңеләймәде, коммунизм дигәннәрен дә күрә алмадык. Чөнки ул конституцияләр, бигрәк тә соңгы икесе, исем өчен генә язылган булып чыкты. Хәтерегездәме, без бары тик СССР Конституциясе көнен генә бәйрәм итә идек. Ә инде РСФСР белән ТАССР конституцияләренең бар икәнен дә белми идек.

Ниһаять, 1992 елның 6 ноябрендә без үзебезнең Конституциябезне кабул иттек. Бу — безнең зур җиңүебез булды. Татарстан Конституциясе фәкать үзебезнең республикага, аның күпмилләтле халкына хезмәт итә, аның үткәнен, бүгенгесен һәм киләчәген яклый. Дәүләтчелегебезне торгызуда аның әһәмияте әйтеп бетергесез зур булачак. «Татарстан Республикасы — республиканың күпмилләтле барлык халкы ихтыярын һәм мәнфәгатен чагылдыручы суверен демократик дәүләт» дип язылган аңа. Бу инде безнең Татарстаныбыз дөньядагы башка дәүләтләр белән янәшә торырга хаклы дәүләт дигән сүз. Өстәвенә Татарстан — халыкара хокук субъекты да. Конституциядә ачык итеп язылган: «Татарстан Республикасы башка дәүләтләр белән мөнәсәбәткә керә, халыкара килешүләр төзеп, дипломатия, консуллык, сәүдә һәм башка вәкиллекләр алмаша. Халыкара хокук принципларына нигезләнеп, халыкара оешмалар эшчәнлегендә катнаша».

Дөрес, әлегә безнең мөстәкыйльлегебезне Россия дә, башка дәүләтләр дә танырга ашыкмыйлар. Киресенчә, соңгы вакытта Россиянең яңа Конституциясен әзерләү уңае белән, республикаларның һәм, әлбәттә, Татарстанның да суверенлыгына кул сузарга тырышулар да ешайды. Мәскәү җитәкчеләре безне ничек тә гап-гади өлкәләр дәрәҗәсендә калдырмакчылар. Әмма Татарстан халкы, татар халкы моның белән беркайчан да килешмәячәк. Без үзебезнең Конституциябездән бер адым да артка чикмәячәкбез.

Без моңа кадәр туган телебезнең язмышы өчен дә борчылып яшәдек. Борчылуыбыз әле дә дәвам итә. Чыннан да, телебез бетү дәрәҗәсенә җиткән иде. Яңа Конституция моңа да чик куйды. «Татарстан Республикасында дәүләт телләре — тигез хокуклы татар һәм рус телләре» диелгән анда. Калганы фәкать үзебездән тора: татар теле тиз арада чын мәгънәсендә

дәүләт теле, республика теле дәрәҗәсенә күтәрелергә тиеш. Биредә барыбызның да тырышлыгы сорала.

Безгә бигрәк тә Конституциябезнең «Кеше һәм гражданның хокуклары, иреге һәм бурычлары» дигән бүлеген яхшы белергә кирәк. Үзебезнең хокукларыбызны һәм бурычларыбызны белми торып, без бервакытта да Татарстанның чын гражданнары була алмыйбыз. Бер генә мисал китерәм. Әлеге бүлектә «Татарстан Республикасы гражданнары үз балаларын тәрбияләү өчен җаваплы. Балигъ булган балалар ата-аналарын кайгыртырга һәм аларга ярдәм күрсәтергә бурычлы» дигән сүзләр бар. Димәк, «кунак ашы — кара-каршы». Чыннан да, дәүләтебез үзенең балаларын тәрбияләүне, аларның сау-сәламәт, белемле, патриот хисле чын гражданнар булып үсүләрен тәэмин итәргә бурычлы. Малайлар-кызлар моны тоеп, аңлап, күреп торалар. Олыларның үзләренә булган әйбәт мөнәсәбәтләрен, хөкүмәтебезнең олы хәсрәтен күреп үскән балалар гына Татарстаныбызга, өлкән буынга ихтирамлы булырлар.

Конституцияне кабул итү белән генә түгел, аны изге санарга һәм үтәргә дә кирәк. Мәскәү җитәкчеләре конституцияләрен дә, законнарын да үзләренә ничек кирәк, шулай боргалыйлар, бертуктаусыз бозалар. Бу инде законсызлык, башбаштаклык дигән сүз. Илдә тәртипсезлек тә, кан коеш та шуннан башлана. Ә инде Конституцияне бозмас өчен аны яхшы белү, җентекләп өйрәнү сорала. Шуңа күрә Татарстан Республикасының яңа Конституциясен сез дә, кадерле укучылар, бик әйбәтләп өйрәнсәгез иде. Сезгә дә шушы Конституция белән яшәргә туры киләчәк бит.

1992

## Кан коела, җан кыела...

Дөнья кайный. Җирдән төтен исе килә. Тын кысыла. Кечкенә Җир шарыбыз ракеталар гөрселдәвеннән, бомбалар шартлавыннан тетрәнеп-тетрәнеп куя. Шәһәрләр җимерелә, кешеләр үлә. Кемгә кирәк соң бу сугышлар? Нәрсә хакына бу ызгышлар, үтерешләр?

Өлкәннәр — президентлар, премьер-министрлар, акыллы дәүләт эшлеклеләре, тәҗрибәле дипломатлар үзара килешергә теләмиләр, уртак тел таба алмыйлар. Әйтерсең лә, мәктәпләрдә, гимназияләрдә, колледжларда укыганда аларны укытучылары фәкать сугышырга, кан коярга, бер-берләренә юл бирмәскә генә өйрәткәннәр. Малай чакларында да аларның күбесе сугыш чукмарлары, башкисәрләр, хулиганнар булгандыр дигән тәэсир кала. Шулай булмаса, сугышырга гына тормаслар иде, киңәш-табыш итәрләр иде, ничек тә килешерләр иде, Фарсы култыгында да бүген сугыш бармас иде.

Ә анда кан коела. Кайчандыр Гыйрак күршесе Кувейтны басып алган иде. Хәзер Гыйракның үзенә каршы АКШ, Франция, Англия, Канада кебек илләрнең берләшкән кораллы көчләре сугыша. Гыйрак һәм Кувейт шәһәрләренә ракеталар оча. Гасырлар дәвамында төзелгән, дөнья мәдәниятенең йөзек кашына әверелгән Багдад шәһәре күзгә күренеп җимерелә, ракеталар, самолетлар янып төшә, солдатлар, иң кызганычы, гади халык һәлак була. Сугышта катнашкан илләргә табутлар кайта.

Безнең ил әлегә бөтен дөньяны тетрәткән бу сугышта турыдан-туры катнашмый. Әмма Гыйрак гаскәрләре безнең ракеталар белән сугыша. Кайчандыр без саткан хәрби кораллар алар... Фарсы култыгындагы шартлаулар кайтаваз булып Балтыйк буенда яңгырый. Нихәл итмәк кирәк, шартлаулар, атышлар, үлем һәм күз яшьләре үзебезнең илдә дә җитәрлек. Фаҗига арты фаҗига, бәрелеш арты бәрелеш, үлем арты үлем... Алма-Ата, Сумгаит, Карабах, Тбилиси, Фирганә, Ош, Көньяк Осетия... Үзара бәрелешләр, кан коеш, җан кыеш республикадан республикага күчә. Литва фаҗигасе безнең күңелләрне яңадан тетрәндерде. Үзебезнең солдатлар үзебезнекеләргә ата. Үзебезнең автоматлар, үзебезнең танклар үзебезнең күкрәкләргә, үзебезнең йортларга төбәлгән. Вильнюста яңадан атыш, яңадан корбаннар... Рига. Тагын кораллы бәрелеш, тагын үлем, тагын яралылар... Таллинн. Анда да шартлау тавышлары ишетелә... Балтыйк буе халыкларының ирекле илдә яшиселәре килә. Үзләренең бәйсезлеге өчен көрәшә алар. Каршыңда автоматлы солдатлар басып торса, барыр юлыңны авыр танклар бүлсә, азатлыкның кадере арта гынадыр, мөгаен.

Бәйсезлекнең юллары шома гына түгел шул. Каршылыклар адым саен туарга гына тора, кара көчләр бәйсезлекне җае чыккан саен буарга гына тора. Балтыйк буендагы соңгы вакыйгалар шул хакта сөйли. Кем ата? Кем приказ бирә? Ни өчен? Беркем берни белми. Беркем бернәрсә өчен дә җавап бирми. Конституция санга сугылмый. Законнар үтәлми. Президентның указларын күпләр тыңламый. Зур республикалар кечерәкләргә ирек бирми. Олы халыкларның кечерәкләрне танныйсы килми. Ләкин һәр халыкның, олы халыклар кебек үк, бәйсез рәвештә яшисе килә. Бу — халыкларның табигый омтылышы һәм хокукы!

Балтыйк буенда яңгыраган автомат тавышлары күңелгә шом сала. Анда безнең дә туганнарыбыз яши, якташ егетләребез хезмәт итә. Бу хәвефле көннәрдә мин үзебезнең Татарстаныбызны уйлыйм. Тыныч, сабыр холыклы, акыл белән эш итүче, үзенә дә, күршеләренә дә бары тик иминлек кенә, муллык кына теләүче республикабыз өчен, аның бүгенгесе һәм киләчәге өчен борчылам. Фарсы култыгында сугыш барганда, Балтыйк буенда үз-үзебез белән көрәшеп ятканда, кемнең генә күңеле тыныч булыр икән?!

30 гыйнвар, 1991

Һау-һаулап килә Яңа ел!

Белмим, сезгә ничектер, минем үземә Җир шары гадәттәгедән тизрәк әйләнә башлады шикелле. Күз ачып йомарга өлгермисең, еллар үтә дә китә, үтә дә китә. Чираттагы Әтәч елы да койрыгын гына күрсәтеп калды. Әлләниләр эшләрбез дип әтәчләнгән идек тә, ул кадәр булдырып булмады әле. Алай да елны бушка уздырмадык үзе. Малайлар-кызлар тагын бер яшькә үсте, без үзебез тагын бер яшькә олыгайдык. Әти-әниләребез, әби-бабаларыбыз бер яшькә картайдылар. Суверен Татарстаныбызга өч яшь тулды. Дәүләт гимныбыз туды. Балаларның сәнгать фестивале булды...

Урам тулы чит ил машиналары. Кибетләрнең киштәләре чит ил әйберләреннән, чит ил ризыкларыннан сыгылып тора. Өсләребездә импортный чүпрәк-чапрак. Бик теләсәң, урам буйлап авыз тутырып «Сникерс», «Марс» ашап йөрергә мөмкин. Телевизордагы кебек. Бик теләсәң, матур савытлы «Кока-Кола», «Пепси-Кола», «Фанта» кебек әллә нинди тәмле сулар эчәргә була. Кибетләр, киосклар тулы алар. Чит ил балалары гына эчкәндә түгел. Акча да бер букча бездә. Ленин бабай башы төшкән акчаларның кадере бар иде, ике башлы бөркет төшерелгәннәрнең бәясе бөтенләй юк. Мең сумлыкларны без элек төштә дә күрми идек. Хәзер әнә бер шоколад та 1000 сум тора, ачуым да бер килмәгәе!..

Ә менә сәясәткә килгәндә, эшләребез тагын да авыррак, катлаулырак, четереклерәк, хәвефлерәк һәм, әлбәттә инде, шау-шулырак. Олы йортта ни булса, кече йортта шул булыр дигәндәй, Рәсәйдәге хәлләр безгә дә тәэсир итми калмый. Анда исә талашалар, сугышалар, бер-берсен утка тоталар. Кыскасы, чын-чынлап революцияле уйныйлар. Рәсәй парламентын атып тараттылар. Монысы әйбәт түгел, безгә шәп парламент кирәк, дигәннәр иде, әлеге сайлауларда Дәүләт Думасына да, Федераль Советка да элекке депутатлар, элекке коммунистлар, шовинистлар һәм яңа фашистлар кереп тулды. Жириновский үзе генә дә ни тора! Әлбәттә, демократлар да бераз бар араларында... Аларның демократлыкларын әйтер идем инде. Берсеннән дә өмет юк. Барысы да шул бер чыбыктан куылган.

Безнең Татарстанда хәлләр ярыйсы әле. Ачтан үлмәскә тырышабыз, һәр кешене социаль яктан якларга, иминлекне сакларга омтылабыз. Халыкларыбыз, шөкер, үзара тату яшиләр. Рәсәй сайлауларында катнашмавыбыз, Рәсәй Конституциясен кабул итмәвебез шулай ук куанычлы вакыйга. Димәк, суверенлыкны күбебез яклый дигән сүз...

Эт елына кереп барабыз. 1994 ел безне өреп каршы ала. Һау-һаулап Яңа ел килә. Маэмай елыннан да әйбәт ел булмас әле, Аллаһы бирсә, менә күрерсез. Эт көнендә калмабыз, этләшмичә генә, тешләшмичә генә, шыңшымыйча гына яшәрбез дип уйлыйм. Әнә, ишетәсезме, Иске ел белән Яңа ел очраша:

— Кик-ри-кү-ү-үк!

— Һау-һау, һау-һау!

29 декабрь, 1993

Туган тел бәйрәме

«Газизләрдән газиз, изгеләрдән изге туган телем, мин бу бәйрәмгә синнән гафу сорарга килдем. Булдыралсаң, кичер син безне — фәкыйрьләреңне. Без бит сине шушы хәлгә төшердек, без бит сине тоткын шикелле өйләребездә биклэп тоттык, без бит сине җәмгыятебезнең иң кирәк урыннарыннан куып чыгардык, без бит сине дәүләт күләмендә хәл ителә торган биек йортларга якын да җибәрмәдек. Телем-телем итеп телдек без сине, газиз телем. Кичер син безне!

Бу ялваруларым сине оныткан, сине санга сукмаган, синнән оялган милләттәшләрем исеменнән дә, үзләре дә урыслашып беткән, балаларын да, онықларын да шул юлга этәргән татарлар исеменнән дә, сине законнан тыш дип игълан иткән, сине мәктәпләребездән, балалар бакчаларыннан куып чыгарган бәгъзе иптәшләр исеменнән дә...

Газиз телем, без сине имгәтеп, гарипләндереп бетердек түгелме? Сине танымаслык хәлгә китердек түгелме? Кол Галиләр кайтса, телдән язарлар иде. Тукайлар кайтса, сине танымаслар иде. Җәлилләр кайтса, рәнҗерләр иде безгә. Әле дә ярый алар күрми, әле дә ярый бабаларыбыз белми бу дөньяда безнеңниләр белән шөгыльләнеп ятканыбызны. Югыйсә күпме ләгънәт сүзләре ишеткән булыр идек...

Телләр күп ул бу дөньяда, әмма синең кебеге булмас. Минем өчен синнән дә затлысы, синнән дә татлысы табылмас. Булса да, анысы барыбер чит-ят, үги тел булыр. Башка телгә минем ата-бабамнарның моңы, аларның ачы газабы, өмет-хыяллары сеңмәгән. Фәкать син генә минем туган телем!

Газиз телем, алай да син исән әле. Шөкер, бөтенләй үк бетмәдең әле. Сине саклаучылар булмады түгел, булды. Үзебез синнән йөз чөергәндә дә, чит мәмләкәтләрдә яшәүче туганнарыбыз саклады сине. Без язарга курыкканда да, Башкортстанның олуг шагыйре Нажар ага Нәҗми яклап чыкты сине. Галимнәребез, әдипләребез саклады. Татар авыллары алып калды».

Туган тел бәйрәмендә сөйләдем мин әлеге сүзләремне. «Ватан» җәмгыяте оештырган бу бәйрәм туган телебезгә, аның язмышына багышланган иде. Туган тел кичәләрендә, әдәби-музыкаль бәйрәмнәрдә еш катнашканым бар югыйсә. Казан мәктәпләрендә, аерым классларда, район күләмендәге фестиваль-смотрларда... Әмма мондыенда катнашканым юк иде әле. Үзенең зурлыгы белән, мөһимлеге, актуальлеге белән башка бәйрәмнәрдән аерылып торды ул. Үзе концерт та, митинг та, кичә дә, үзе бик җитди мәҗлес тә, үзе олы бер милли бәйрәм дә иде Академия театры мәйданында.

Илебезнең төрле төбәкләреннән, җиребезнең төрле илләреннән килгән милләттәшләребез дә бизәп җибәрде бәйрәмне. Туган телебезне Төркия, Япония, Финляндия, Австралия, Көнбатыш Германия кебек ерак илләрдән җыелган татарлар авызыннан ишетү бигрәк тә тәэсирле булды. Чыннан да, ул илләрдә дә яши икән, яңгырый икән бит безнең телебез. Әйе, әйе, митингта да алар безне татар телен саклап калырга чакырып сөйләделәр. Югыйсә туган телнең кирәклеген хәзер үзебез дә аңлый башладык бугай инде. Шулай булмаганда, туган тел бәйрәменә меңләгән кеше җыелмас иде!

4 июль, 1990

Рәттән дүрт «5»ле!

Әле кайчан гына газетабызның 5 нче, 55 нче, 555 нче саннары басылып чыккан иде. Инде менә «Сабантуйның биш мең дә биш йөз дә илле бишенче саны да дөнья күрде. Безнең бүгенге саныбыз, күрәсезме, фәкать «5»леләрдән генә тора: уңнан укысаң да — 5555, сулдан укысаң да — 5555. Берьюлы дүрт «5»ле! Мондый тәңгәллек гомергә бер генә тапкыр була торгандыр ул. Карагыз әле, ничек матур булып, күз явын алып, балкып торалар! Нәкъ менә сезнең көндәлекләрегездәге «5»ле билгеләре шикелле. Сезнең берьюлы дүрт «5»ле алганыгыз да юктыр әле. Алсагыз да сирәкләрегезгә генә эләгәдер андый бәхет. Ә менә безнең газетабызга бүген рәттән дүрт «5»ле билгесе куйдылар. Бу — Вакыт Галиҗәнапларының безгә биргән бәясе, безгә куйган билгеләре. Горурланырлык та, бераз гына мактанып та алырлык вакыйга.

Ә бит әлеге 5555 санының һәрберсенә күпме көч, күпме хезмәт куелган! Ничә буын журналистларыбызның, редакция хезмәткәрләренең йокысыз төннәре, алар узган йөзләгән, меңләгән чакрымнар, исәпсез-хисапсыз очрашулар, редакциягә укучыларыбыздан килгән меңләгән хатлар: хәбәрләр, шигырьләр, әкиятләр, хикәяләр, рәсемнәр... Уйлый башласаң, исләрең-акылларың китәрлек. Нинди генә талантлы журналистлар, шагыйрьләр, язучылар эшләмәгән бездә?! Бездә әсәрләрен бастырмаган берәр татар язучысы, шагыйре калды микән? Юктыр, мөгаен...

Безнең газета битләрендә иң күп басылучы Шәвәли дигән малай булырга тиеш. Бездә туган, бездә үскән ул Шәвәлигә дә 55 яшь туладыр инде. Шәвәли дигәннән, Татарстанның халык шагыйре, Шәвәлинең әткәсе Шәүкәт Галиев 5 томлык сайланма әсәрләрен бастырып чыгарды. Анда Шәвәлигә багышланган 55+55 шигырь урын алган. Шәүкәт абыебыз исә Г.Х.Андерсен исемендәге халыкара Почетлы диплом иясе дә бит әле. Ә бүген бөек әкиятчебез Г.Х.Андерсенның туган көне. Җитмәсә, халыкара балалар китабы көне дә. Бәйрәм өстенә бәйрәм! Менә бит нинди истәлекле көндә чыга безнең 5555 нче саныбыз.

Гомумән, 5 саны һәрвакыт безнең юлдашыбыз булды: хәзер дә газетабызның һәр санын «5»лелек итеп чыгарырга тырышабыз, һәм бүгеннән үк газетабызның 55555 нче санын чыгару өчен әзерлек эшләрен башлаячакбыз. Ходай кушса, халкыбыз, республикабыз исән булса, ул көннәр дә килеп җитәр. Һичшиксез килеп җитәр!.. Тик ул санны бездән соң килгән яңа буын чыгарыр инде. Туктагыз әле, чыннан да, ничәнче елда чыгачак соң әле безнең 55555 дип язылган илле биш мең дә биш йөз дә илле бишенче бәйрәм саныбыз? Бәлки, сез үзегез санап чыгарырсыз? Сез бит «5»кә генә укыйсыз түгелме соң?!

2007

«Сабантуй»да сынатмыйк!

«Яшь ленинчы» битләрен актарып утырам. Ниләр генә юк анда! Кемнәр генә язышмаган да, кемнәр турында гына язылмаган, нинди генә хәлләр тасвирланмаган да, кайсы гына вакыйгалар яктыртылмаган ул битләрдә... 70 еллык Татарстан тарихы, татар балаларының совет чорына туры килгән шатлык-кайгылары, өмет-хыяллары... Совет иле кичергән авырлыклар, фаҗигаләр, дәһшәтле сугыш еллары... һәммәсе дә бар анда. Бүген инде ул сәхифәләрне мыек астыннан гына елмаеп та, ул чаклардагы вакыйгаларга, малайларның-кызларның кылган эш-гамәлләренә ышанмыйчарак та укырга мөмкин. Безнең әби-бабаларыбыз, әти-әниләребез нинди беркатлы булганнар, янәсе. Ленинга, Сталинга, партиягә, коммунизмга ышанып яшәгәннәр, янәсе...

Әйе, бүгенгедән чыгып караганда, алар чыннан да беркатлы булганнар. Әмма ул малайлар-кызлар матур киләчәккә чын күңелдән ышанып яшәгәннәр, шул матур көннәр тизрәк килсен дип тырышканнар. Дулкынлана-дулкынлана күкрәкләренә октябрят значогы кадаганнар, муеннарына пионер галстугы бәйләгәннәр, зур горурлык хисләре белән комсомол билеты йөрткәннәр, һәм, без уйлаганча, барысы да начар, барысы да ялгыш булмаган. Ул чакта да малайлар-кызлар сезнең кебек үк уйнаганнар, шаярганнар, күңел ачканнар, укыганнар, эзләнгәннәр, хыялланганнар, иҗат иткәннәр.

«Яшь ленинчы» битләрен актарганда, ул чорлардагы балаларның көчле рухына, иҗат дәртенә, пионер ялкынына сокланып туймалы түгел. Юкка гынамыни газетабызның яшь хәбәрчеләре соңыннан танылган әдипләр булып киткәннәр. Татарның атаклы әдәбият-сәнгать әһелләре «Яшь ленинчы»ны чыгаруда турыдан-туры катнашалар. Безнең редакциядә эшләгән, бездә иҗат мәктәбе узган каләм ияләрен бүген бөтен татар матбугатында күрергә була.

Газетабызның яңа исеменә дә өйрәндек. Дүрт ел бит инде «Сабантуй» булып чыгабыз. Ил тормышы белән, халык язмышы белән янып яшәгән балалар газетасы бүген дә заман белән, балалар белән бер сафта атлый. Заманалар үзгәрә, балалар да үзгәрә. Алар белән бергә газета да үзгәрә бара. Төп максатыбыз гына, кыйблабыз гына шул килеш кала — чын кеше тәрбияләү! «Сабантуй»да чыныгу алган малайларыбыз-кызларыбыз Тормыш дигән олы Сабантуйда сынатмаслар, туган Татарстаныбызның чын патриотлары булып үсәрләр.

1994

**Төрле-төрле язмалар**

Кемгә кирәге бар ул Васьканың?

Кешелеклелек сыйфатлары кечкенәдән үк тәрбияләнә. Төрле бөҗәкләрне, кошларны, җәнлекләрне яратып үсүчеләр генә, көчсез, ярдәмчесез дусларын явызлардан саклый белүчеләр генә Ватанын, туган җирен, халкын чын мәгънәсендә ярата ала, шәфкатьле, яхшы кеше булып үсә ала икән. «Кемгә кирәге бар ул Васьканың?» исемле фильмны карагач, нәкъ әнә шул фикергә киләсең. Фильм кешеләр белән җәнлекләр арасындагы дуслык турында.

...Малай өйгә песи баласы алып кайта. Әтисе исә аны үтерә дә канауга чыгарып ташлый. «Кемгә кирәге бар ул Васьканың?» — ди ул. Малай бу кешене шәфкатьсезлеге өчен күралмый башлый.

— Безгә шәфкатьсез кешеләр кирәкми. Безгә батыр һәм мәрхәмәтле кешеләр кирәк, — ди СССРның халык артисты С.В.Образцов. Ул әлеге малайның хатына җавап итеп шушы фильмны эшләгән.

Безнең күз алдыбыздан дулкынландыргыч күренешләр үтә.

...Урам буйлап кара күзлек кигән кеше бара. Янәшәсендә — акыллы, хуҗасына турылыклы эте.

— Колли — минем күзләрем, — ди күзләрен Курск дугасында югалткан В.П.Белов. — Ул мине илле маршрут буйлап йөртә.

Менә Красноярск краендагы имгәтелгән, авырган хайваннарны дәвалый торган «Айболит больницасы». Бакудагы Кинг исемле арыслан яши торган Берберовлар гаиләсе. Овчаркалар өйрәтүче яшь кенә чик сакчылары...

Без фильмда шәфкатьсез, кансыз кешеләр белән дә очрашабыз.

— Хайваннарны җәзалаучы һәрбер малай җинаятьче булып китмәскә дә мөмкин. Әмма һәрбер җинаятьче шуннан башлаган, — ди С.В.Образцов.

Фильм безне кешелеклелеккә, шәфкатьлелеккә чакыра, яхшы кешеләр булырга өнди.

27 февраль, 1974

«Гайни әби» кем шигыре?

Безнең редакциягә укучыларның әдәби язмалары бик күп килә. Алар арасында шигырьләр дә, хикәяләр дә, әкиятләр дә була. Без аларны җентекләп карап чыгабыз, кат-кат укыйбыз. Матурраклары булса, сөенә-сөенә газета битләрендә бастырып чыгарабыз. Дөрес, һәрбер язма бер үк дәрәҗәдә уңышлы да булмый. Бу — табигый күренеш. Укучылар әдәбият теориясенә төшенеп җитмиләр, шигырь техникасын белмиләр. Алар күңелләре белән тоеп кына, сиземләү буенча гына язалар. Ничек кенә булмасын, әдәбият сөюче укучыларның шигъриятне яратулары безне шатландыра. Аларга аз булса да ярдәм итәргә тырышабыз, киңәшләр биреп хатлар язабыз.

Бүген исә әдәбиятны, шигъриятне яратучы булып күренергә тырышучылар турында, әдәби караклар турында сөйлисе килә.

Менә Чаллы районы Мусабай-Завод мәктәбенең V класс укучысы Сәрия Мәүләвиева хаты. Ул үзенең шигырен «Яшь ленинчы» газетасы битләрендә бастырып чыгаруны үтенгән. Дөрес, Сәрия бик матур шигырь җибәргән. Ләкин үзенекен түгел, Нәкый ага Исәнбәтнең шигырен күчереп җибәргән ул. Шуңа күрә без аны газетада бастырмадык. Кызганычка каршы, Сәрия кебекләр очрый әле. Мәсәлән, Чувашиянең Козлов районы Альменево авылыннан VII «Б» класс укучысы Фирдания Әшрәфҗанова Гамил Афзалның «Гайни әби» исемле шигырен ике тапкыр күчереп җибәрде инде. Шушындыйлар рәтенә Буа районы Яңа Чәчкап мәктәбенең VIII «Б» класс укучысы Ранис Газизовны да кертергә кирәк. Ул Рушания Гатинаның («Ялкын» журналы, 1973 ел, 4 нче сан) «Курчаклар» исемле хикәясен күчереп җибәргән. Ә менә Лаеш районы Татар Янтыгы авылыннан IV класс укучысы Гөлсинә Хәмидуллина Линарис Лероновның («Яшь ленинчы», 1974 ел, 9 нчы сан) «Хыялым» исемле шигырен үзенеке итеп тәкъдим итә.

Мондый укучылар тагын бар әле. Менә алар: Аксубай районы Яңа Ибрай мәктәбенең V «А» класс укучысы Рәис Камалов; Сарман районы Иске Кәшер мәктәбенең IV класс укучысы Резеда Кәримова; Баулы районы Бәйрәкә мәктәбенең III «Б» класс укучысы Зөлфия Гәрәева; Куйбышев районы Иске Рәҗәп урта мәктәбенең V «В» класс укучысы Кәшифә Баһманова; Алексеевск районы Түбән Майна мәктәбенең III класс укучысы Гөлсинә Латыйпова; Азнакай районы Татшуган мәктәбенең IV «А» класс укучысы Алик Лукин; Чүпрәле районы Иске Кәкерле мәктәбенең III «А» классы укучысы Фәридә Хәлиуллина; Яңа Кәкерле мәктәбе укучысы Гөлнар Сафина; Шатрашан авылыннан IX класс укучысы Җәүдәт Җәләлов; Аксубай районы Яңа Дума авылыннан VII «Б» классы укучысы Әнисә Әюпова; Саба районы Тимершык авылыннан VII класс укучысы Назиф Юсупов; Мамадыш районы Шәдче мәктәбеннән II класс укучысы Әлфинә Тимергалиева; Башкортстанның Туймазы районы Камыштау авылыннан Зилә Ахунҗанова.

Бу укучылар шагыйрьләребезнең, шулай ук «Яшь ленинчы»да һәм «Ялкын» журналында чыккан иштәшләренең шигырьләрен тулысынча яки аерым юлларын күчереп җибәргәннәр. Кыңгыр эш кырык елдан соң да беленә, диләр бит. Алар үзләренең гаепләрен, шигырь язуның авыр һәм катлаулы хезмәт икәнен аңларга тиешләр.

20 апрель, 1974

Рәхмәт сиңа, музыка!

Залга әллә нәрсә булды. Яңа гына колакны ярып кергән шау-шулар, пышылдаулар сүнде. Зал кинәт кенә уйчанланды, җитдиләнде, тынды. Күңелләр дә ниндидер олы бер үзгәреш, могҗиза көтеп тынып калды.

Беренче аккордлар... Алар әле ярсырга, дулкынланырга да өлгермәгән хисләрне телеп үттеләр. Утлы, кайнар очкыннар булып залга тылсымлы авазлар чәчрәде, зал үткен, ялкынлы авазлар белән тулды. Алар төрле төстәге вак-вак йолдызлар сыман күзгә күренеп киткән кебек булдылар. Бу авазларда көчле дәһшәт тә, куәтле күкрәү да җитәрлек. Кара әле, күкрәүнең дә үз моңы, үз аһәңе бар икән ләбаса! Рояль телләре тетрәнеп-тетрәнеп китә. Алар әйтерсең лә үзләреннән-үзләре басылалар. Рояль янында утырган кызый ул телләргә көч, куәт кенә биреп тора кебек. Шушы кеп-кечкенә, нәзек кенә нәфис бармаклар шундый олы көчкә ия дип кем уйлар... Ә күңелләрдә — моң-зар давылы! Ул давылны теләсәң дә тыеп булмый...

Үзәк өзгеч тавыш белән скрипка елый. Нәрсәгәдер моңлана, әрни, сыкрый ул. Кемнәрне генә елатмаган да, кемнәрне генә юатмаган бу скрипка моңнары! Ул исә һаман елый. Аңа башкалары кушыла. Залда талгын гына моң тирбәлә. Таш күңелләрне дә эретерлек шушы моң залда утыручы нечкә күңелләргә ничек тәэсир итмәсен инде. Рояль аккордларыннан әле булса айнып җитә алмаган кызыйның күңел түренә скрипка авазлары үтеп керде. Бу минутта аның бик тә елыйсы килә иде. Тик кызый аны үзе дә сизмәде. Ул әтисенә борылды. Әти кеше дә скрипка моңнарыннан оеп, ят бер дөньяда — моңнар дөньясында йөзә иде. Кызый әтисенә гаҗәпләнеп карады. Ни булган аңа дип уйлады ул. Әтисенең мондый чагын күргәне юк иде аның. Ул әтисенә ныграк сыенды. Ә моң агылды да агылды.

Сәхнәгә укучылар чыга. Бертөсле киемнән, бер-берсенә охшаган укучылар. Бу — хор. Аларның бөтенесенә дә бер үк төсле аваз, бер үк төсле халәт хас. Ә бит аларның теләкләре дә, максатлары да бер үк. Шуңа күрә җырлары да матуррак, көчлерәк яңгырый. Зал яктырып китә, йөзләргә нур, елмаю куна. Хорга залдагылар кушыла: «Һәрвакыт булсын кояш!»

...Сәхнә бушап калды. Музыка тынды. Ләкин ул безнең күңелләрдә дәвам итә, безнең йөрәкләрдә яңгырый. Рәхмәт сиңа, дустыбыз музыка!

20 ноябрь, 1974

«Күзләр үтте, кышлар җитте...»

(Редакциягә килгән шигырьләр турында)

Редакциягә шигырьләр килә. Төрле шигырьләр. Арада оста, шома язылганнары, рәхәтләнеп укырлыклары очрый. Андыйларны укып шатланасың, укучының һәрбер табышына,

һәрбер яңа бизәгенә сөенәсең. Шулай да шигырьләрнең күбесе, гадәттә, гади сүзләр тезмәсеннән, эшләнмәгән, уйланмаган юллардан тора. Алар чын әдәби әсәр түгел әле. Булсын! Бу бит укучыларның беренче адымнары гына, беренче омтылышлары гына. Шулай булуга да карамастан бу инде беренче тапкыр дөньяга үз мөнәсәбәтеңне белдерү: Чили фашистларына нәфрәтеңне игълан итү, матурлыкны сиземләү, олы әдәбиятны, гүзәл сәнгать дөньясын аңларга омтылу, табигатебезнең кадерен, Кояшны, кояшлы таңнарны, кояшлы Ватаныбызны күз карасы кебек саклау кирәклеген тою нәкъ менә шушы беркатлы, дүртьюллык шигырьләрдән башлана да инде. Укучы күңелендә гражданлык хисләре, эстетик һәм рухи зәвык тәрбияләнә. Ул дөньядагы гаделсезлекләргә дә, изгелеккә дә, гүзәллеккә дә битараф түгел. Шушы шигырьләр белән бергә көрәшче дә, матурлыкка табынучы да, коммунизм төзүче дә үсә.

Сез газетабыз битләрендә укучыларның иҗаты белән танышып барасыз инде. Шуңа күрә бу күзәтүдә шигырь язучыларның күбесенә уртак булган кайбер кимчелекләр, җитешмәгән яклар турында әйтеп китәсе килә.

Көз җиттеме, редакциягә көз турында язылган шигырьләр ява башлый. Бик күп килә алар. Кулына каләм ала торган һәр укучы көзгә багышланган шигырь язып калырга тырыша. Кыш якынлашса да, яз, җәй җитсә дә, шул ук күренеш. Бәйрәм вакытларында исә редакция өстәле бәйрәм шигырьләре белән тула. Хикмәт нәрсәдә соң? Минемчә, моның сере гади генә. Укучыларның күпчелеге иске, таныш темаларга язарга ярата. Белгәнеңне, укыган шигырьләргә охшатып, әзер шигырь калыбына саласың да куясың. Яңа тема эзләп торасы юк. Менә шуңа күрә әйбәт шигырь килеп чыкмый да инде.

Шушылардан, ягъни уртак темалардан уртак кимчелекләр, уртак җитешсезлекләр дә килеп чыга. Шигырьләрнең күбесе тапталган юллардан, искереп беткән эпитетлардан, метафоралардан гыйбарәт. Көз турындагы шигырь, һичшиксез, «Җәйләр үтте, көзләр җитте» дип башлана. Әгәр дә кышка багышланган булса, «Кыш та килде, җир ак тунын киде» дигән сүзләр булмый калмый. Бер үк эпитетларны, бер үк чагыштыруларны туган авылга, туган җиргә, туган илгә багышлап язган шигырьләрдә дә еш очратырга мөмкин. Күренеп тора, шигырь язучылар туган авылларын яраталар, хөрмәт итәләр. Ләкин укыганнан соң, алар барысы да бер үк авыл турында язмадылар микән дип шикләнеп куясың. Ә бит һәр авылның үз матурлыгы, кабатланмас ягы булырга тиеш. Бер авыл, мәсәлән, урман буенда, бөдрә каеннар арасында чумып утыра, икенчесе елга буенда — тар гына тыкрыктан төшүгә, тын гына ага торган елгага килеп чыгасың. Анда суга иелеп, таллар битен юа. Өченче авыл таулар арасына, үзәнлеккә урнашкан. Аның өстендә бөркетләр бөтерелә. Авылларның берсе бик зур, икенчесе кечкенә, һәркайсында бер-берсенә һич тә охшамаган кызыклы, эшчән, уңган кешеләр яши. Аларны күрә белергә, күрсәтә белергә генә кирәк.

Табигать һәрвакыт үзгәрештә. Сезнең яңгырдан соңгы табигатьне күзәткәнегез бармы? Бөтен тирә-юнь яңартылган, өр-аңа буяу белән йөгертелгән кебек. Буявы да кибеп бетмәгән шикелле елкылдап тора. Бөтен җир сафланып, ачылып киткән. Ә бит бернәрсә дә үзгәрмәгән, бары яңгыр гына явып үткән.

Яисә туган авылыгыздан бер генә атнага аерылып тордыгыз ди. Сез кайтуга авылыгыз, һичшиксез, алыштырып куйган кебек булыр. Үзегез дә аптырап калырсыз. Бу матурлыкны моңа кадәр нишләп күрмәдем икән, дип уйларсыз.

Әгәр да син игътибарлы икән, болар сине дулкынландыра, уйландыра, күңелдә шигырь юллары туа.

Редакциягә килгән күпчелек шигырьләрдә таушалган, тапталган, күптән искереп беткән чагыштырулар була. Ә бит чагыштырулар гаҗәп тә күп! Чөнки дөньяны һәркем үзенчә күрә, туган илен дә, авылын да, әнисен дә үзенчә ярата. Шулай булгач, шигырьләр дә төрле булырга тиеш бит. Мәсәлән, ярга килеп бәрелүче ярсыган дулкынны берәүләр котырган арысланга, икенчеләр үкереп-үкереп бәргәләнгән үгезгә охшатырга мөмкин. Яисә кояшта ялтыраучы пыяла кисәген асылташ белән чагыштырырга була. Һәм, киресенчә, күңелсез, боек минутларда асылташларның да гади пыяла кисәге булып күренүе бар. Кыскасы, эзләнергә генә кирәк.

Шигырь язу өчен тагын берничә сыйфатның булуы мәҗбүри. Кеше иң элек күрә белергә, соклана белергә, ярата һәм нәфрәтләнә белергә тиеш. Җырчы, композитор тойган моңны тойсаң гына, рәссам күрә алган гүзәллекне күрә белсәң генә, шулар белән рухланып, сабыйларча шатлана белсәң генә, әйбәт шигырь язып буладыр ул.

Мәкаләдә күрсәтелгән кимчелекләр түбәндәге укучыларның шигырьләренә дә хас. Шул сәбәпле алар газетада басылмадылар: Дания Газизова, Илдус Фатыйхов, Заһид Мәхмүтов, Мөнир Нәбиев, Мөнир Шәмсетдинов (Кукмара районы); Нәфикъ Галәвиев, Корбан Гыйззәтуллин, Ринат Зыятдинов, Рамил Җәләлов (Саба районы); С.Гобәева, Азат Гаязов (Актаныш районы); Вакыйф Мофаһаров, Елизавета Малова, Сәрия Гәрәева, Әлфир Йосыпов (Мамадыш районы); Илгиз Галиев, Гөлфия Сабирова (Буа районы); Рәйхат Харисов, Камилә Илдарханова (Түбән Кама районы); Самат Сафиуллин, Фазыл Нуриев, Мөдәррис Маслахов, Камилә Шәрапова, Фәндәс Кәримов (Чирмешән районы); Зәмфира Локманова, Инсөя Әхкиямова, Илсөяр Габдрахманова (Минзәлә районы); Азия һәм Алмазия Хәсәновалар, Тәскирә Шәнгәрәева (Зәй районы); Рәүхәт Гәрәев, Гөлфинә Сибгатуллина, Диләрә Вәлиева, Розалия Биктаһирова (Апас районы); Заһит Шакиров, Тәлгать Сабиров, Халидә Гыйздәтова (Мөслим районы); Равил Хәсәншин, Әлфирә Шамбазова, Әлфия Баһавиева (Чаллы районы); Гөлфәния Нурмиева, Нурзидә Латыйпова, Чулпан Мөхәммәтҗанова (Балтач районы); Шамил Сәйфетдинов, Гөлзадә Гайнуллина, Мөнәвәрә Гайнетдинова (Әлмәт районы); Миргазиз Садыйков, Рузилә Хуҗина (Балык Бистәсе районы).

14 декабрь, 1974

## «Кызыл ромашка»

Казанның 31 нче мәктәбендә яшь җәлилчеләр укый. Алар монда Муса Җәлилнең һәм аның көрәштәшләренең батырлыгы белән рухланып, канатланып яшиләр. Алар кылган һәммә әйбәт эш, изге башлангыч Җәлил батырлыгына барып тоташа...

Мәктәптә шундый матур бер традиция яшәп килә: М.Җәлил шигырьләрен иң яхшы сөйләүчеләргә конкурс уздыру. Ел саен мәктәп залында татарча да, русча да Җәлил шигырьләре яңгырый. «Вәхшәт», «Алман илендә», «Дуска», «Җырларым»... Шунысы кызык, конкурста иң күп укылган шигырь һәрчак «Кызыл ромашка» була. Менә шуңа күрә дә яңа гына төзелгән яшь җәлилчеләр штабына «Кызыл ромашка» дип исем бирергә булалар. Штаб членнарына да ошый бу исем. «Кызыл ромашка» штабының тарихы моннан ун ел элек әнә шулай башлана.

Штаб эшләгән эшләрне саный китсәң, тиз генә санап та бетерә алмассың. Аларның кайберләрен генә атасаң да, штаб төзүгә, музей оештыруга күпме көч куелганын, күпме вакыт сарыф ителгәнен күзалларга мөмкин булыр иде. Уйлап карагыз, башта бит берни дә булмаган. Бөтенесе дә пионерларның гап-гади теләгеннән, кызыксынуыннан гына, аларның олы бер омтылышларыннан гына башланган. Ә инде башлап йөрүчеләргә берни дә җиңел генә бирелми. Пионерлар иң элек кул астында булган китапларны, фоторәсемнәрне җыйганнар, Җәлилне күреп белгән язучылар белән очрашулар уздырганнар. Азлап-азлап музей өчен кирәк әйберләр туплаганнар. Материаллар күбәйгән саен, Җәлил турында күбрәк белгән саен үзләренең дә кызыксынулары арта төшкән. Пионерлар Мәскәүдә Әминә апа Җәлилова белән Чулпан янында булганнар, аларның истәлекләрен язып алганнар. Шагыйрьнең туган авылы Мостафага барганнар. Кечкенә Муса уйнап үскән болыннарда йөргәннәр, ул эчеп үскән чишмәнең суын эчеп караганнар, авылдашлары белән сөйләшеп утырганнар. Оренбургта Җәлилнең сеңлесе Хәдичә апа белән очрашканнар...

«Кызыл ромашка» мәктәптәге гади штаб кына түгел. Аны илебездәге бөтен яшь җәлилчеләрнең дә уртак штабы яисә үзәк штабы дияргә мөмкин. Нишләп алай дисезме? Беренчедән, ул иң беренче штабларның берсе. «Кызыл ромашка» төзелгәндә андый штаб беркайда да булмаган әле. Икенчедән, илебезнең төрле почмагында яшәүче яшь җәлилчеләр, хәтта чит илләрдәге яшь җәлилчеләр дә штаб белән элемтә тоталар. Киңәш сорап та, ярдәм сорап та язалар алар. Үзләре дә киләләр.

Эшләнгән эшләр санап бетергесез, эшлиселәре исә тагын да күбрәк, тагын да кызыклырак, мавыктыргычрак. Штаб членнары менә ничә еллар инде «Муса Җәлил» теплоходының экипажы белән элемтәдә торалар. Диңгезчеләр яшь дусларына хатлар, котлау телеграммалары җибәрәләр, бүләкләр салалар. Дуслык күптәннән дәвам итә, ләкин әлегә кадәр очрашып күрешкәннәре юк әле аларның. Шуңа күрә алдагы очрашуны түземсезлек белән көтәләр яшь җәлилчеләр.

Аннары пионерлар Новгородта да булдылар. Аларның исәбе элекке Волхов фронтында Җәлил эзләре буйлап походка чыгу иде. Ләкин аларга рөхсәт бирмәделәр. Ул урыннар әле булса миналардан чистартылып бетмәгән икән. Әмма яшь җәлилчеләр өмет өзмиләр. Алар Җәлил эзләре буйлап һичшиксез үтәчәкләр әле.

Бу көннәрдә дружина пионерлары аеруча бирелеп, тырышып эшлиләр. Барысы да олы юбилейга әзерләнә. Кичәләр, конференцияләр уздырыла. Музей аерым бүлмәгә күчерелде. Хәзер шуны җиһазландыру эше бара. Бүлмә эчендә камера эшләнгән. Җәлил утырган төрмә камерасына охшаган бу камерага укучылар тыныч кына карый алмыйлар. Җәлил шигырьләре нәкъ шушындый камерада язылган бит инде. Юбилейга һәр отряд бүләк әзерли. Мин I–III класс укучыларының бүләген карап утырдым. Ул бүләк — рәсемнәр альбомы. Җәлилгә багышланган рәсемнәр, Җәлилнең шигырьләренә иллюстрацияләр ясалган анда. Шулар белән танышканнан соң, укучыларның Җәлил тормышын, аның шигъриятен никадәр тирән аңлауларын тоясың. Әйе, укучылар Җәлилне яраталар, аның тормышын, иҗатын яхшылап өйрәнәләр, беләләр, аның батырлыгын үзләренә үрнәк итеп алалар. Укучылардан Җәлилнең кайсы гына шигырен сорасаң да, яттан сөйләп бирәләр, ирекле темага

сочинение язсалар, күбесе Җәлилгә багышлап яза. «Сез Җәлил батырлыгын кабатлый алыр идегезме?» — дигән соравыма да алар бер дә икеләнмичә: «Кабатлар идек!» — дип җавап бирделәр. Җәлил батырлыгын, җәлилчеләрнең батырлыгын бүген яшь җәлилчеләр, 70 нче еллар пионерлары дәвам иттерә...

Мәктәпкә килеп кергәч тә коридорның сул ягында Җәлилгә багышланган мемориаль стена бар. Стенада яшь җәлилчеләрнең 2006 ел укучыларына атап язылган хатлары саклана. Еллар узар. Киләчәк буын укучылары ул хатны алып укыр. Алар бүгенге пионерларның мактаулы эшләренә сокланып туймаслар, Җәлилгә багышлап шундый әйбәт музей оештырганнары өчен рәхмәт укырлар. Җәлил батырлыгы буыннардан буыннарга күчәр.

14 февраль, 1976

## Тыныч булсын дөньялар!

Тыныч булсын дөньялар! Гади генә шушы өч сүз һәркемнең күңелендә яшидер, мөгаен. Шушы өч сүзне эчтән кабатлап йөрүчеләр бардыр. Чөнки Тынычлык кешеләр өчен, бигрәк тә безнең өчен — совет халкы өчен — аеруча газиз, аеруча кадерле. Күпме кан түгеп, күпме гомерләр бәрабәренә яулап алынган тынычлык бит ул. Тынычлыкның кадере торган саен арта гына бара. Менә ничә еллар инде Ватаныбыз зәп-зәңгәр күк астында яши, эшли, иҗат итә. Кешеләр узган коточкыч сугышны онытмаганнармы әле? Яшьләр, балалар сугышның нинди афәт икәнен беләләрме, аңлыйлармы? Киләчәгебезнең якты, матур буласына ышаналармы алар? Менә шушы сорауларга җавап табарга теләп, без фотохәбәрчебез Николай Седов белән, Казан урамнарына чыгып киттек. Дөрес, без кешеләрнең нинди җавап бирәселәрен дә, нинди теләк белдерәселәрен дә алдан ук якынча белеп тора идек. Ни өчен дисәң, һәммә совет кешесе бер уй-хис белән, бер теләк белән яши бит. Шулай булса да, без сөйләшкән өлкән кешеләрнең дә, яшьләрнең дә җаваплары газета укучыларыбызны һичшиксез кызыксындырыр, уйландырмый калмас дип ышанабыз.

Бауман урамы. Бертуктаусыз халык ташкыны агылып тора. Кемдер эшкә ашыга, берәүләр кибетләргә кирәк-ярак алырга чыккан, һәркемнең үз мәшәкате, үз эше. Шулай да аларны бергә берләштергән уртак бер сыйфатны шунда ук чамаларга мөмкин. Ул — бәхетле йөзләр, үзләрен иркен, ышанычлы һәм тыныч сизү... Ә менә безнең сораулардан соң аларның йөзләре җитдиләнде, карашлары уйчанланды, киеренкеләнде.

Әнә ап-ак шәл бөркәнгән әби килә. Маһикамал Мәһдиева дип таныштырды ул үзен.

— Әбекәй, сугышны хәтерлисезме әле? — дип сорадык без аннан.

— Бик күп сугышларны күрдем инде мин, балалар, — дип башлады ул сүзен. — 80 яшь бит инде миңа. Герман сугышын да, гражданнар сугышын да күрергә туры килде. Соңгы

сугышта ирем ятып калды... — Әбинең күзләреннән яшьләр тамды. — Тагын нәрсә әйтим соң? Елларга иминлек бирсен инде, балалар. Дөньялар гына тыныч булсын!

Әйе, дөньялар гына тыныч булсын. Шул чакта барысы да әйбәт булыр. Шушы ук сүзләрне Бөек Ватан сугышы ветераны Гомәр ага Гыймазетдинов та кабатлады:

— Сугыш — үлем, сугыш — ачлык, сугыш — афәт ул. Мин аларны үз күзем белән күргән кеше. Фронтка киткәндә 19 яшь кенә иде әле миңа. Биш туган сугыштык без дошманга каршы. Икесе сугыш кырларында һәлак булды. Икесе сугыштан соң, авыр яралардан үлделәр. Мин үзем дә әллә ничә тапкыр үлем белән күзгә-күз очраштым. Өч мәртәбә авыр яраландым. Соңгы тапкыр Берлин урамнарында — 4 майда, сугыш беткән көннәрдә яраладылар.

Хмельницкий шәһәрендә Бөек Ватан сугышында һәлак булган геройларга һәйкәл куелган. Анда минем исем-фамилиям дә бар иде. 22 елдан соң мине пионерлар эзләп тапты. Шуңа кадәр мин һәлак булганнар исемлегендә йөргәнмен. Юк, ул сугышны оныту мөмкин түгел. Оныта алмыйбыз без аны. Шуңа күрә дә мин укучылар алдында еш кына чыгышлар ясыйм. Алар да белеп торсыннар.

Милиция өлкән лейтенанты Әсхәт Әһлиев безгә түбәндәгеләрне сөйләде:

— Мин җәмәгать тәртибе сагында торам. Әтиләребез (минем дә әтием сугыш ветераны) яулап алган шушы матур, тыныч тормышны тагын да матурлау — безнең изге бурычыбыз ул. Шуны аңлаучы яшьләрне, укучыларны күреп күңел куана. Шулай да кайбер укучылар бу хакта уйламыйлар әле. Әйтик, аларның кайберләре җәмәгать тәртибен бозалар. Трамвай-троллейбусларда ветераннарга урын бирмиләр. Ә бит без ветераннарны аеруча хөрмәтләргә тиешбез. Алар безнең матур киләчәгебез өчен үлемнең күзенә карап барганнар бит.

Казандагы 105 нче мәктәпнең тарих укытучысы Борис Сосновский:

— Без сугыштан соң туган буын. Үз күзләребез белән күрмәдек без ул коточкыч вакыйгаларны. Ләкин һәрбер совет халкының хәтерендә яши ул сугыш. Шуңа күрә дә без тыныч тормышның кадерен белергә, яңа сугышны булдырмаска тиешбез. XXV съезд материаллары белән танышканнан соң, бу өлкәдә партиябезнең армый-талмый көрәшүен күрәсең. Соңгы елларда гына коралсызлану, халыкара киеренкелекне йомшарту буенча никадәр эш башкарылды. Болар бит барысы да тынычлык хакына, бәхет һәм якты киләчәк хакына эшләнгән эшләр.

Мин Совет Армиясе сафларында хезмәт итеп кайттым. Анда хәзер Бөек Ватан сугышы солдатларының уллары, оныклары хезмәт итә. Алар тынычлык сагында. Аларга ышанырга була. Алар барда илебез күге тыныч булыр.

Инженер Рәиф Кадыйров улы Рөстәм белән ял итәргә чыккан иде. Без 4 яшьлек Рөстәмнән: «Син сугышның нәрсә икәнен беләсеңме?» — дип сорадык. Ул башта безгә, аннары әтисенә карап алды. Бераз уйлап торгач: «Юк, белмим», — дип җавап бирде.

Әйе, Рөстәм чыннан да сугышның ни икәнен белми әле. Ул да берчак үсеп җитәр. Китаплардан укып, кинолардан күреп, узган сугыш турында белер. Белер, белми калмас. Чөнки аны һәрберебез белергә, хәтерләргә тиеш. Аны онытырга безнең хакыбыз юк. Ул исәннәр өчен, килер буын өчен кирәк. Тыныч тормышның кадерен белер өчен, шушы тыныч тормыш хакына армый-талмый көрәшер өчен кирәк.

Ә көрәш дәвам итә. Бу көрәш — халкыбызның ил куәтен арттыруда армый-талмый эшләве. Бу көрәш — халкыбызның тынычлык юлыннан атлавы. Бу көрәш — салкын сугыш кабызырга тырышучы капиталистларга каршы халкыбызның кайнар бердәмлеге.

23 июнь, 1976

Хуш киләсең, музыка!

Яз — елның иң музыкаль чоры. Ул безгә бетмәс-төкәнмәс язгы авазлар, сагынып көтеп алган якты, шат җырлар алып килә. Гөрләвекләр агышы, сыерчыклар сайравы... Бөтен дөнья сихри музыка белән тулы. Кояш әйтерсең лә дирижер. Ул үзенең нурдан ясалган таякчыгы белән җирдәге бөтен авазларны үзенә карата. Барысы да Кояшка буйсына. Гөрләвекләр дә, җырчы кошлар да аңа төбәлгән. Кояш нурлары хәрәкәткә килү белән җирдә гаҗәп бер язгы җыр башлана. Тантаналы җыр! Якты җыр! Бу җырга һәммәсе дә кушыла: гөрләвекләр дә, кошлар да, тамчылар да... Әнә күзгә күренмәс җил! Ул — әйбәт музыкант. Агач ботакларына скрипка кылларына кагылгандай тиеп үтә дә дөньяга тагын яңа бер аваз өстәлә. Елгалар да телгә килә. Бөреләр уяна. Һәркемнең үз җыры, үз моңы, үз авазы.

Мондыйда кем җырламый түзә алсын. Бигрәк тә укучылар. Мондый якты көннәрдә күңел үзе җырлап тора. Әйе, табигатьтәге гаҗәп музыкага укучыларның да көчле авазы кушыла. Балалар музыка атналыгы юкка гына яз көне, нәкъ менә шушы көннәрдә уздырылмый шул. Яз — үзе җыр, үзе музыка!

Мәктәпләрдә музыка авазлары яңгырый башлады инде. Бүген М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында атналыкны ачу тантанасы була. Укучылар берничә көн рәттән күренекле композиторлар, артистлар, музыкантлар белән очрашалар. ТАССРның дәүләт симфоник оркестры атналык өчен махсус программа әзерләде. Казан консерваториясенең актлар залында узачак бу концертларда якын-тирәдәге районнардан килгән балалар да булачак. Филармония артистлары да укучыларга лекцияконцертлар әзерләделәр. Кинотеатрларда музыкаль фильмнар фестивале уздырылачак. Казан, Лениногорск, Арча, Алабуга, Әлмәт һәм Түбән Камадагы музыка училищеларында махсус концерт бригадалары төзелде. Алар да мәктәпләрдә чыгыш ясауны планлаштырдылар. Укучыларны бик күп кызыклы очрашулар, күңелле концертлар, онытылмас көннәр көтә. Алда — язгы каникул. Музыкаль каникул, җырлы-биюле каникул!

24 март, 1976

Сизми дә калырсыз әле

Казанның нәкъ үзәгендә тылсымлы бер йорт бар. Аны «Әкият иле» дисәң дә була, «Тылсымнар дөньясы» дип атасаң да ярый. Ни өчен дисезме? Чөнки биредә күз күрмәгән, колак ишетмәгән тамашалар кылына. Әкияттә генә очрый торган җен-пәриләрне, убырлы карчыкларны, кешечә сөйләшә ала торган еланнарны күрергә телисезме? Монда җитәрлек алар. Рәхим итегез! Бер дә куркып тормагыз. Сезнең кебек әйбәт малайларга-кызларга тимиләр алар. Ул әкият җәнлекләренең, кош-кортларының үз эшләре, үз дөньялары. Әгәр дә аларны читтән генә күзәтеп торсаң, бик гаҗәп хәлләргә тап буласың. Бактисәң, алар арасында да явызлык һәм изгелек, саранлык һәм киң күңеллелек, матурлык һәм ямьсезлек бар икән. Алар арасында да матур тормыш өчен көрәш бара икән. Алар арасында да яхшылык һәрвакыт җиңеп чыга, явызлык җиңелә икән. Аларны карап тору бик файдалы һәм гыйбрәтле. Шуңа күрә дә бу йортның залы балалар белән һәрчак шыгрым тулы була. Малайлар-кызлар әлеге әкият «халкы» белән бергә шатланалар, борчылалар, дулкынланалар. Үзләре дә сизмәстән шул әкият илендә яши башлыйлар.

Сез бу тылсымлы йортның серенә төшенгәнсездер инде, мөгаен. Аның тышкы ягына зур хәрефләр белән «Казан курчак театры» дип язылган. Театр быел үзенең 45 нче сезонын башлап җибәрде. Быел да сезне мавыктыргыч та, тылсымлы да, кызыклы да әкият-спектакльләр көтә. Менә алар: Р.Батуллинның «Баһадирлар»ы, А.Гайдарның «Хәрби сер»е, «Дөрләсен учаклар» исемле тамаша, Г.Рәхимнең Г.Тукай әсәре буенча эшләнгән «Кәҗә белән Сарык әкияте», Казанның 800 еллыгына багышланган «Тылсымлы курай» әсәре, Г.Х.Андерсенның «Су кызы»... Аларны санап чыгу мөмкин түгел. Алар бик күп. Әгәр дә театрның спектакльләрен карап барсагыз, сезнең алда өр-яңа бер дөнья ачылыр. Ул театрга бер барсаң, икенче тапкыр гел барасы гына килеп тора. Ышанмыйсызмы әллә? Юри генә бер барып карагыз әле. Икенче мәртәбә тагын барганыгызны сизми дә калырсыз. Мин әйткән иде диярсез менә.

Казан курчак театры сезне көтә, дуслар. Рәхим итегез!

30 октябрь, 1976

Без ничек ял иттек

Менә бу ял көне ичмасам! Үзе җылы, үзе кояшлы. Теләгәнчә ял итеп кал. Чөнки мондый көннәр еш булмас, җәйнең бер генә ае калып бара. Июльнең соңгы көне бит бүген.

Улым Алмаз белән урамга чыгып киттек. Олы малай инде ул. Өч яшь ярымлык. Үзе бертуктаусыз сөйләнә, сораулар яудыра. Туктый да белми, арый да белми. Мине генә хәлдән тайдыра. Иң элек паркка кердек. Безнең каршыда гына ул. Урам аша гына чыгасы. Анда исә төрле аттракционнар, карусельләр, таганнар бар. Алмаз башта атка утырып әйләнде, аннары машинага, ракетага... Шуннан соң Карабас-Барабасның сакалыннан шуып төште. Мине дә кыстый башлады. Сәбәп табып шумый калырга иде исәп. Ни дисәң дә, уңайсыз бит: тирә-якта халык кайнаша. Олы башың белән шуып йөрү килешмәс. Чалбар да кызганыч. Шулай да Алмаз: «Әти, нигә шумыйсың, куркасыңмыни?» — дигәч, үземнең батырлыгымны күрсәтер өчен булса да шуып төшәргә туры килде. Янәшәдәге малайларга-кызларга бу бик ошады булса кирәк. Алар да әти-әниләрен Карабас-Барабасның сакалыннан шуып төшәргә кыстый башладылар. Алмаз исә «батыр» әтисен җитәкләп, таган янына ашыкты.

Аннары без «Әкият»кә киттек. Әкият дигәч тә, чын әкият түгел инде. Бауман урамында шундый бер кафе бар. Балалар өчен. Бик кызык анда: тиен дә бар, кошлар да, балыклар да. Алмаз бик ярата аларны. Әкиятне дә шунда гына дип белә. Әкият укый башласаң да: «Юк, бу әкият түгел, әкият Бауман урамында ул», — дип кенә җибәрә.

Алмаз кояшка бәйләнергә ярата. Кояш та аңа бәйләнә. Берчак бакчага илткәндә, кояшка караган икән дә, үзенең күзен чагылдырган. Үзе миңа зарлана: «Кояшны яратмыйм мин», — ди. Сәбәбен сорагач: «Күзгә керде ул минем», — ди. Ә бүген кояшка карап-карап торды да: «Әти, нигә калмый ул бездән?» — дип сорады. Мин дә кояшка игътибар иттем. Чыннан да, кояш безгә ияреп бара иде. Без туктыйбыз, ул да туктый. Кузгалабыз, ул да кузгала. Кызулыйбыз, ул да шулай. Улыма: «Кояш безне ярата ул, шуңа бездән калмый. Син дә ярат аны», — дип җавап кайтардым. Риза булды. Ә күңелдә кинәт кенә шигырь язу теләге туды. Өйгә кайткач шигырьне яздым. Исеме — «Уза идем».

Узышабыз кояш белән —

Мин чабам, ул да чаба.

Ул узалмый, мин узалмыйм —

Икебез дә бер чама.

Яндык-пештек, арып беттек —

Мин калмыйм, ул да калмый.

Узып та китә алмый.

Тик кояш кызык итте —

Болытка кереп китте.

Ә үзе болыт артыннан

Көлгән була, җитмәсә.

Уза идем мин кояшны,

Әгәр кереп китмәсә.

...Ә кич белән бергәләшеп телевизор карарга утырдык. Башта Казаннан А.Гайдар исемендәге балалар Культура сараеның бию ансамбле чыгыш ясады. И матур бииләр дә инде. Хәтта Алмаз да түзмәде, кушылып бии башлады. Аннары «Толымлы могҗиза» исемле фильм күрсәттеләр. Гимнасткалар турында ул. Аларның батырлыклары турында. Алмаз: «Мин дә гимнастка булам», — дип, идәндә тәгәри башлаган иде дә, барып чыкмагач, тиз туктады. Шуннан соң диванга утырып, шым гына карый башлады. Бер әйләнеп караганда, ул тәмле итеп йоклый иде. Әнисе аны караватка алып салды.

Кино беткәндә келт итеп исемә төште: мин бит 31 июль турында «Яшь ленинчы»га мәкалә язарга тиеш идем. Менә 31 июльдә ниләр булган, шуларны язарга булдым.

1977

Күңелле сәфәр

«Әллә кайларда әллә ниләр бар, диләр... Бер дә әллә кайларга барып йөрисе юк, карый белергә дә, күрә белергә генә кирәк, кызыклар адым саен ул!» — ди Шәвәли. Дөресен сөйли! Шәвәлинең яңа маҗараларын, Хәлим, Сәлим, Мөсәлим нишләгәнне белерсез бу китапта... Әйдәгез, күңелле сәфәргә чакырабыз сезне!» Күренекле балалар шагыйре, Тукай премиясе лауреаты Шәүкәт абый Галиевнең «Күңелле сәфәр» китабы шул сүзләр белән башланып китә. Әйдәгез, дуслар, чыннан да, шушы китап буйлап сәяхәт итеп алабыз. Бу сәфәребез шигърият иленә булыр.

Әйдәгез, кузгалдык. Нинди кызыклар, нинди сөенечләр көтә икән безне? Менә беренче тукталышка да килеп җиттек. Ул «Шәвәли дөресен сөйли» дип атала. Биредә, үзегез дә сизеп торасыздыр инде, сезнең күптәнге танышыгыз Шәвәли яши. Ул үзе гап-гади бер ма-

лай. Сездән үзгәрәк сыйфатлары да бар аның. Шаянлыклары, шуклыклары белән бераз сезгә дә охшаган. Мәсәлән, ул «Сабан туе батыры» шигырендә көрәшеп батыр калган малай. Балалар бакчасында. Шәвәли һәр шигырьдә үзенчә ачыла, яңа кызык сыйфатлары белән үзен һәрчак яраттыра. Аның тапкырлыгына, теләсә нинди авыр хәлләрдән дә җиңеп чыга белүенә кайчакта көнләшеп тә куясың. Мөгаен, Хуҗа Насретдин бабайның төпчек энесе, йә булмаса, аның оныгыдыр ул. Юкса шулкадәр шуклык, наянлык каян килсен аңа, «Шәвәли» тукталышындагы иң соңгы шигырь янына да җиттек. «Шәвәли сәяхәте» дип атала ул. Поездга утырып ул да сәяхәткә чыккан. Булмаса, аны да үзебез белән алыйк. Бергә-бергә күңеллерәк булыр.

Әнә икенче тукталыш та күренә. Исеме — «Имән ни дигән?» Кызык исем. Шулай бит? Без табигать кочагына килеп эләктек шикелле. Әһә, әйттем бит. Беренче шигыре үк «Күбәләк» исемле. Аннары «Керәшәләр», «Дөмбәскә», «Камыш тургае», «Керпе таптык»... Бу тукталышта әллә никадәр тереклек иясе белән танышырга була. Биредә табигать шулкадәр матур: сокланып туймаслык... Ләкин без табигать өчен көенә дә белергә тиешбез. Чөнки табигатькә кул сузучылар, аны рәнҗетүчеләр дә очрый әле. Алар агачларның канатларын каералар, кошларны, җәнлекләрне дә җәлләп тормыйлар. Шагыйрь абыегыз әнә шуларга борчыла, ул әнә шуларны уйлый. Менә «Бер йортлы шәһәр» шигыре янында бераз тукталып алыйк. Әлеге бер йортлы шәһәр ни дип уйлыйсыз? Соң, әлбәттә, кырмыска оясы. Ул урманда тыныч кына яшәп ята. Аның халкы да уңган, эш сөючән. Ул малайларның әйбәтлегенә ышана, алардан курыкмый. Әмма беркөнне «шәһәрне» туздырып ташлыйлар. «Шәһәр»нең тынычлыгы югала. Хәзер инде аз гына тавышка да сискәнеп яши ул... Чү, мылтык тоткан бер малай нәрсә атып йөри ул анда? Кара, кара, атты түгелме соң? Әйе шул... Әмма куянның исе дә китмәде: куак арасына кереп посты. Баксаң, малай фотоаучы икән. Андый әйбәт малайлар да күп бу тукталышта.

Ә менә бу тукталышның исеме бигрәк тә кызык инде — «Акыл теше кемгә чыга?» Биредә сез төрле шигырьләр белән танышырсыз.

Юлыбызны дәвам итәбез. Бусы — «Жираф белән Зариф» тукталышы. Исеменнән үк күренгәнчә, бу — зоопарк кебегрәк җир булырга охшый. Ялгышмаганбыз икән. Монда, чыннан да, кошлар, җәнлекләр җитәрлек. «Мыр-мыр белән Дер-дер», «Нәни тычкан ясый кояш», «Күсе нидер урлаган», «Мәймүн...» Болар үзе бер зоопарклык бит.

Ә без иң соңгы тукталышка да килеп туктадык. «Хәлим, Сәлим, Мөсәлим» тукталышы булыр бу. Биредә Шәүкәт абыйның яңа геройлары яши. Китап тышлыгындагы бер велосипедка утырып баручы малайлар шулар инде. Өч туган, өч дус, өч иптәш алар. Дюманың «Өч мушкетер»ы яисә «Өч танкист», Репинның «Өч баһадир»ы шикеллерәк. Кем белә, бәлки, алар да үскәч баһадирлар булырлар. Ә бүгенгә алар гел бергә. Бергә булгач күңеллерәк тә, җиңелрәк тә. Бу тукталыштагы шигырьләр нәкъ шул хакта сөйли.

Сәяхәтебез төгәлләнеп килә, дуслар. Ул шулкадәр күңелле булды, беткәнен сизми дә калдык. Инде Шәүкәт абыйга рәхмәтләр әйтеп, яңа сәфәргә кадәр саубуллашыйк.

17 август, 1977

Репетиция

Сезнең җәй көне урманда яисә болында булганыгыз бармы? Әгәр булса, андагы төрле-төрле кошларның төрле авазлар чыгарып сайрауларын онытылып тыңлап торганыгыз бардыр, шәт. Аларга чишмәләр чылтыравы, агачлар шавы, чикерткәләр черелдәве, үләннәр кыштырдавы да кушылса, Табигатьнең Мәңгелек Хоры барлыкка килә. Яки су буенда шау-гөр килеп су коенган иптәшләрегезнең шат авазлары. Яисә авылда кич белән көтү кайткандагы тавышлар. Анда йөзләгән авазлар барысы бергә буталып, үзенчәлекле хор хасил була. Дөрес, алар билгеле бер тәртипкә салынмаган, аларның дирижерлары да юк. Ә хәзер мин сезгә чын хор турында, халык хоры исемен йөртүче балалар коллективы турында сөйләмәкче булам. Казандагы А.Гайдар исемендәге балалар Культура сарае турында ишеткәнегез бар инде сезнең. Ул чын мәгънәсендә сәнгать сарае, музыка сарае. Әлеге хор да нәкъ менә шушында.

...Мин хор бүлмәсенә килеп кергәндә, аның җитәкчесе Н.Ф.Сизова чираттагы репетицияне башларга тора иде. Аның беренче сүзләре шул булды: «Кызлар! (Хор фәкать кызлардан гына тора.) Үзегезгә мәгълүм, ике көн элек кенә без республикабыздагы Культура сарайлары арасында уздырылган смотрда катнаштык. Сезнең җырларны анда бик яраттылар һәм... беренче дәрәҗә диплом белән бүләкләделәр! — Кызлар дәррәү кул чаптылар. Аларның шатлыклары чиксез иде. Наталья Федоровна сүзен дәвам итте: — Сез концертта беренчеләр булдыгыз. Ләкин әле бу барысы да ал да гөл дигән сүз түгел. Мәсәлән, сез үзегезне бик киеренке тоттыгыз. Кыскасы, тагын да тырышыбрак җырларга кирәк».

Шушы кереш сүздән соң репетиция башланды. Бүлмәдәге 80 кызның карашы дирижерга төбәлде. Аның кулы күтәрелүгә, берьюлы 80 аваз яңгырады. Бер авазны хәтерләткән әлеге авазлар башта акрын гына пәйда булды, аннары сиздерми генә үсә, көчәя барды: до-ре-ми-фа-соль-ля-си... Бүлмәдә авазлар тибрәлә. Дирижер бертуктаусыз күрсәтмәләр бирә, төзәтмәләр кертә, үзенә кирәкле авазларны эзли... Репетициядә сәгать ярым утырып, мин хор сәнгатенең гаять авыр һәм мавыктыргыч булуын төшендем. Баксаң, хор коллективизм хисе тәрбияли икән. Ничек дисезме? Ә бит хор члены берьюлы берничә төрле эш эшләргә мәҗбүр: иң элек үзең җырлыйсы көйне (мелодияне) хәтердә калдырырга кирәк (ә хор — дүрт тавышлы! Димәк, дүрт кыз бер үк вакытта дүрт төрле итеп җырларга тиеш була), дирижерның хәрәкәтләрен аңларга һәм аны игътибар белән күзәтергә кирәк. Үзеңнең тавышыңны тыңлау гына җитми әле, иптәшләреңнекен дә тыңлый белергә кирәк. Әгәр дә аларның җырлаганнарын ишетмәсәң, аларны тыңламасаң, шунда ук төгәллекне югалтасың, бөтен хезмәтне юкка чыгарасың. Монда инде сиксәнең бер булып, бер-береңне аңлап, тыңлап җырласаң гына үз максатыңа ирешергә мөмкин.

Кайбер малайларның хорда җырлаучылардан көлеп йөрүләрен беләм мин. Тезелеп басасың да кычкырып җырлыйсың, имеш. Юк икән шул, алай гына түгел икән! Андый малайлар үзләре булдыра алмаганга гына көләләр икән. Хорда җырлау өчен көч тә, түземлек тә, батырлык та, музыкага мәхәббәт тә кирәк икән.

Репетициядән соң хорга йөрүче кызлар белән сөйләшеп тордык. Сәгать ярым туктаусыз җырлап торсалар да, арыганнары сизелми, күңелләре күтәренке иде аларның. Менә аларның хор турындагы кайбер фикерләре.

Резеда Вәлиева (55 нче мәктәп): «Мин монда бик күп дуслар таптым. Шуларның иң якыны, әлбәттә, музыка. Шуңа күрә мин бирегә яратып, сагынып киләм. Безгә бер-беребезне аңлавы да җиңелрәк, сөйләшер сүзләребез дә күп. Безне монда музыка дуслаштыра».

Наташа Манынина (45 нче мәктәп): «Хорга икенче класстан бирле йөрим. Элек мин җиңел көйләрне генә ярата идем, хәзер симфоник музыканы да рәхәтләнеп тыңлыйм. Чөнки хор җитди музыканы тыңлый белергә өйрәтә. Музыка тыңлаганда андагы төрле төсмерләрне тоя белергә, аңлый белергә кирәк. Әмма аны аңлау җиңел түгел. Шуңа күрә иң башта үзеңне мәҗбүр итәргә, күнектерергә кирәк. Хор исә нәкъ әнә шул күнекмәләрне бирә дә инде».

Репетиция тәмам. Кызлар өйләренә таралды. Мин аларга кызыгып, көнләшеп калдым. Алар биредә музыка фәненә өйрәнәләр. Белеп торам, алар бу хорга гомер буйларына рәхмәт укырлар. Чөнки кош сайравын, чишмә чылтыравын, халык моңнарын тыңлап ләззәтләнгән кебек, алар Бах, Шопен, Бетховен, Чайковский кебек бөек композиторларның әсәрләрен дә тыңлап рухланалар. Җитди музыка дөньясында үзләрен ят кеше итеп тоймыйлар. Бәхетле кызлар!

25 март, 1978

Акбай цирк карый

Күренекле француз язучысы Экзюпериның канатлы бер сүзе бар. «Без барыбыз да балачак иленнән», — дигән ул. Һәм бик дөрес әйткән. Заманында мин дә шул балачак илендә яши идем, сезнең кебек шаян бер малай идем. Еллар үтте. Үсәргә туры килде. Инде олыгайдым гына дигәндә, «Яшь ленинчы» газетасында эшли башладым, һәм нииндидер тылсым көче белән, үзем дә сизмәстән, яңадан балачак иленә, сезнең янга әйләнеп кайттым. Кайттым да шаккаттым! Бар да якын, бар да таныш! Үзем белән бергә уйнап үскән малайларны-кызларны да, дустым Акбайны да шунда ук танып алдым. Шушы могҗизадан соң мин балалар өчен шигырьләр яза башладым...

«Акбай цирк карый» дигәч тә, бу китап Акбай исемле маэмай турында гына икән дип уйлый күрмәгез тагын. Әгәр дә шулай гына булса, сезгә бер дә кызык булмас иде. Шуңа күрә дә әлеге китапка бегемот, зебра, шүрәле, аюлар турындагы шигырьләр дә, сезнең кебек

малайларга-кызларга багышланганнары да кертелде. Аннары елмаючы бүре, тәмле кычыткан, тылсымлы курай, автобуска утырып йөрүче буран белән дә танышырсыз. Алмаз исемле хәйләкәр малай турында да укырсыз. Шигырьләр арасында кызыклары да, моңсулары да җитәрлек. Чөнки берәүләр юмор ярата, икенчеләргә исә лирик шигырьләр ошый төшә. Шуңа күрә теләгәнегезне сайлап укый аласыз.

Аннары шуны да онытмагыз, бу китапта сезнең яраткан рәссамыгыз, «Яшь ленинчы»да озак еллар эшләүче Юрий Денисов абыегызның да өлеше бар. Китап битләреннән елмаеп торучы малайларны, кызларны, маэмайларны, аюларны ул эшләде бит. Шулай булгач, «Акбай цирк карый»ны икебезнең дә күчтәнәчебез итеп кабул итәрсез.

5 август, 1978

## Искитмәле исемсез китап

Ишеттегезме әле, Шәүкәт Галиев белән безнең тагын бер яңа китабыбыз чыкты бит, малайлар. Юри генә китап кибетләренә керсәгез, үзегез дә күрерсез. Зәп-зәңгәр тышлы калын бер китап. Безнең Шәүкәт абый яшь чагында бухгалтер булган кеше, саннар белән генә сөйләшергә ярата. Шулай булгач, безнең әлеге китап 423 битле, 1 сум 50 тиенлек булып чыга инде. Редакторы — Таһир Нурмөхәммәтов, рәссамы — Тавил Хаҗиәхмәтов. Нил Юзиевнең «Балаларга шатлык өләшүче» дигән мәкаләсе дә бар анда. Шигырьләрне икәүләшеп сайлап алдык: иң элек минем турындагыларын, аннары Шәүкәт абый үзе яраткаииарын. Ә безнең Шәүкәт абый хәйләкәр ул — сез ератканнарын гына ярата. Китапка исем сайлаганда гына уртак фикергә килеп булмады. Мин әйтәм: «Безнең туган якларда» дисәк, шәп булачак», — дим. Ул әйтә: «Тургайлар министрына хат» дип куярга кирәк», — ди. Мин: «Акыл теше кемгә чыга?» — дим. Ул: «Алтын куллар», — ди. Мин: «Тылсымлы карандашлар», — дим. Ул: «Бусы — хәрби сер», — ди... Минем ачу да чыкты, «Бөтенесе дә сер түгелдер бит инде», — дим. «Физзарядка ясый куян», «Хәзинәләр иленә сәяхәт», «Көзгеләр көлеп тора», — дип тә карыйм. Әле беребезгә, әле икенчебезгә ошамый. Ахырда уйлаштык-уйлаштык та, китапны исемсез генә чыгарырга булдык. «Шәүкәт Галиев. Балалар өчен шигырьләр». И бетте-китте. Ә теге икәүләшеп тапкан исемнәрне дә әрәм итмәдек — бүлек исемнәре булып калды алары.

Әгәр дә китапны игътибар беләнрәк укысагыз, аннан 1959 елда язылган шигырьләрне дә, 1984 елда язганнарын да табарсыз. Димәк, китапка шагыйрь абыйның 25 ел буе иҗат иткән шигырьләре, күңелле һәм көлкеле мәзәкләре, җырлары, табышмаклары тупланган. Шагыйрьнең күп шигырьләре сездән дә иртәрәк туган икән бит, әй.

Китапның соңгы битен укып карагыз әле: тиражы 7500 дип язылган. Күпме соң бу? Болай караганда күп шикелле, әлбәттә. Ә безнең Татарстанда күпме китапханә бар? Ничә мәктәп? Ничә укучы? Китапханәләргә таратып чыксаң да, берәр генә китап тиячәк түгелме соң? Малайларның-кызларның үзләренә бөтенләй калмый дигән сүз бит бу. Ул чагында китаптагы 511 шигырьнең берсен дә укый алмый калулары бар аларның. Сез дә өлешсез кала күрмәгез дип, мин сезгә китаптагы бер шигырьне булса да укытыйм әле.

Туган тел — иң татлы тел,

Туган тел — иң тәмле тел.

Тәмле дип телең йотма —

Туган телне онытма!

«Туган тел» дип атала бу шигырь. Дүрт кенә юллык шигырь лә бу дияргә ашыкмагыз. Бик мәгънәле шигырь ул. Шуңа күрә дә шагыйрь абыегыз аны ике ел буе язган. Әйе, әйе, ике ел буе! Әйбәт шигырь тиз генә язылмый шул. Укуы гына тиз аны...

Әнә, күрәсезме, укучылар Шәүкәт абыйдан автограф алырга тезелгәннәр дә инде. Бәхетле малайлар, кызлар! Ләкин, кадерле дуслар, сез дә борчылмагыз, китап кибетләрендә бар әле ул китап. Ашыгыгыз, озак тормас, таралып бетәр! Аннары... ни... китапны алгач, Шәвәли турындагы шигырьләрне дә укырга онытмагыз, яме!

Шәвәли

26 март, 1988

1100 битле китап

Бу көннәрдә без халкыбызның Бөек Тарих Китабыннан гасыр тузаннарын кагып төшердек, кабат-кабат актарып карадык. Әлеге бөек китапның беренче битләрен безнең болгар бабаларыбыз яза башлаган. Китап әлегә 1100 биттән тора. Һәрбер бите үзенә берәр елны сыйдырган. Ул еллар исә халкыбызның шатлык-кайгыларын да, бәхетле минутлары белән ачы күз яшьләрен дә, якты хыялларын да бергә туплаган. Китап битләрен актарганда бөек Болгар дәүләтенең чәчәк аткан чоры белән дә, монгол яуларыннан соң ятып калган хәрабәләре белән дә, Алтын Урда һәм Казан ханлыгының гөрләп торган чаклары белән дә, Октябрь революциясеннән соңгы еллар белән дә танышырга мөмкин.

Бөек Болгар! Китапның иң беренче бите. Унбер гасыр элекниндирәк иде икән ул? Урамнарыннан ниндирәк малайлар, кызлар узган икән? Бәхетле булдылар микән алар?

Бүген дә Болгарда, нәкъ моннан 1100 ел элекке кебек, кабат азан яңгырый. Ул борынгы бабаларыбызның, аларның моңнарының кайтавазы булып ишетелә. Болгар хәрабәләре һаман да саклый әле ул моңнарны. Ташларга уелып калган ул моңнар уйларны уята, хатирәләрне яңарта. Халыкка хәтере кайта! Биредә гадәти җырлар да сагышлырак, моңлырак булып тоела. Ташлар әллә үксеп елый, әллә инде үксеп җырлый. Бөек дәүләттән, бөек Болгардан шушындый ташлар гына калсын да... Үксемәс җиреңнән үксерсең.

Китапның иң беренче бите! Мәңгелек китап! Аның әле 1100 бите генә язылган. Ә дәвамын безгә язасы. Дөресрәге, сезгә, кадерле балалар!

6 сентябрь, 1989

## Эт тормышы

«Туйдырды бу эт тормышы. Салкын. Юеш. Кайчаннан бирле туйганчы ашаган юк. Барып борын төртергә җылы ояң, сырышырга, сырпаланырга юньле хуҗаң булмасын. Эткәлиләр дә төрткәлиләр, төрткәлиләр дә типкәлиләр. Көпә-көндез атып китәргә дә күп сорамаслар. Алла сакласын!

Элек, ичмасам, ачка интекми идең. Акмаса да тама иде, корсагың тулганчы ашамасаң да, яланырга табылып тора иде. Ә хәзер... Үзгәртеп кору башланганнан бирле туйганчы ашаган юк. Кибетләргә якын килерлек түгел. Итнең килосы әнә ничә сум! Колбасаларны әйтеп тә тормыйм. Каян килсен андый акча. Селәгәеңне агызып торасың-торасың да, койрыгыңны сыртыңа салып чыгып китәсең. Урам буйлап теләнергә, чүплектә казынырга.

Туйдырды бу эт дөньясы. Өрәсең-өрәсең, барыбер файдасы тими. Колакларына да элмиләр. Элегрәк безнең өрүне ишетүгә очып качалар иде караклар. Хәзер кая ул, исләре дә китми. Кем нәрсә урлый ала, ташыйлар гына. Бөтен илне ташып бетерәләр инде. Шуңа күрә чиныйбыз да шыңшыйбыз гына. Хәер, бөтен ил белән шыңшыйбыз хәзер. Ашарга юк, кияргә юк, илнең рәте калмады, дип шыңшыйбыз. Тик берәү дә җәлләми, һәркемнең үз кайгысы. Шыңшыдың ни дә шыңшымадың ни!

Зоопаркка кереп качар идең, анда да җәнлекләр, кош-кортлар ачка койрык чәнчеп яшиләр, ди. Белмим инде, нишләргә?! Эт көненә калдык бит, эт көненә. Әллә чит илгә качарга шунда, әллә айга, галәмгә очарга. Элек этләрне галәмгә очырталар иде бит, хәзер анысын

да оныттылар. Утырып кына китәр идем шул ракета дигәннәренә. Ә монда — салкын. Кар катыш яңгыр ява башлады — калтырата. Озын кыш җитте... Кешеләре дә этлек кенә уйлап йөри. Туйдырды, билләһи, эт типкелегендә яшәү. Эт итеп тиргиләр, эт урынына кыйныйлар, күз дә ачырмыйлар. Хет кач, хет егылып үл. Тормышмыни бу?! Дөньясын әйтер идем. Шул бер этен дә кеше төсле яшәтә алмаган ил нинди ил була ди инде ул, йә?! Туйдырды бу эт тормышы!» — дип зарланган ди Акбай исемле бер Казан маэмае.

28 октябрь, 1992

**Әңгәмәләр**

Әкиятләр дөньясы

**Казан курчак театры үзенең 40 еллык юбилеен бәйрәм итә. Шул уңай белән махсус хәбәрчебез Роберт Миңнуллин театр директоры Әзһәр Шәехович Хөсәенов белән очрашты. Сезнең игътибарыгызга шул әңгәмәне тәкъдим итәбез.**

**Хәбәрче.** Казан курчак театры 40 ел эчендә данлы юл үтте. Театрның беренче адымнары, беренче уңышлары турында сөйләсәгез иде, Әзһәр Шәехович!

**Ә.Хөсәенов.** Театр 1934 елда, курчак сәнгатенең зур энтузиасты С.М.Мерзляков тарафыннан оештырыла. Театр коллективы беренче көннәрдән үк үзенең иҗат йөзен, башка театрлар арасында үз урынын табарга омтыла. Башта бик авырга туры килә, әлбәттә. Театрның материаль базасы булмый, кадрлар, бигрәк тә милли кадрлар мәсьәләсе килеп баса. Бөтенесен дә театр үзе әзерли, кадрларны үзе тәрбияли. Театр артистлары да, театр художниклары да шушында тәрбияләнә. Шуңа күрә дә бу бәйрәм көннәрендә ТАССРның атказанган артистлары Ф.Таһировны, М.Хисамованы, В.Гафаровны, Н.Бикмөхәммәтованы, Б.Рычковны һәм ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, театрга комсомол путевкасы белән килгән, озак еллар коллективны җитәкләгән С.Хөснине хөрмәт белән телгә алабыз. Нәкъ менә алар театрны оештыруда актив катнаштылар, курчак сәнгатен югары дәрәҗәгә күтәрделәр.

Театр күрсәткән спектакльләрне балалар бик тиз яратып өлгерәләр. 1935 елда ук инде «Красная Татария» газетасында зур гына мәкалә басылып чыга. Анда шундый юллар бар: «Театр Казанда гына түгел, Юдино һәм Зеленодольск балаларына да таныш. Ул татар һәм рус балаларына үз ана телләрендә хезмәт күрсәтә». 1937 елда театр Мәскәүдә Бөтенроссия конкурсында да катнаша. Театр беренче елларда рус әдәбиятыннан алынган спектакльләр генә куйса, кырыгынчы еллар башында ул Г.Тукай иҗатына мөрәҗәгать итә башлый. Сәх-

нәдә бер-бер артлы Тукайның «Шүрәле» һәм «Кәҗә белән Сарык әкияте» буенча эшләнгән спектакльләр күрсәтелә. Татар балаларына зур сөенеч була ул.

**Хәбәрче.** Бөек Ватан сугышы башлангач театр үзенең эшчәнлеген тагын да җанландырып җибәрә. Шул хакта бераз сөйләп китсәгез икән.

**Ә.Хөсәенов.** Сугыш елларында, театр, бөтен авырлыкларга да карамыйча, эшен дәвам иттерә. Ул мәктәп укучылары алдында, госпитальләрдә чыгыш ясый. Госпитальләрдән килгән рәхмәт хатлары әле дә саклана бездә. 1945 елның 9 маенда Җиңү демонстрациясендә театр артистлары да катнашалар. Алар җиңелгән Гитлер һәм аның иярченнәренең курчакларын алып чыгалар. Ләкин артистлар мәйданга кадәр барып җитә алмыйлар. Халык ул курчакларга таш атып, аларны ватып бетерә. Бу вакыйга, беренчедән, халыкның фашизмга ачы нәфрәтен чагылдырса, икенчедән, кешеләрнең курчакка курчак итеп кенә карамауларын күрсәтеп тора.

**Хәбәрче.** Курчакка курчак итеп карамау дигәннән, сезгә бер сорау бирәсе килә. Курчак сәнгате, гомумән, нидән гыйбарәт? Аның вазифасын, бурычларын һәм әһәмиятен ничек аңларга?

**Ә.Хөсәенов:** Бу җәһәттән курчак сәнгатенең зур остасы, СССРның халык артисты С.Образцовның бик әйбәт сүзләре бар: «Курчак сәнгате ул аеруча көчле һәм тәэсирле театр коралы». Бу чыннан да шулай. Балаларда сәнгать дөньясын аңлау нәкъ менә курчаклардан башлана. Кечкенә чагында караган спектакльләр бала күңелендә гомергә саклана. Курчаклар ул әкият, могҗиза дигән сүз. Әкият исә үз чиратында тәрбия чарасы да, элек-электән әкиятләр аша явызлыкка нәфрәт, изгелеккә мәхәббәт тәрбияләнгән бит. Мине бер нәрсә борчый: соңгы вакытта әкиятләргә игътибар һәм ихтирам кимеде шикелле. Минемчә, әкиятләрдән баш тарту дөрес булмас иде. Шушыны искә алып, Туфан Миңнуллин «Гафият турында әкият» язды. Биредә нәкъ шул мәсьәлә күтәрелә.

Безнең театрның тагын бер мөһим ягы бар. Ул Яшь тамашачылар театрына да, Академия театрына да, Опера һәм балет театрына да тамашачылар әзерли.

Аннары, театр мәктәп тормышы белән дә тыгыз элемтәдә тора.

**Хәбәрче.** Сез әле әкияткә игътибар кимүен әйттегез. Бу — тамашачыларның да кимүенә китермиме? Тагын бер каршылык бар шикелле. Безнең чор — техника заманы. Балаларны хәзер бик күп әйберләр кызыксындыра. Алар радиодан, телевидение буенча әллә никадәр тапшырулар белән танышалар. Мәсәлән, мультфильмнарны гына алыйк. Алар курчак театрына аяк чалмыйлармы?

**Ә.Хөсәенов.** Юк, әлбәттә. Киресенчә, бер-берсен тулыландыралар гына. Мультфильмнар балаларда курчак театрын аңларга, ныграк төшенергә ярдәм итәләр, курчакларга игътибарлырак булырга өйрәтәләр. Курчак сәнгате бүгенге көндә, гомумән, күтәрелеш чорын кичерә. Курчак театрларын балалар гына түгел, өлкәннәр дә яратып карыйлар. Телевидение тапшыруларында Үзәк курчак театры чыгышларын караганыгыз бардыр инде сезнең. Бу бит югары дәрәҗәгә җиткән сәнгать.

**Хәбәрче.** Әзһәр Шәехович, сезнең театрны сәяхәтче театр дияргә мөмкин, чөнки театр һәрвакыт гастрольләрдә йөри. Шул хакта да берничә сүз әйтмәссез микән?

**Ә.Хөсәенов**. Әгәр дә артист үз казанында гына кайнаса, бер урында гына таптаныр иде, бернинди дә үсеш булмас иде. Без моны һәрчак истә тотабыз. Театрның географиясе дә,

биографиясе кебек үк, шактый бай. Безнең коллективны Татарстанның һәр шәһәрендә, һәр авылында яхшы беләләр, яраталар, көтеп алалар. Безнең иҗат шулай ук башка республикаларга да таныш. Быел март-апрель айларында Дагстанда 40 көнлек гастрольдә булып кайттык. Безне анда зурлап каршыладылар, яратып озаттылар. Буйнак шәһәренең 1нче урта мәктәбендә артистларны почетлы пионерга кабул иттеләр.

**Хәбәрче**. Театрның тормышы, бүгенге уңышлары, бүгенге артистлары белән дә таныштырып китсәгез әйбәт булыр иде.

**Ә.Хөсәенов**. Театр элекке театр түгел инде. Коллектив бик нык үсте, үзгәрде. Белемле, талантлы яшьләр килә. Быел гына бездә Ленинградтагы музыка һәм кинематография институтыннан һәм Казан театр училищесыннан килгән 15 артист эшли башлады. Безнең театр яшь башкаручылар смотрында да беренче урынны яулап алды. Яшь, талантлы артистлар З.Хаҗиев, И.Катаева, Э.Йосыпов һәм А.Шестопалов истәлекле бүләкләр белән бүләкләнделәр. Бер төркем татар драматурглары безнең театр белән тыгыз элемтәдә торалар. Н.Фәттахның «Энҗеле үрдәге», Т.Миңнуллин белән Р.Батуллин әсәрләре сәхнәләрдә зур уңыш белән бара.

**Хәбәрче**. Яшь тамашачыларны нинди яңа спектакльләр, нинди шатлыклар көтә? Шушы традицион сорауга да җавап бирсәгез икән.

**Ә.Хөсәенов**. Театр зур иҗат планнары белән яши. Киләсе елның 9 Маенда Бөек Җиңүне бәйрәм итәчәкбез бит. Шул бәйрәмгә Р. Батуллин «77 пәһлеван» исемле пьеса язды. Аның геройлары илебездәге төрле милләтләрнең легендар уллары.

Габдулла Тукайның да 90 еллык юбилее җитә. Хәзер аның балачагына багышланган яңа спектакль куярга әзерләнәбез. М.Җәлилнең 70 еллыгына яңа спектакль өлгереп килә.

**Хәбәрче:** Рәхмәт, Әзһәр Шәехович. Укучыларга бу әңгәмә ошар дип уйлыйм. Сезне театрның олы бәйрәме белән котлыйбыз, яңа иҗат уңышлары телибез.

23 октябрь, 1974

Песиләр дә сөйләшә монда...

Казан курчак театры 7 октябрьдә С.Т.Аксаков әкияте буенча эшләнгән «Ал чәчәк» спектакле белән үзенең яңа сезонын башлап җибәрәчәк. Быелгы сезон кайсы яклары белән әһәмиятле? Яшь тамашачыларны нинди мавыктыргыч спектакльләр көтә? Шушы сораулар

белән кызыксынып, без курчак театрында булдык. Театрның баш режиссеры Роберт Мөхлисович Батуллин белән әңгәмә нәкъ шул хакта барды.

**Хәбәрче**. Роберт Мөхлисович! Иң беренче соравыбыз репертуар турында, һәр сезонның үзенчәлекле бер ягы була. Әйтик, үткән сезон тулысы белән диярлек Бөек Җиңүнең 30 еллыгына багышланган иде. Без сезон барышында күп кенә кызыклы әсәрләр белән таныштык. Быелгы сезон кайсы ягы белән аерылып торачак? Шул хакта берничә сүз әйтсәгез иде.

**Режиссер**. Һәр сезон театр өчен мөһим дә, җаваплы да. Шулай ук һәрбер сезон, сез әйткәнчә, үзенчәлекле дә. Ә менә быелгысы, минемчә, тагын да мөһимрәк, истәлеклерәк һәм бай эчтәлеклерәк булачак. Партиянең XXV съезды якынлаша. Шушы вакыйга уңае белән без планнан тыш бер спектакль әзерлибез. Аннары съездга багышлап «Яхшы спектакльләр атналыгы» уздырырга җыенабыз. Тагын бөек шагыйрьләребез Габдулла Тукай һәм Муса Җәлил юбилейлары. Җәлил көннәрендә инде сезгә таныш булган «Кара шәүләләр» спектакле куелачак. Тукай бәйрәменә багышлап «Су анасы», «Шүрәле» һәм «Кәҗә белән Сарык» экиятләрен сәхнәләштерергә исәплибез.

**Хәбәрче**. Тукай әкиятләрен сәхнәләштерү әйбәт, әлбәттә. Әмма алар укучыларга бик таныш әсәрләр бит. Шуңа күрә тамашачыларга кызык булыр микән? Кабатлау гына килеп чыкмасмы?

**Режиссер**. Шулай. Тукай әкиятләре һәммәбезгә дә таныш. Күбебез аларны яттан да белә. Ләкин ул әкиятләрне балалар яратып карар дип уйлыйм. Ни өчен дисезме? Беренчедән, әкиятләр күпмедер дәрәҗәдә үзгәртелеп биреләчәк, эчтәлеге баетылачак. Аның шулай икәнен яшь тамашачылар үзләре дә күрерләр. Икенчедән (монысы аеруча мөһиме), әкиятләр китаптан укыганда бик гади булып күренергә мөмкин. Ә инде шул ук әсәрне сәхнәдә күрү бала өчен икенче дөнья ачу белән бер. Биредә җансыз әйберләр җанлана, хәрәкәтләнә. Песиләр, маэмайлар телгә килә, сөйләшә башлый. Бала ул әкиятне ун тапкыр да карарга мөмкин. Аннары, безнең театрның тагын бер өстен ягы: ул башка театрлар булдыра алмаган әйберләрне эшли ала. Әйтик, Данко күкрәгеннән йөрәген алып факел итеп балкыта ала... Ә башка театрларда моны эшләп булмый. Курчак театрының серле көче, тылсымы менә шунда да инде.

**Хәбәрче.** Безнең редакциягә укучылардан бик күп хатлар килә. Алар арасында: «Ничек курчак театры артисты булырга?» — дигән сораулар да бар. Шул хатларга безнең газета аша җавап бирсәгез әйбәт булыр иде.

**Режиссер.** Бик теләп җавап бирәм. Элегрәк бу сорауга җавап бирүе читенрәк булыр иде, әлбәттә. Хәзер инде эшләр әйбәтләнде. Казан театр училищесында курчак театры артистлары әзерли торган бүлек ачылды. Анда VIII–X класс белемле кызлар, егетләр укый ала. Ә инде укуларны дәвам иттерергә теләүчеләргә Ленинград музыка һәм кинематография институтының курчак театры артистлары һәм режиссерлары бүлегенә имтихан тотарга мөмкин.

**Хәбәрче.** Хәзер мәктәпләрдә дә курчак театрына игътибар итә башладылар. Курчак театры белән кызыксынучы укучыларга үзегезнең теләкләрегезне, кайбер киңәшләрегезне дә җиткерсәгез иде.

**Режиссер.** Әйе, кайбер мәктәпләрдә, бигрәк тә Мамадыш районы мәктәпләрендә курчак театры белән кызыксыну артты. Бу — бик матур күренеш. Бу җәһәттән, Югары Сөн һәм Югары Ушмы сигезьеллык мәктәбе укучыларының мактаулы эшен куәтлисе килә. Алар безнең театр белән тыгыз элемтәдә торалар. Шуның нәтиҗәсе буларак, алар курчакларны да үзләре ясыйлар. Дөрес, кибетләрдә кайбер уенчыклар сатыла. Баштарак шулардан файдаланырга мөмкин. Мәскәүдән, Балалар уенчыклары фабрикасыннан да соратып алырга була. Анда курчак театрлары өчен махсус комплектлар эшләнә. Әкиятнең пьесасы да, курчаклары да була ул комплектта. Ләкин бу — бик җиңел юл. Монда инде теләгән пьесаны куя алмыйсың. Шуңа күрә курчакларны үзегез ясарга өйрәнергә кирәк. Теләк булса, максатка ирешеп була ул. Ә минем теләк: курчак театры һәр мәктәптә булсын иде!

**Хәбәрче.** Әңгәмә өчен рәхмәт, Роберт Мөхлисович. Ә инде сезнең теләкне безнең укучылар искә алырлар дип ышаныйк. Яңа сезон яңа иҗат уңышлары, яңа кызыклы очрашулар алып килсен.

Әңгәмәне Р.Миңнуллин язып алды.

4 октябрь, 1975

Әй рәхәт соң сәхнәдә!

Камал исемендәге Ленин орденлы Татар дәүләт академия театрының дүрт артисты безнең редакциядә кунакта — түгәрәк өстәл янында. Алар — РСФСРның атказанган, ТАССРның халык артисткасы Вера Минкина, ТАССРның халык артисткасы Рауза Хәйретдинова, ТАССРның атказанган артисты Равил Шәрәфиев, артист Хәлим Җәләлов. Алар әле яңа гына Казанның 83 нче мәктәбендә булганнар. Туп-туры шуннан килүләре икән. Анда укучылар белән очрашканнар, үзләренең иҗатлары, хезмәтләре белән таныштырганнар, театр сәнгате турында сөйләшкәннәр. Безнең әлеге сөйләшүебез дә шуның дәвамы кебек килеп чыкты. Без кунакларга төрле сораулар бирдек. Укучыларның артистлар турында сорап язган хатлары белән таныштырдык. Алар безгә рәхәтләнеп җавап кайтардылар. Сөйләшү артистларның үзләре турында, гомумән, артист хезмәте хакында барды. Кунакларыбызның сөйләгән сүзләре, әйткән фикерләре артист булырга хыялланучы кызлар, малайлар өчен дә, укучыларыбыз өчен дә кызыклы һәм файдалы булыр дип уйлыйбыз.

— Укучылар шуны онытмасыннар иде: укып кына артист булып булмый. Аның өчен иң элек сәләт, талант кирәк. Аннары теләк һәм омтылыш кирәк. Театр сәнгатенә мәхәббәт кирәк. Әгәр дә синдә шушы сыйфатлар бар икән, укырга да була. Аның өчен бездә театр училищесы бар. Теләсәң, Мәскәүдә, Ленинградта, илебезнең башка шәһәрләрендә белем алырга мөмкин. Ләкин артист өчен уку гына да җитми әле. Ул җырлый да, бии дә белергә тиеш, — Рауза апа Хәйретдинова үзенең сүзен шулай башлап җибәрде. — Безгә мәктәп-

ләрдә, укучылар арасында еш булырга туры килә. Хатлар да язып торалар, киңәш сорыйлар, рәхмәтләр әйтеп язалар. Бер очрашу вакытында бер кыз миннән: «Сез бәхетлеме, Рауза апа?» — дип сораган иде. Мин аңа: «Әйе, мин бик бәхетле!» — дип җавап бирдем. Бу чыннан да шулай. Чөнки мин кечкенәдән хыялланган максатыма ирештем. Теләгем кабул булды.

Аннары Рауза апа үзенең бәләкәй чактан ук спектакльләрдә катнашуын, курчаклар белән театр уйнавын исенә төшерде, җырларга, биергә яратуы турында сөйләде.

Вера апа Минкина да беренче тапкыр ничек итеп сәхнәгә чыгуын хәтерләде:

— 1931 елда безнең авылдагы чиркәүнең тәреләрен кисеп алдылар. Бик зур иде ул тәреләр. Аннары без аларны яргалап сарайга ташыдык. Шуннан соң ул чиркәүне клуб иттеләр. Мин ул чакта IV класста гына укый идем әле. Шул клубта авыл яшьләре «Банкрот» спектаклен куйдылар. Анда мин дә катнаштым. Шуның хөрмәтенә әти миңа беренче тапкыр өр-яңа чын ботинка сатып алып бирде. Шатлануымны күрсәгез! Әле булса онытканым юк. Әлеге спектакльдә нинди роль уйнавым белән кызыксынасызмы? Әйтсәм, ышанмассыз. Сиражи хатынын уйнадым мин анда! Белмим, нишләп миңа биргәннәрдер ул рольне. Шулай да бик шәп уйнаган кебек булган идем. Шунысы кызык, ул рольне бик күп еллардан соң тагын уйнарга туры килде. Монысында инде — олы сәхнәдә. Академия театрында. Кайсысын әйбәтрәк уйнаганмындыр, хәзер инде хәтерләмим. Әмма беренчесе бүгенгедәй күз алдымда.

Равил Шәрәфиев күбрәк комедиядә уйный. Бу хакта артист үзе болай ди:

— Мин театрга чыннан да комедияләрдә уйнау нияте белән килдем. Теләгем комик образлар тудыру иде. Теләгемә ирештем дип уйлыйм. Андый образларның максаты бик изге. Ул — тамашачының күңелен күтәрү, җитешмәгән яклардан көлү һәм аларны бетерүдә ярдәм итү. Сер итеп кенә әйткәндә, кызык рольләр генә уйнау кайчакта туйдыра да башлый икән. Үзеңне башка рольләрдә дә сынап карыйсы килә. Дөрес, андый рольләр дә уйналды. Әйтик, «Канат җәйгәндә» спектаклендә Үмеркәй образын мин бик яратып, бирелеп башкардым. Ул минем иҗади рухыма туры килә иде. Уйныйсы килеп йөргән башка рольләр дә күп. Мин, мәсәлән, Дон Кихотны бик теләп уйнар идем. Ул минем күптәнге хыялым. Чехов пьесаларындагы геройлар да кызыктыра. Мин бигрәк тә трагикомедияләрдә уйный алыр идем кебек. Рус актеры Леонов та бит элегрәк гел комик рольләр генә башкара иде. Хәзер исә трагикомедияләрдә дә искиткеч итеп уйный.

Туры килгәндә, мин балалар өчен дә яратып уйныйм. Алар алдында чыгыш ясавы күңелле. Алар сәхнәне чын күңелдән кабул итә белә, сәхнәдәге вакыйгаларга битараф карамый. Ләкин аларның ихтыяҗлары да башкачарак, шуңа күрә артист алдына куелган таләп тә зуррак.

Әгәр дә мин яңадан малай чагыма, 14 яшьлек чагыма кайта алсам, барыбер артист булыр идем. Аннары математика белән ныграк шөгыльләнер идем. Бер чит тел өйрәнер идем. Әгәр мәктәптә үк өйрәнгән булсам, әйтик, инглиз телен, мин бүген рәхәтләнеп Байронны, Шекспирны оригиналда укыр идем. Аннары, һичшиксез, шахмат уйнарга өйрәнер идем. Шахмат уйнаучы яу кырындагы полководец кебек бит ул.

Сүзне Хәлим Җәләлов дәвам итә:

— 14 яшемә яңадан кайтсам, нәрсә эшләячәгемне күз алдыма китерә алмыйм. Ә менә мәктәптә укыганда мин шахмат белән мавыга идем. Ярыйсы гына мат куйган чакларым да

булды. Математиканы да ярата идем. Рәсем ясау белән дә кызыксынып алдым. Үзешчән сәнгать түгәрәкләрендә актив катнаштым. Хәтта шигырьләр дә яза идем. Кыскасы, мавыгуларым шулкадәр күп иде, мәктәпне тәмамлаганда (ә мин аны көмеш медаль белән бетердем) үземнең кем буласымны тәгаен генә белми идем әле. Шуңа күрә Казанга, авыл хуҗалыгы институтына барып кердем. Артист булу теләге көчлерәк булып чыкты: институтның өченче курсыннан театр училищесына китеп бардым. Ялгышканмынмы, юкмы, анысы тамашачыларга ныграк күренәдер.

Аннары укучыларның сәнгатьне яратулары мине бик сөендерә. Мәктәпләрдә булганда сәнгатькә мәхәббәт аеруча күзгә ташлана. Сәнгатькә гашыйклар өчен «Гүзәллек дөньясы» маршруты менә дигән хәзинә икән. Маршрут буенча алар концертлар, спектакльләр куялар. Сәнгатькә багышланган төрле атналыкларда катнашалар. Сәнгатьне яратырга, аңларга өйрәнәләр. Сәнгатьнең тылсымлы серләренә төшенергә омтылалар. «Гүзәллек дөньясы»нда актив катнашучылар сәнгатьне, әлбәттә, театр сәнгатен дә аңлап, белеп, яратып үсәләр. Дөрес, аларның һәммәсе дә артист та булмас. Ләкин хикмәт артист булуда гына түгел бит әле. Алар, иң мөһиме, рухи яктан бай булып, әзерлекле, зәвыклы тамашачылар булып үсәләр.

Аннары кунакларыбыз үзләренең иҗатлары, иҗат лабораторияләре белән таныштырдылар, образларның ничек тууы турында сөйләделәр.

**Рауза Хәйретдинова**. Образлар гаять тә авырлык белән туа. Сәхнәгә чыкканчы зур бер эзләнү чоры кичерәсең. Образларга кирәк сыйфатларны күбрәк кешеләрдән эзләргә тырышасың. Артистның, гомумән, күзе очлы булырга тиеш. Үзеңне генә уйнасаң, ролең бик ярлы булыр иде. Шуңа күрә без манераларны, мимикаларны, сөйләшүләрне кешеләрдән өйрәнәбез.

**Вера Минкина.** Яңа рольне уйнар алдыннан, чыннан да, бик күп эзләнергә, күп әйберләр белән танышырга, өйрәнергә туры килә. Бу бигрәк тә чит ил язучыларының әсәрләрен куйганда шулай. Ни өчен дисәң, анда барысы да ят: гореф-гадәтләре дә, кешеләре дә, мохите дә. Ләкин барыбер аларның тормыш агышына кушылырга кирәк. «Эзоп»тагы Мелитаны уйнаганда мин шундый авырлыкка тап булдым. Бик күп материал эзләргә, китаплар укып чыгарга туры килде. Әмма андый рольләрне уйнавы кызыклырак. Тамашачылар өчен дә кызык.

**Равил Шәрәфиев.** Кайбер рольне баштарак яратмыйсың. Яратмыйча гына әзерлисең, яратмыйча гына уйныйсың. Сәхнәгә чыгасы да килми. Әмма бер алынгансың икән, уйнарга кирәк, яратырга кирәк! Һәм, чыннан да, тора-бара ул рольне ярата башлыйсың. «Әлдермештән Әлмәндәр»дәге Газраил белән дә шулай килеп чыкты. Башта бер дә яратмаган идем. Хәзер менә сәхнәгә чыгасы гына килеп тора.

Дөресен генә әйткәндә, артистның да төрле чаклары була. Уңышлы рольләр белән беррәттән тонык, төссез рольләр дә килеп чыгарга мөмкин. Моны тамашачылар сизгәнче, иң элек артист үзе сизәргә тиеш. СССРның халык артисты Хәлил ага Әбҗәлиловның бик әйбәт сүзе бар иде: «Әгәр дә артист минем уңышсыз ролем юк дисә, ул чын артист була алмас иде». Бу чыннан да шулай. Артист зур ихтыяр көченә ия булырга тиеш...

Дүрт артист. Дүрт талант. Дүрт характер. Дүртесе дә үзенчәлекле, бер-берсенә һич тә охшамаганнар. Татар театрын яратучылар әлеге артистларны да, һичшиксез, яраталардыр. Вера апа Минкина уйнаган татар карчыкларын гына исегезгә төшерегез. Алар бит коеп куйган татар әбиләре. Ул тел дисеңме, ул мимика, ул интонация дисеңме! Һәркем аны үз әбисенә охшатадыр. Ә Рауза апа Хәйретдинованың уйнавы? Ул уйнаган апалар чәчрәп то-

ра, аларның һәркайсы хәтергә уелып кала. Чөнки артистка бөтен җанын, бөтен күңелен биреп уйный белә. Равил Шәрәфиев исә үзенең кыяфәте, килеш-килбәте белән үк тамашачыны яулап ала. Тамашачыны үзенә игътибар иттерер өчен аңа берничә фраза әйтү дә җитә. Хәлим Җәләлов — хәрәкәт артисты. Ул сәхнәдә тик кенә тора алмый. Күбрәк хәрәкәтләр, жестлар белән образ тудыра.

Әлеге артистлар сәхнәдә уйнамыйлар, яшиләр. Үзләре уйнаган образда, спектакльдәге вакыйгаларда яшиләр. Вера апа Минкинаның бер сүзе хәтердә калды: «Әй рәхәт соң сәхнәдә!» Бу сүзләрне бөтен гомерләрен театрга, сәхнәгә багышлаган, һәрбер рольдән тәм табып яшәгән артистлар гына әйтә аладыр. Артист бәхете әнә шул гади генә сүзләргә сыеп беткән түгелме соң?! Ә андый артистлар бик күп безнең театрда. Бу көннәрдә Татар дәүләт академия театры үзенең 70 еллык юбилеен билгеләп үтә. Шундый зур тантана көннәрендә кунакларыбызны да, аларның сәхнәдәшләрен дә олы бәйрәмнәре белән чын күңелдән котлыйбыз.

18 декабрь, 1976

## Батырлык нидән башлана?

Бу сөйләшүгә хат белән китап сәбәпче булды. Беренчедән, Зәй районы Иштирәк мәктәбеннән Николай Харитонов Муса Җәлилнең батырлыгы турында язуыбызны сорап хат язган иде. Икенчедән, Татарстан китап нәшрияты язучы Рафаэль Мостафинның «Кечкенә Муса турында хикәяләр»ен бастырып чыгарды. Шушы уңай белән хәбәрчебез Роберт Миңнуллин язучыга берничә сорау белән мөрәҗәгать итте. Ул безгә бик теләп җавап бирде.

— Рафаэль абый! Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты, легендар Муса Җәлилнең тормыш юлын сездән дә күбрәк өйрәнгән язучы юктыр, мөгаен. Сез инде ул хакта берничә китап та чыгардыгыз. Аларга тагын бер яңа китап өстәлде. Ул — «Кечкенә Муса турында хикәяләр». Безнең укучылар ул хикәяләрнең кайберләре белән таныш инде. Шуңа күрә аларның әлеге китап белән кызыксынулары табигый. Әгәр дә китапның язылу тарихы турында берничә сүз әйтсәгез, укучылар өчен кызыклы булыр иде.

— Китапның язылу тарихы еракларга барып тоташа. Муса Җәлил минем якташым бит. Әтинең туган ягы — Оренбург өлкәсенең Шарлык районы Яңа Муса авылы — Җәлилнең туган авылы Мостафадан 20 — 25 чакрымнар гына. Мусаның укытучысы Абдулла Усманов минем әтине дә укыткан кеше. Менә шул Абдулла абыйның сөйләве буенча мин инде

кечкенә чакта ук, 11 — 12 яшьләрдә вакытта ук Муса турында ишетеп белә идем. Кечкенә Мусаның башлангыч мәктәпне бер елда тәмамлавы, аның бөтен әйбер белән дә кызыксынуы, төрле сораулар бирергә яратуы турында сөйләгәннәре хәтергә сеңеп калган. Мусаның авылларында беренче комсомол булуын, авылда беренче балалар оешмасы төзүен тирә-якта болай да беләләр иде.

«Герой-шагыйрь эзләре буйлап» исемле китабым чыккач, Мусаның балачагы, яшьлек еллары турында сорап, миңа бик күп хатлар килде. Хат язучыларның күбесе, әлбәттә, пионерлар. «Муса Җәлил безнең яшьтә чакта нинди булган?» Менә шул сорау кызыксындыра аларны. Чыннан да, кечкенә чакта Муса нинди булган соң? Шушы сорауга җавап эзләп, мин яңадан Оренбург якларында булдым. Мусаның бергә үскән егермеләп яшьтәшен эзләп таптым. Аларның кайсысы Оренбургта, кайсысы Мәскәү янында, илебезнең башка шәһәрләрендә яши. Материаллар туплаганда миңа бигрәк тә шагыйрьнең туганнары Хәдичә апа Җәлилова (ул хәзер Оренбургта яши), Фрунзе шәһәрендә яшәүче Ибраһим абый Җәлилов ярдәм итте...

— Укучыларның соравын тагын бер тапкыр кабатлыйсы килә. Муса кечкенә чакта нинди булган соң?

— Җәлилнең тормыш юлын ныклап өйрәнгәннән соң, мин шуңа ышандым: батырлык беркайчан да үзеннән-үзе генә барлыкка килми икән. Мусаның батырлыгы да шуны раслый. Батырлык иң элек аның характерына бәйләнгән. Көрәшче буларак ул иртә өлгергән, иртә камилләшкән. Бик иртә көрәш юлына баскан. Инде 13 яшендә ул мылтык тотып дошманга каршы сугыша. 14 яшендә «Кызыл чәчәк» исемле оешма төзи. Искелек белән аяусыз көрәш алып бара. Яшьтәшләрен җыеп спектакльләр куя. Шагыйрьнең ул чактагы беренче шигырьләре үк инде рухы, пафосы белән «Моабит дәфтәре»ндәге шигырьләр белән аваздаш.

— Рафаэль абый, сез ничек уйлыйсыз, батырлыклар бер-берсенә охшыймы?

— Һәр батырлык үзенчә. Әмма батырлыкларның уртак яклары да бар. Менә, мәсәлән, Җәлилнең көрәштәше шагыйрь Рәхим Саттар. Ул да авылда үскән. Табигатьне яраткан. Ул да кечкенәдән үк үзенең характерын тәрбияләгән. Тугайларда, болыннарда берүзе йөргән. Куыш ясап, атналар буе берүзе кунып ята торган булган. Аның батырлыгы да кечкенәдән үк формалаша башлаган. Башка мисаллар да китерергә була. Ягъни мин шуны әйтмәкче булам, бик иртә, кечкенәдән үк чыныккан булсаң гына, батыр булып була. Иртә чыныгу кеше характеры өчен бик әһәмиятле.

Мин мәктәпләрдә еш булам. Укучылар белән очрашам. Шундый очрашулар вакытында кайберәүләр: «Шундый шартларга эләксәк, бәлки, без дә батырлык эшләр идек», — диләр. Ә бит батырлыкны теләсә нинди шартларда да эшләргә мөмкин. Батырлык эшләргә шартлар бүген дә җитәрлек.

— Җәлилнең характеры турында ниләр әйтә аласыз? Аннары, аның батырлыгына нинди сыйфатлар хас?

— Муса кечкенәдән көчле ихтыярлы, көчле характерлы була. Ул үзен рухи яктан гына түгел, физик яктан да чыныктыра. «Кешенең сәламәтлеге үз кулында» дигән хакыйкатьне ул үзенә кулланма итеп ала. Һәм аны беркайчан да үзгәртми. Көн саен иртән физзарядка ясый, салкын су белән юына. Шуңа күрә ул бөтен авыруларны да җиңә. Аның белән бер камерада утырган бельгияле А.Тиммерманс болай ди: «Төрмәдә болай да салкын, хәтта

бәсләр куна. Әмма ул үлем көткәндә дә салкын, хәтта бозлы су белән юына иде. Ул коенганда, мин чирканып тора идем».

Мусаның тагын бер әйбәт сыйфаты: ул да булса, аның гомер буе күп белергә омтылуы. Башта ук әйткәнемчә, кечкенәдән үк ул гаять кызыксынучан була. Барысын да белергә тырыша. «Ул башта мәдрәсәдә белем ала, аннары рабфакта, Мәскәү университетында укый. Рус телен, немец телен әйбәт белә, хәтта төрмәдә, үлем көткәндә дә вакытын бушка уздырмый. Шигырьләр язу белән бергә А.Тиммерманстан француз теленә, аннары Р.Лайфрединидан итальян теленә өйрәнә. Кыскасы, Муса һәрчак белемгә омтылган.

Әмма Җәлилнең герой буларак, патриот буларак иң кирәкле һәм иң яхшы сыйфаты — иле һәм халкы турында уйлавы. Нәкъ менә гомеренең соңгы минутына кадәр иле һәм халкы турында уйлау, зур итеп уйлау, бөтен теләк-омтылышларын әйтеп бирергә тырышу Мусаны герой иткән дә инде. Моны шагыйрьнең соңгы көннәренә кагылышлы кечкенә бер деталь дә ачык чагылдыра. 1944 елның августында Тиммерманс Муса белән очраклы рәвештә тагын бер тапкыр очраша. Муса аннан: «Минем шигырьләрем ничек?» — дип сорый. Тиммерманстан уңай җавап алгач, шигырьләренең исән калганын белгәч, ул бәхетле елмая. Чөнки шагыйрь шигырьләренең халкына кирәк икәнлеген белә, аларның Туган илгә кайтып җитәсенә ышана.

— Рафаэль абый! Кечкенә чакта һәркемнең батыр буласы килә, һәркем батыр булырга хыяллана. Шундый укучыларга нинди киңәшләр әйтер идегез?

— Үз-үзеңдә батырлык тәрбияләүне бүгеннән үк, кечкенә чактан ук тәрбияли башларга кирәк. Беренчедән, үз-үзеңне җиңә белергә өйрәнү бик мөһим. Икенчедән, көн режимын саклау зур әһәмияткә ия. Ә инде характер тәрбияләгәндә вак нәрсә булмый. Биредә һәр кылган эш зур роль уйный. Җәлил батырлыгы исә һәр укучыга үрнәк була ала. Алар Җәлилдән үрнәк алырга, үзләрендә кирәкле сыйфатлар тәрбияләргә тиеш.

— Иң соңгы сорау. «Герой-шагыйрь эзләре буйлап» исемле китап белән әлеге китап арасында өзеклек бар. Ул — Җәлилнең яшьлеге. Шагыйрьнең шул чоры турында да язмыйсызмы?

— Әйе, бу чыннан да шулай. Шуны истә тотып, мин яңа китап язам. Ул Җәлилнең бала чагыннан алып 1941 елга кадәр чорны эченә ала. Китап Мәскәүдә, «Детская литература» нәшриятында чыгачак. Аннары «Атаклы кешеләр тормышы» (ЖЗЛ) сериясе өчен Җәлил турындагы китап өстендә эшлим.

— Рәхмәт сезгә, Рафаэль абый. Яңа китабыгыз да, башка китапларыгыз кебек үк, үз укучысын табар, яратып укылыр дип ышанабыз.

22 гыйнвар, 1977

## Исәнме, тарих!

Шушы елның 25 октябрендә танылган татар совет язучысы Нурихан Фәттахка 50 яшь тула. Бу олы юбилей уңае белән газетабызның хәбәрчесе Роберт Миңнуллин язучы янында булды һәм аңа берничә сорау белән мөрәҗәгать итте.

— Сезне кем дип атыйк, Нурихан абый? Прозаикмы, шагыйрьме, драматургмы? Балалар өчен язучымы? Әллә тарихчымы?

— Мин үземне сез уйлаганча ук «күпкырлы» дип әйтмәс идем. Әгәр мин балалар әдәбияты белән, олы проза, драматургия, тел, тарих белән кызыксынам икән, бу әле «күпкырлылыкны» күрсәтми. Без бүген язучы, шагыйрь, драматург, тарихчы, телче дип атап йөрткән иҗат кешесе элек, гомумән, һәртөрле өлкәдә эшли алган. Бер үк кеше шигырь дә язган, көйләр дә чыгарган, төзүче дә, химик та, астроном да, математик та булган.

Хәзер профессия чикләре тарайды, фән, әдәбият-сәнгать төрле тармакларга бүлгәләнде. «Әдәбият» агачының бер ботагы булган «балалар әдәбияты»нда гына да әллә никадәр «чыбыклар» барлыкка килде (мәсәлән, балалар шагыйре, балалар язучысы, балалар драматургы, балалар әдәбияты тәнкыйтьчесе һ.б.). Мин мондый бүлгәләнүне бик үк хуп күрмим. Мин үземне, гомумән, иҗат кешесе дип, язучы дип беләм һәм иҗатка сәләтле булган һәркем эзләнергә, төрле жанрда язып карарга тиеш дип исәплим.

Без, язучылар, укучы өчен, халык өчен язабыз. Теле, әдәбияты булган халыкның тарихы да бар. Кемдер телне бозып сөйләшсә, культурабызны, тарихыбызны бик үк дөрес аңламаса, күңелемдә бер теләк туа: һичшиксез, күбрәк, яхшырак язарга, һәммәсен дә үтемле итеп аңлатырга, төшендерергә кирәк. Халкының тарихы белән кызыксынмаган кеше язучы була алмый. Безнең халкыбыз тарихына кагылышлы күпме мәгълүматлар эзләп табылган! Табыласылары күпме!

Тарихи әсәр язганда мин иң әүвәле үткәннәрнең чын рухын, сулышын сиземләргә тырышам! Ул чор кешеләре ничегрәк гомер сөргәннәр, ничегрәк яшәгәннәр, нинди сүзләр белән сөйләшкәннәр... һәммәсе дә гаять мөһим.

— Нурихан абый, Сез, әлбәттә, республика мәктәпләрендә укучылар оештырган музейларның күбесен беләсездер...

— Әйе, чыннан да, укучылар мәктәп музейлары оештырып бик файдалы, бик кирәкле эш эшлиләр. Аларга әби-бабайларның «искедән калган» сүзләренә колак салгаларга, гореф-гадәтләрнең, йолаларның, уен-җырларның, хәтта ырымнарның серле мәгънәләрен аңларга, истә калдырырга кирәк булыр. Халыкның рухи мирасын белү, аны яклау, саклау — һәрбер совет кешесенең изгедән дә изге бурычы бит. Тел, тарих, этнография — гаҗәеп мавыктыргыч фәннәр...

— Нурихан абый, «Казан утлары»ның киләсе елгы икенче санын нишләптер Сезнең исем белән бәйләп сөйлиләр...

— (Сиздермәскә тырышып өстәлнең уң ягында тау кадәр булып өелеп яткан кулъязмаларга карап ала.) Юкка сөйләмиләр, күрәсең. Әйтсәм әйтим инде, «Сызгыра торган уклар» дип аталган тарихи романның беренче китабын төгәлләдем. Ул «Казан утлары»ның нәкъ шул санында басыла башлый.

— Сезнең «Сызгыра торган уклар»ыгыз кайсы гасырларга кадәр очып бара соң?

— Мин моннан ике мең йөз еллар элеккеге, хәзерге Монголия һәм Төньяк Кытай җирендә яшәгән, борынгы кытайлар белән аяусыз көрәш алып барган гуннар (яисә сөннәр) тормышын тасвирладым. Сөннәр... Кемнәр соң алар — сөннәр? Карасаң, алар күп кенә төрки кабиләләрнең борынгы бабалары булган бит.

Безнең җиребездәге һәр калкулык, һәр үзәнлек — тарих. Күз алдыма китерәм: сабый үз авылы янындагы ниндидер калкулык янына туктап җиргә тезләнгән дә шыпырт кына мәңгелеккә дәшә:

— Исәнме, тарих! Бу — мин килдем сиңа!

21 октябрь, 1978

Әкиятләр дөньясына сәяхәт

Бүгенге кунагыбыз — Ленар Шәйхи улы Җамалетдинев. Ул — танылган фольклорчы, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты галиме, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Шагыйрь Роберт Миңнуллин аңа берничә сорау белән мөрәҗәгать итте.

— Сез ничә әкият беләсез? Гомумән, татарда ничә әкият бар икән?

— Сүз халык әкиятләре турында барганда бу сорауны мин ике өлешкә бүләр идем. Беренчесе: бездә ничә әкият тексты бар? Икенчесе: ничә сюжет бар? Гадәттә без, кулыбызга килеп кергән китапның күләмен билгеләп, калын, юка, дибез, фәләнчә табак яисә фәләнчә битле, дибез. Балалар исә күбесенчә бу китапта ничә әкият булуын санап чыгалар. Менә шул әкиятләрнең саны әкият текстларының саны була инде. Әле бит басылмаган әкиятләр дә бар. Аларның текстлары архивларда, китапханәләрнең кулъязмалар бүлегендә, музейларда һәм аерым кешеләрдә саклана. Әйтик, бер бала әбисеннән яисә бабасыннан бер әкият язып алды ди, бу инде шул бала кулында саклана торган текст була. Ул да югалмаска тиеш. Әнә шундый басылып чыккан һәм әлегәчә басылмый яткан әкият язмаларының суммасы безнең татар әкиятләре фондын тәшкил итә. Шушы фондта ничә әкият, ягъни ничә текст бар дип сорасагыз, җавап бирәм: миңа мәгълүм булган кадәресе 2 мең тирәсе. Бу оч-

ракта бер әкият, ничә мәртәбә басылуына карамастан, бары бер текст булып кына санала. Мәсәлән, «Шомбай» дигән әкият 20 тапкыр басылган, әмма ул бер үк текст.

Хәзер мәсьәләгә икенче яктан килик. Әнә шул 2 мең текстка күз салсак, арада 15 «Шомбай» бар икән. Ягъни 15 текстның эчтәлеге бер үк. Әмма аларны 15 кеше сөйләгән. Болар инде 15 текст була алса да, 15 әкият була алмый, бәлки, «Шомбай» әкиятләренең вариантлары, ягъни төрдәшләре генә булып торалар. Бәс, шулай икән, әкиятләрне эчтәлекләре буенча санарга мөмкин түгелме соң? Әйдәгез, эчтәлекне гадиләштереп сюжет дип атыйк та әлеге әкиятләребез фондын сюжетлар буенча төркемләп карыйк, һәр текстта бер генә сюжет булганда төркемләү уңышлы бара. Ә менә «Камыр батыр» һәм «Турай батыр» әкиятләрен ничек итәргә? Икесендә дә бер үк сюжет: батыр егет җир астында Үзе бер карыш, сакалы биш карыш картны үтерә, җир өстенә хәзинәләрне һәм кызларны җибәрә, үзе чыга алмый — дуслары хыянәт итә, соңыннан барыбер хаклык җиңә. Сюжетлары бер үк булса да, бу ике текстның ике мөстәкыйль әкият икәнен һәр бала да белә. Камыр батырның могҗизалы рәвештә тууы үзе үк игътибарны җәлеп итә һәм аны башка бернинди герой белән дә бутый алмыйсың. Шуңа күрә могҗизалы туу үзе генә дә аерым сюжет булып йөртелә. Шулай итеп, бер әкияттә сюжет бер генә булмаска да мөмкин. Кайбер әкиятләрдә аларның саны хәтта 4 — 5 кә җитә. Фәндә бу күренеш контаминация дип атала. Хәзерге вакытта дөнья халыкларының әкиятләрендә очрый торган сюжетларның берләштерелгән каталоглары бар. Аларны сюжет күрсәткечләре дип атыйлар. Сорауның икенче өлешенә җавап итеп әйтәм: татар халык әкиятләрендә әнә шул халыкара күрсәткечләрдә теркәлгән 380 ләп сюжет ачыкланды. Әлеге күрсәткечләрдә булмаган сюжетларны да исәпкә алганда татар әкиятләре репертуарында алар 450 ләп булыр дип уйлыйм. Бу эш әле тәмамланмаган. Насыйп булса, якын елларда без моңа да ирешербез.

— Сез ничә әкият китабы чыгардыгыз?

— 6 китап. Бер китабым ике төрле булып басылды. Икенчесе яхшы кәгазьдә, төсле рәсемнәр белән чыкты, шуның өстенә ялтыравык тышлы һәм зур форматлы. Зур булганга күрә, аны бер шүрлеккә дә бастырып куеп булмый. Әнә шул гел ятып кына тора торганын да аерым китапка санасагыз, ул вакытта 7 данә була.

— Шулар арасында үзегез өчен иң кадерлесе бармы?

— Әйе, хәтта икесе. Беренчесе — көнкүреш әкиятләре томы. Бу китап 1981 елда нәшер ителгән иде. Ул җәмәгатьчелек тарафыннан хупланган «Татар халык иҗаты»ның 12 томлык җыелмасындагы бер китап буларак кына түгел, бәлки бик күп көч кергән хезмәт буларак кадерле миңа. Аны әзерләгәндә төрле китапханәләрдә әкиятләрнең барлык басмаларын күздән кичерергә, шулай ук Казан, Мәскәү, Ленинград, Уфа архивларында да байтак кына казынырга туры килде. Нәтиҗәдә күп кенә текстлар беренче мәртәбә шушы китапта дөнья күрде. Кадерле китапларымның икенчесе — 1986 елда нәшер ителгән «Татарские народные сказки» дигән җыентык. Урыс телендәге бу зур җыентык Татарстан китап нәшриятының элеккеге директоры Гарәф ага Шәрәфетдинов инициативасы белән әзерләнде. Зур тираж белән басылганлыктан ул халкыбызның 150 әкиятен йөзләрчә мең укучыга, шул исәптән урыс теле аша башка бик күп милләт укучыларына да мәгълүм итте. Шуның өстенә күп халыкларның фольклор галимнәре өчен дә ул мөһим чыганак булды.

— Сез үзегез әкияткә ышанасызмы?

— Бу сорауда әкияттә сурәтләнгән вакыйгалар, аерым алганда, тылсымлы әкияттәге маҗаралар күздә тотыла дип уйлыйм. Әкиятләрдә чынбарлык белән фантазия бергә үрелеп бара. Ләкин һәрбер гаҗәеп нәрсә бүгенге көн биеклегеннән караганда гына фантазия дип ка-

бул ителә. Аларны тарих сызыгына куеп карадың исә, һәммәсенең дә гадәти нәрсә икәнлеге ачыклана. Шулай булгач, убырлы карчык та, дию дә, кызларны ашый торган аждаһа да, үлгән кешене терелтү дә, карурман эчендәге шомлы йорт та — барысы да булган яисә бар дип ышанылган нәрсәләр.

— Әкият кешегә ни өчен кирәк?

— Әкият кешегә беренче чиратта чын кеше булу өчен кирәк. Әкият яңа гына теле ачылган сабыйны яхшылык белән явызлыкны аерырга өйрәтсә, үсмерләрдә әдәплелек, әхлаклылык, инсафлылык, мәрхәмәтлелек, батырлык һ.б. сыйфатларны тәрбияләүдә зур ярдәм итә. XVIII гасырда яшәгән немец философы һәм мәгърифәтчесе Гердер: «Әгәр сабыйга беркайчан да әкият сөйләмәгән булсалар, аның күңелендә эшкәртелмәгән кыр кала, һәм шуннан соңгы елларда инде бу кырны эшкәртү мөмкин булмаячак», — дигән. Димәк, ата-аналар һәм педагоглар карамагында әкият бик үтемле тәрбия чарасы булып тора. Язучылар исә халык әкиятләрен өйрәнеп, әдәби әкиятләр иҗат итәләр. Моннан тыш халык әкиятләренең фәнни әһәмияте дә гаять зур. Тарихчылар, философлар, иҗтимагый фикер тарихын, дин тарихын өйрәнүче галимнәр, этнографлар, сәнгать белгечләре, телчеләр, диалектологлар — берсе дә әкиятне читләтеп үтә алмый. Аларның һәркайсы әкиятләрдә үзенә кирәкле материалны таба, алардан нәтиҗәле файдалана.

— Тормыш бигрәк авырайды. Берәр әкият иленә китеп яшисегез килмиме?

— Авырлыктан качып әкият иленә китү мәсьәләне бик җиңел хәл итү булыр иде. Ярый, мин киттем дә ди, биредә бит халык кала. Минем, киресенчә, бүген «Сабантуй» гәҗитен укучы яшьләр белән бергә мөстәкыйльлек яулаган иркле Татарстаныбызны тизрәк гүзәл әкият иленә әверелдерәсем килә.

— Алып батыр, Камыр батыр, Тапкыр кыз кебек әкият геройлары тормышта очрыймы?

— Безнең халкыбыз — батыр халык, гадел халык, талантлы халык. Физик җәһәттән карасак, бүгенге сабантуй батырлары, әйтик, 110 — 120 килограммлы пәһлеван әлеге әкият батырларына охшамаганмыни? Гадәттә мондый батырлар мәрхәмәтле дә булалар. Ә сугышта күрсәткән батырлыклар! Герой исемен алган каһарманнарыбыз гына да 200 дән артык. Безгә һөҗүм иткән дошман да Үзе бер карыш, сакалы биш карыш картка караганда күп мәртәбә көчлерәк иде. Хәзерге вакытта Татарстанның мөстәкыйльлеге, халкыбызның империя тырнагыннан котылуы хакына үлемгә барырга да әзер торган кыз һәм егетләребезнең төрле формадагы көрәшләрен мин шулай ук әкияттәге хәлләргә охшатам. Әкиятләрдә һәр очракта да хаклык җиңеп чыга, тормышта да ул шулай булыр.

— Әкиятләр төшегезгә кереп интектермиме?

— Юк алай, Ходайга шөкер, тыныч йоклыйм.

— Үзегезнең бала чагыгызны искә төшерегез әле, әкият белән бәйләнешле берәр вакыйганы хәтерләмисезме?

— Минем язмыш ул җәһәттән кызыгырлык булмады бугай. Сугыш чорында һәм сугыштан соң нәкъ менә әкиятләр тыңлар чагымда миңа дистәгә якын урында яшәргә туры килде. Ят җирләрдә бер яки ике ел яшәп кенә тәмам үзләшеп җитеп тә булмагандыр, һәрхәлдә даны чыккан әкиятчеләр очрамады.

Әниемнән ишеткән берничә кечкенә әкият һәм авыл башындагы чирәмлектә кичен сыерлар саклаганда яисә атлар белән куна барганда яшьтәшләрем сөйләгән берничә әкият кенә истә калган. Аның каравы үскәч фольклор экспедицияләре вакытында бик үзенчәлекле әкиятчеләр белән очрашканым булды. Алар турында мәкаләләр дә бастырдым.

— Безнең «Сабантуй»да балалар язган бик күп әкиятләр басыла. Аларга мөнәсәбәтегез ничек? Гомумән, бүген әкияткә урын бармы?

— «Сабантуй»дагы әкиятләр белән хәл кадәри танышып барам. Аларның сыйфаты, әлбәттә, төрлечә. Әмма мине укучыларның әкиятләрне яратуы һәм үзләренең дә әкиятләр иҗат итүе бик шатландыра. Безнең әдәбиятыбыз, сәнгатебез, мәдәниятебез нинди генә югары дәрәҗәгә ирешсә дә, әкияткә ихтыяҗ һичшиксез калачак. Ихтыяҗ булдымы инде — ул яшәячәк. Димәк, әкият — мәңгелек.

— Әкият яратучы малайларга, кызларга нинди киңәшләрегез бар?

— Әкият яратучы балалар арасында әкияткә мәхәббәтләрен гомер буена саклаучылар булсын иде. Алар халык әкиятләре белән кызыксынып, әби-бабайлардан шуларны язып алсыннар һәм бу язмаларның коллекциясен булдырсыннар иде. Һәр мәктәптә шундый бер генә укучы табылса да, без никадәр рухи байлыкны саклап калыр идек. Магнитофонга яздырганда бу эш хәтта фәнни әһәмияткә дә ия булачак. Шундый теләге булган укучылар, бәлки, хат та язарлар әле. Мин киңәшләрем белән аларга ярдәм итәргә әзермен.

17 февраль, 1993

## Балалар кайда да бер алар

«Сабантуй»ның баш мөхәррире Роберт Миңнуллинның Башкортстан балалары һәм үсмерләре газетасы «Йәншишмә»нең мөхәррире Рәмил Йәнбәк белән әңгәмәсе

— Рәмил дус, сине безнең редакциядә күрүебезгә бик шатмын. Без инде бер-беребезне күптәннән беләбез. Тукай бабайча әйтсәк, «тел вә лөгать алмашып» яшибез. Газеталарыбыз да таныш. Үзең белән дә таныштырып кит инде. Укучыларыбыз белеп калсын.

— Мин сезгә Урал, Агыйдел якларыннан сәламнәр алып килдем. Башкортстандагы Күгәрчен районының Дауыт-Каеп авылында туганмын. Уфадагы интернат-мәктәптә укыдым. Хәзер ул республика күләмендәге башкорт гимназиясе. Аннары — университет. 5 нче курста ук үзебезнең балалар газетасында эшли башлаган идем. Аңа да 18 ел узып киткән икән инде.

— Ялгышмасам, син бит берзаман башка эшкә дә китеп караган идең бугай.

— Синең кебек инде, Роберт. Үзең дә башта «Казан утлары»на, аннары телевидениегә киткән идең бит.

— Мал да ашаган җиренә кайта, димәкче буласың инде?

— Юк, бүрене бүреккә салсаң да урманга карый, дияргә уйлаган идем.

— Балалар газетасы, балалар дөньясы үзе дә кара урман инде ул. Анда бер барып керсәң, тиз генә чыгармын димә. Үзеңнән-үзең адашасың.

— Үзебез белән балаларны да шунда «адаштырып» калдыра алсак, бездән дә бәхетле кеше булмас иде.

— Үскәчтен дә шул урманнан чыга алмаслык итеп. Югыйсә кайбер кешеләр үзләренең балачакларын оныталар да әллә кем булалар...

— Һәр газетаның үз традицияләре, үзенчәлекләре булса да, безнең максатлар — бердер. Ул — баланы олы дөньяга әзерләү, олы кеше итеп тәрбияләү.

— Балалар болай да үзләрен олы кеше итеп тоялар инде анысы. Шуңа күрә алар белән шаярырга ярамый. Барысын да, аңлап, белеп тора безнең малайлар, кызлар.

— Шуңа да карамастан заманында үзебез дә шактый гына алданып яшәдек, укучыларыбызны да алдаштыргаладык. Нишлисең, газета — заманны чагылдыручы көзге шул. Хәзер узганнардан гыйбрәтләр, сабаклар алып, элекке ялгышларны кабатламаска кирәк.

— Хәзерге тормышыбызны ничек бар, шулай күрсәтү мөһим бүген. Матур, ялтыравык сүзләргә тиз ышана торган беркатлы, наив балалар тәрбияләүдән сакланырга кирәк. Без инде моны аңладык, шул юнәлештә эшли дә башладык. Әмма заманаларның авырлыгы безгә дә өстәмә авырлыклар китереп чыгарды. Сездә дә шундый хәлдер инде?

— Иң элек шунысын әйтим, безнең «Йәншишмә» әлегә иң арзан газета. Бер саны 2 тиен генә.

— Карале, 2 тиенлек газета да була икән, әй! Безнең «Сабантуй» кыйммәтрәк. Бер саны — 3 тиен. Хәер, 2 тиенгә дә, 3 тиенгә дә хәзер берни дә ала алмыйсың, «Йәншишмә» белән «Сабантуй» алсаң гына инде. Әмма бу кыйммәтчелек заманында барыбер бәяләребезне күтәрергә туры киләчәк.

— Безне элекке партиянең элекке типографиясеннән аерып чыгардылар. Үзебезгә үзебез хуҗа хәзер. Кызганычка каршы, үзебезне үзебез асрый алмыйбыз шул бүген. Елның теләсә кай вакытында ябылырга мөмкинбез. Шуңа күрә быел еллык бәябез әлегә 10 сум 80 тиен булыр дип торабыз.

— Алдагысын Алла белсен. Без дә сездән калышмабыздыр. «Салават күпере»нең әнә бер саны, әгәр чын булса, киоскларда 10 сум булачак икән. Нишләмәк кирәк, кәгазь кыйммәтләнә, почта, типография чыгымнары арта. Ә журналистларыбызның эш хаклары һаман да түбән.

— Ә син баш мөхәррир буларак күпме эш хакы аласың соң?

— Әйтер идем инде... Авылдашлар белсәләр көләрләр. Әгәр дә чынлап әйтсәң, зур газеталарда эшләүче мөхәррирләрнең шоферлары миннән күбрәк ала.

— Борчылма, Роберт дус, минем дә шул чама гына. Иң мөһиме, газета чыксын да, укучылар укысын.

— Анысы шулай. Укучы дигәннән, сезнең укучылар күпмерәк соң?

— 25 мең.

— Азрак икән шул, азрак. Безнеке — 38 мең.

— О-о-о! Сезнең күп!

— Күбен-күп лә ул, тик 7 млн. татар өчен әллә ни түгел шул.

— Җитә ул. Элегрәк без барыбыз да тираж артыннан куа идек. Хәзер, киресенчә, тираж арткан саен, чыгымнарыбыз да арта гына. Миңа калса, хәзер иң мөһиме, булган кадәр укучыларыбыз язганнарны яратып укыса, үзләре дә язышып торса, шул бик җиткән. «Йәншишмә»гә хатлар күп килә: шигырьләр, экиятләр, мәкаләләр...

— Беләм, беләм. Мин дә бит Башкортстанда туган малай. Иң беренче шигырем дә сездә басылды.

— Бер генә дә түгел, ике тапкыр бастырганбыз әле ул шигыреңне.

— Булды андый хәл. Бер кызый күп еллардан соң аны үзенеке итеп бастырган иде шул. Үзебездә дә булгалап тора шундыйрак ЧПлар. Әле күптән түгел бер шигырьне полосадан алып ташларга туры килде. Нинди таныш юллар дип укысам, үземнең «Каурый болыт» дигән шигырем булып чыкты. Бер кыз бала күчереп җибәргән. Әле яңарак кына Шәүкәт Галиевнең «Туган тел» шигырен башка авторныкы дип биргәнбез. Гафу үтенергә туры килде. Ә шагыйрь үзе бу хәлгә сөенде генә. Әмма сирәк була мондый күңелсезлекләр. Безнең иҗатчылар шагыйрьләрдән дә шәбрәк яза хәзер.

— Бездәге кебек икән. Балалар иҗатына без дә күбрәк урын бирергә тырышабыз. Берәрсен укып күрсәтимме? Әле менә Илеш районының Иске Татыш авылыннан Ирина Мусинаның шигырьләре басылды. «Соңладың» дигәне менә ничек:

Мин көлгәндә — син көлмәдең.

Эндәштем — эндәшмәдең.

Чит каенны барып кочтым,

Син шунда көнләшмәдең.

Назлы чәчәкләрне сөйдем,

Гүзәллекне күрмәдең.

Мин калганмын, син белмәдең,

Биеклеккә үрләдең.

Күпме еллар өзелеп көттем,

Нигәдер күренмәдең.

Юлларыңа нурлар сиптем,

Аларга төренмәдең.

Көтмәгәндә кайдан килдең?..

Мин сине танымадым.

Сөю ялкыннарын чәчтең —

Мин дөрләп кабынмадым.

— Минем якташлар, ягъни Илешләр булдыра инде ул. Тик ни... Рәмил дус, сезнең укучылар бик иртә гашыйк булалар икән бит, әй. Безнең мондый мәхәббәт шигырьләрен бастырган юк.

— Ышанмыйм. Бастырмасагыз да, язалардыр. Безнең бит үсмерләр газетасы да. Әгәр сез бастырмасагыз, мәхәббәт шигырьләрен безгә җибәрсеннәр, һичшиксез, бастырырбыз.

— Юк инде, моннан соң без дә бастырырбыз, мөгаен. Ә хәзер мин сиңа Балтач районының Норма авылыннан Алсу Габбасованың «Колыныма» дигән шигырен укып күрсәтим.

Юргый-юргый колын чаба

Болын, кырлар, таулар буйлап.

Аңа карап күңел тулды,

Йөрдем менә ниләр уйлап:

Шатланасың, колынкаем,

Уйнап үтә көннәрең дә.

Сугышка кергәннәр атлар

Бөтенләй чит-ят җирләрдә.

Дошманнарны җиңү өчен

Алар бик күп файда салган.

Илгә кайта алмаганнар,

Гәүдәләре шунда калган.

Болын буйлап колын чаба,

Уйнасын ул, шатлансын гел.

Әй, колыным, сиңа дәшәм:

«Тормышыңның кадерен бел!»

— Менә дигән шигырь. Балалар кайда да талантлы инде алар.

— Балаларга карата мөнәсәбәт тә бертөсле шул, кызганычка каршы. Бездә, мәсәлән, малайлар, кызларның күптән инде кәнфит ашаганнары юк, матур кием-салым күргәннәре юк. Кибетләр — буш. Булганнары да кыйммәт. Белмим, сездә ничектер? Ельцин бабайны мактыйлар бит.

— Үзегезнең дә Россиядән чыгып бетә алганыгыз юк бит әле, Роберт дус. Шулай да, дөресен әйтим, сездә бәяләр арзанрак. Әмма юклык, кыйммәтчелек кайда да бер инде ул. Үкенечкә каршы, безнең Башкортстанда кибетләр бай дип мактана алмыйм. Ә инде бәйсезлеккә килгәндә, без дә Россия кул астыннан котылырга тырышабыз.

— Әлбәттә, шулай. Әмма ул безнең бүгенге укучыларыбызны ничек тәрбияләвебезгә дә бәйләнгән. Без бит элек пионерлар газетасы идек. Сезнеке — «Башкортстан пионеры», безнеке — «Яшь ленинчы». Дөньялар үзгәрә. Газеталар гына түгел, балалар тормышы үзе дә. Бездә, әйтик, балаларның бер өлеше үзләрен «варис-пионерлар» дип йөртәләр. Башка оешмалар да төзелә. Дин белән кызыксыну арта. Кайчакларда аптырабрак та калабыз. Шулай да аларга комачауламаска, кирәк чагында ярдәм итәргә тырышабыз. Үзләре уйлансыннар, хәл итсеннәр. Хөррият заманы бит.

— Бездә дә шул ук күренеш. «Башкортстан пионерлары» дигән оешма эшли. Элекке пионер отрядлары да саклана әле. Скаутлар да бар. Балалар оешмалары ничек кенә аталса да, элекке пионер оешмасының әйбәт якларын үзләренә алсыннар иде алар.

— Балаларны намуслы, кешелекле, инсафлы итеп тәрбияләү — яңа оешмаларның төп бурычы булырга тиеш. Аннары әлеге оешмалар ике республика арасында дуслык элемтәләре урнаштырсалар да әйбәт булыр иде.

— Без инде аны, Роберт, күптән башлаган идек бит. Хәтерлисеңме, ике ел элек без синең белән Башкортстан районнарында булган идек. Мәктәпләрдә узган очрашуларда безнең икебезне дә дустанә кабул иттеләр, яратып калдылар. Син — татар, син башкорт диюче булмады. Шуның кебек без дә укучыларыбызны үз милләтенең патриотлары итеп, шул ук вакытта халыкларны да хөрмәт итүче балалар итеп тәрбияләргә тиешбез.

— Мин синең белән тулысынча килешәм. Без — ут күршеләр, кан кардәшләр. Без дус булсак, бергә булсак, Татарстанның да, Башкортстанның да киләчәге яктырак булыр. Аннары, игътибар иткәнсеңдер, безнең «Сабантуй»ның девизы — «Бөтендөнья балалары, дуслашыгыз!» Дуслык туганнардан, күршеләрдән башланырга тиеш! «Сабантуй» «Йәншишмә» укучыларына Идел буйларыннан, Казаннан дуслык сәламнәре озатып кала!

19 февраль, 1992

Кайтыр идем балачагыма

Роберт абыегыз Миңнуллин Халыкара Г.Х.Андерсен бүләге лауреаты булды. Аның «Дөньядагы иң зур алма» исемле китабы ЮНЕСКОның Балалар һәм яшүсмерләр әдәбияты буенча Халыкара советы (Ай-Би-Би-Уай) тарафыннан Г.Х.Андерсенның Почетлы исемлегенә кертелде, үзе Г.Х.Андерсен исемендәге Почетлы диплом белән бүләкләнде. Аны тантаналы төстә Испаниянең Севилья шәһәрендә октябрь аенда тапшырачаклар. Роберт абыегыз шулай ук Ай-Би-Би-Уайның XXIV нче конгрессына да чакырылды.

Әлеге Халыкара олы бүләк Татарстанның ике генә шагыйренә бирелде, икесе дә — «Сабантуй»ныкылар. Берсе — Роберт Миңнуллин, икенчесе — безнең редколлегия әгъзасы, хөрмәтле шагыйребез Шәүкәт ага Галиев.

Вакыйга редакция бүлмәсендә бара. Өстәл янында бик җитди кыяфәттә Алмаз

утыра. Рузилә керә.

Рузилә. Алмаз, сөенче! Роберт абыйга премия биргәннәр. Г.Х.Андерсен премиясе.

Алмаз. Чынмы? Әйдә, үзен котлап чыгабыз.

Рузилә. Бер уңайдан бирәсе сораулар да бар иде.

Алмаз. Нинди сораулар?

Рузилә. Элек мәктәпкә язучылар килә торган иде. Мин Роберт Миңнуллин килүен күпме көттем, килмәде. Шушы балачак сораулары һаман күңелдә йөри.

Алмаз. Бик әйбәт. Әйдә, котлап, балачагын искә төшереп чыгыйк алайса.

Вакыйга мөхәррир бүлмәсенә күчә. Р.Миңнуллин язып утыра. Ишек

шакыйлар. Алмаз белән Рузилә күренә.

Алмаз. Керергә мөмкинме?

Р. Миңнуллин. Әйдәгез, түрдән узыгыз.

Алмаз (Рузиләгә күз кысып). Бу көннәрдә кәефегез бик яхшы күренә, Роберт абый. Берәр зур шатлыгыгыз бармы әллә?

Р.Миңнуллин. Әйе шул. Менә газетабызның тиражы арткан. Безнең өчен шуннан да зуррак шатлык була алмый инде.

Рузилә. Бу бөтенебезнең дә уртак шатлыгы булды. Яңа ел бәйрәмнәрендә дә күңелегез күтәренке иде.

Р.Миңнуллин. Әйе, әйе, Яңа елларны да матур каршыладык шул. Истә калырлык булды.

Алмаз (читкә). Иң мөһимен тәки әйттереп булмый бит әле. Роберт абый, берәр яңа...

Р.Миңнуллин. Әйе шул, яңа китабым да чыкты. Рус телендә, «Ох уж эти взрослые» дип атала.

Рузилә (түзмичә). Роберт абый, без бит сезне Г.Х.Андерсен премиясе белән котларга кергән идек.

Р.Миңнуллин. Бәй, ник аны башта ук әйтмисез? Ул турыда онытып та җибәргәнмен ләбаса. Әйе шул, «Дөньядагы иң зур алма» исемле китабым Г.Х.Андерсенның Почетлы исемлегенә кертелгән. Менә быелның октябрендә Испаниянең Севилья шәһәрендә Почетлы дипломны тапшыру булачак.

Рузилә (Алмазга күз кысып). Роберт абый, бәләкәй чакта Г.Х.Андерсенның кем икәнен белә идегезме соң?

Р.Миңнуллин. Үзен белми идем анысы, әмма бик ярата идем мин аның әкиятләрен. Төгәл хәтерләмим, мөгаен, татарчага тәрҗемәләре булгандыр аларның. Иң ошаган икесе — «Дюймовочка» белән «Кургаш солдат» әкиятләре. Ничектер моңсу сагышлы китап иде ул. Шул әкиятләр искә төшсә, әле дә балачагымны сагынам.

Алмаз. Үскәч кем булырга хыяллана идегез?

Р.Миңнуллин. Умартачы яки артист, һәрхәлдә, язучы, шагыйрь булу турында уйлаганым да булмады.

Алмаз. Иң яраткан уенчыгыгыз?

Р.Миңнуллин. Трактор, машина һәм пистолет. Тракторларны без иске «зәпчәстләрдән» үзебез ясый идек. Тавышын да «тырррр» итеп авыз белән үзебез чыгара идек. Бервакыт, шәһәрдән кунакка кайткан бер малайның безнең машина белән «пи-би-ип» дип уйнап утырганын күргәч, шәһәрдә машиналар шундый тавыш белән йөриләр микәнни дип шаккаткан идек.

Алмаз. Ул елларда колхозда машиналар аз булгандыр шул.

Р.Миңнуллин. Бөтенләй юк иде диярлек. Күп эшне атлар башкарды. Миңа да күп туры килде ат белән чүмәлә тарттырырга. Тик никтер миңа гел ябык, хәлсез, сыртлары чыра кебек беленеп торган ат туры килә иде.

Рузилә. Роберт абый, иң яраткан уенчыгыгыз пистолет дидегез. Сугышырга да яраткансыздыр инде алайса?

Р.Миңнуллин. Юк, күбрәк мине кыйнадылар. Аннары Фән энекәш, мине яклап, аларны кыйнап кайта иде.

Алмаз. Роберт абый, балачагыгызда иң үзәккә үткән әйбер нәрсә булды? Ачлыкмы?

Р.Миңнуллин. Юк, мин үзебезне ач яшәдек дип әйтә алмыйм. Аллага шөкер, әнкәй бишебезне дә ач-ялангач итмәде. Сугыш арты еллары булса да, начар яшәмәдек. Киемнәрне дә әнкәй үзе тегә иде. Ә менә иң үзәккә үткәне, мөгаен, балачак юлларыдыр. Ул юлларда иза чиккәннәр! Күрше Аккүз авылы безгә өч чакрым. Мәктәпкә шунда йөреп укыдык. Елның теләсә кайсы вакытында кар көртенә бата-чума да, яңгырда, суыкларда да мәктәпкә йөрдек. Район үзәгенә бару да бер җәфа иде. Һич онытыласы юк ул балачак юлларының.

Рузилә. Балачак, гадәттә, мәктәп белән үрелеп искә төшә. Мәктәп елларын сагынасызмы?

Р.Миңнуллин. Сагынмаган кая ул! Иртәнге алтыдан торып, караңгыда ук юлга чыга идек. Без мәктәпкә килеп җиткәндә, Аккүз малайлары тормаган да була әле. Инде без бөтен уеннарны уйнап чыгып, хәлдән тайгач кына аккүзнекеләр килеп җитәләр иде.

Алмаз. Уен дигәннән, нинди уеннар уйнап үстегез?

Р.Миңнуллин. Лапта, ашыклы, качышлы уйнарга ярата идек. Аннары, безне уеннан да бигрәк, клуб үзенә тартты. Балачакның иң зур бәхете иде инде ул клубка чыгып кино карап кайтулар. Бәйрәмнәрдә җырлап, биеп, шигырь сөйләп концертлар куюлар истә калган. Бигрәк тә театр уйнарга ярата торган идем. Әле дә хәтеремдә, «Маякчы кызы»н сәхнәләштердек. Мин матрос булдым. Аңа сәхнәдә аталар. Шунда егылдым да кайчан торырга икәнен белмичә селкенергә дә куркып яттым да яттым. Йоклап китә язганмын...

Алмаз. Китаплар укырга яраткансыздыр инде...

Рузилә (сүзгә кушылып). Гармун да балачак дустыгыз идеме, Роберт абый?

Р.Миңнуллин. Әйе, беренче өйрәнгән көем — «Умырзая». Гел шуны уйнагач, әнием: «Башка көй белмисеңмени?» — дип ачулана иде әле. Ә китапларның иң күбе балачакта укылды инде. Бервакыт әтием янына эшкә баргач, кирәксезгә чыккан бер төргәк китап таптым. Аркадий Гайдарның «Кайнар таш»ы бар иде арада. Ә менә С.Ковпакның «Путивльдән Карпатка кадәр» дигән китабының соңгы битләре ертылган булып чыкты. Шуның ахырын әле дә укый алганым юк.

Рузилә. Роберт абый, беренче шигырьләрегез хәтердә калмаганмы?

Р.Миңнуллин. Мин үземнең иптәшләрем турында язудан башладым. Мәсәлән, бер шигырьнең ике юлы истә калган.

Безнең Фарил бигрәк «әйбәт»,

Ул чәчә һәрвакыт гайрәт.

Монысы иптәш малай турында:

Безнең Альберт әйбәт бала,

Гел «бишле»ләр генә ала.

Тагын бер шигырем истә калган:

Летчик-космонавт

Гагарин Юрий,

Дөньяны шаккатырып,

Космоста йөри.

Менә шундый шигырьләрдән башладым инде.

Алмаз. Роберт абый, соңгы соравыбыз азрак уйландырыр, бәлки. Мөмкинлек булса, шушы мөхәррирлек вазифагызны, дәрәҗәләрегезне ташлап, балачакка кайтыр идегезме?

Р.Миңнуллин. Бернәрсәгә дә карамыйча чаба-чаба кайтып китәр идем һәм шунда, үзебезнең «Сабантуй» укучылары арасында калыр идем.

Алмаз, Рузилә (бер-берсен бүлдереп). Рәхмәт, Роберт абый. Олы бүләгегезнең рәхәтен күрергә язсын!

Мөхәррир яшь журналистлар Рузилә Мөхәммәтова белән Алмаз Гыймадиевның

кулларын кыса һәм иҗат уңышлары тели. Ишек ябыла.

Сөйләшү вакытында газетабызның фотографы Николай Седов килеп керде һәм

сиздермичә генә әңгәмәдәшләрне рәсемгә төшереп алды.

Роберт Миңнуллин кемгә охшаган?

Шагыйрь иҗаты турында

Роберт Миңнуллин кемгә охшаган?

Авылда егетләр күп була, ә менә көтүе белән малайлар ияреп йөргәне бер була. Рәхәт аның янында — төрле кызыклар уйлап чыгара ул, мавыгып киткәнеңне сизми дә каласың. Кирәк андый башлап йөрүчеләр — сокланып, охшарга тырышып үсү өчен кирәк. Егет үзе дә малайларсыз тора алмый: ник шунда сакаллы сабый дип әйтмәсеннәр, олыгайса да малайлыгын онытмас, һәр яңалыкка гаҗәпләнеп, тагын нинди кызыклар тудырып булыр микән дигән шаян-шук күзләр белән карар ул.

Роберт абыегыз Миңнуллин китабын укыганда бу хакта искә алуым бер дә юкка түгел, ул — нәкъ менә сез уйлаганча — әлеге наян егеткә охшаган! Мин аны беренче шигырьләреннән башлап беләм. Сез аларның күбесен яттан сөйлисездер. Бергә җыеп укыгач тагын да кызыграк икән — дуслар-танышлар җыелып күрешкән шикелле. Шагыйрьнең үзе кебек мыек астыннан гына елмаеп тора ул шигырьләр. Җавап итеп сез дә елмаясыз икән — бу инде аңлашу, дуслашу дигән сүз. Шаян шигырь бушка теш ыржайту түгел, тапкырлык, зирәклеккә өйрәнү ул. Нинди һөнәр сайласагыз да, йөгерек фикер йөртергә өйрәткән әсәрнең файдасы тими калмас. Әкияттә генә түгел, тормышта да зирәк, тапкырлар җиңә! Мин үземнең Шәвәлием белән кулга-кул тотынып Роберт Миңнуллинның Алмазы баруына шатмын. Андый дуслар күбәйгән саен, сезгә дә кызыграк булыр!

Охшашлык турында сөйли башлаган идем. Роберт Миңнуллин шигырьләрен укыйм да ирен читенә поскан елмаюында Әхмәт Фәйзи елмаюын танып алам. Аңарда үзе мыштым гына тыелып, бүтәннәрне көлдергән Бари Рәхмәт чалымы да сизелеп китә. Кемнәрдер Робертны хәтта Шәүкәт Галиевкә дә охшатып куялар. Минемчә, ул барыннан бигрәк... үзенә охшаган! Ә без, Әхмәт Фәйзи дә, Бари Рәхмәт тә, Шәүкәт Галиев тә, шулай ук Роберт Миңнуллин да — кыскасы, барыбыз да, тыйнак кына әйткәндә, сезгә, сезнең ихласлыкка, сезнең шаянлыкка охшаганбыз, дуслар!

Телевидениедән «Шигъри тәлгәшләр» дигән сезгә бик таныш тапшыру алып барганда Роберт Миңнуллин гел бүтәннәргә сүз биреп утыра. Ә менә бүгенге «тапшыруда» мин аның үзен сезгә тапшырам — сөйләр сүзе күп, тыңлагыз шагыйрь абыегызны!

Шәүкәт Галиев

1981

Җиде абый тай җигә

Һәр яңа китап — көтеп алынган кунак төсле. Ә һәр кунакның үз холкы, фигыле, гадәтләре дә үзенчә була. Берәүләр төрле мәзәкләр сөйләп көлдерергә ярата, көтелмәгән сораулар

биреп уйга калдыра, җитешмәгән җиренә бармак төртеп күрсәтүчеләр дә, акыл өйрәтергә яратучылар да бар...

Шагыйрь Роберт Миңнуллинның яңа китабы — шигырь сөюче дуслар белән танышырга теләгән кунагы — җор күңелле, ягымлы, игътибарлы кешеләргә хас гадәтләрнең барысына да ия.

Шагыйрьнең («Җиде абый тай җигә» дигән китапны әйтүем) һәр шигыре кояш нурына манылган, шуңа күрә аларны елмаюсыз укып та булмый:

Ялыкмыйбыз кояштан,

Кояш безгә гел кирәк,

Гел кояшлы җир белән

Гел кояшлы көн кирәк.

Кояшлы көндә малайлар өйдә утырамыни?! Алар сабан туенда: урамда качышлы уйный, җиде абыйның тай җиккәнен карап торалар, елгадан йолдыз чүплиләр, мөгезсез бозаулар белән сөзешәләр, әкәмәт җанварлар белән очрашалар. Хәер, барысын да санап бетереп кара, малайлар булган җирдә маҗаралы хикмәтләрнең бетәсе юк! Әнә шуңа күрә дә шагыйрь Роберт Миңнуллин малайларны бик ярата.
Ни генә дисәк тә, уен уен инде ул. Шаярулар белән гөрләп үтеп киткән һәр көнгә әниләр нәтиҗә ясый, ә нәниләр акыл җыя, җитдиләнә, сорау арты сорау яудыра, хыялларга бирелә.

Шагыйрь абыегыз сүз уйнатуга корылган шигырьләр дә алып килгән һәм бик дөрес иткән. Чөнки шигырьләре мәктәпкәчә яшьтәге балаларга бүләк ителгән ич, әйдә, укысыннар — телләре ачылсын, сөйләшергә, акыллы булырга һәм елмаерга өйрәнсеннәр. Нәниләр генәме? Юк, бу шигырьләрне кем генә кулына алса да укып бетермичә түзә алмас.

Көтеп алган кунагыбыз наян да, шук та, самими дә, хәйләкәр һәм тапкыр да, җитез дә... Шушындый кунакны якты йөз белән каршы алмыйча мөмкинме соң?!

Камил Кәримов

1981

Булатка күчтәнәч

Чаллыдан сеңлемнең малаеннан хат килде. Бер биткә өч кенә сүз язган: «Туган көнгә кил», дигән. Әнисеннән хат алдарак килгән иде, бик борчылып язган. «Апа, Булат татар мәктәбенә бармыйм, ди. Нишләргә инде? Бер вакыт табып, килеп китә алмассыңмы?» — дигән. Булат белән бу турыда авылда да сөйләшкән идек инде. Минем үземә дә: «Андрей кая барса, мин дә шунда укыйм», — дигән иде. Кат-кат сөйләшкәч, минем белән килешкән дә кебек булган иде. Шулай да аерылышканда: «Быел мәктәпкә бармыйм әле, матур итеп яза да белмим», — дип калган иде. Биш яшеннән үзлегеннән укырга өйрәнде. Әлифбасы «Вата-

ным Татарстан» газетасы булды. Хәрефләрне шуннан өйрәнде. Быел аңа 7 яшь тула, мәктәпкә бармый чарасы юк. Мин дә туган көнгә бармый кала алмыйм. Тик менә Булатны сөендерерлек бүләк кайдан табарга? Уенчык машиналары да бар, бер җизнәсе урыс булгач, күз явын алырлык бик матур урысча китаплары да күп. Һич башка килми, белмим, нәрсә алырга? Уйлап, эзләп йөрим.

Беркөнне китап кибетендә эшләүче ханым бер китап бирде. Шундый матур китап. Роберт Миңнуллин. «Күчтәнәч». Булат та китапны бик яратты. «Күчтәнәч», дип кычкырып укыды да: «ашыйм, ашыйм» дип көлдерергә тотынды. Роберт абыйсының рәсемен күргәч, күз кысып, пәп итеп алды да, телен күрсәтеп, «Әнкәмнең догалары», дип, икенче бүлмәгә кереп китте. Байтак кына вакыт тавышы ишетелми торды. Китабын кулыннан куймаган икән әле. Әйләнеп чыкты да:

— Яхшы бу, — диде.

— Ник яхшы? — дим. — Нәрсәсе яхшы?

— Тиз ятлана, тел тотлыгып тормый. Сөйлимме? — диде.

Алты строфалы «Йолдыз буласым килә» дигән шигырьне ятлап та өлгергән икән. Ошап киткән, әтисеннән, әнисеннән, апасыннан шигырь сайлата. Янәсе, аларга бүләк итеп ятлый.

— 1 сентябрь көнне укытучыңа сөйләргә ятлап куй, — дим.

Кашларын җыерып, тынып калды. Әтисенә-әнисенә карап-карап алды. Сизелеп тора — җилле-җилле сөйләшүләр булгалап алган. Шомлы тынлыкны Булат бозды, китабын ачып карады да:

— Казан апа, хәйләкәр син түлке, — диде. Көлеп рәхәтләнә үзе. Китабын тотып Андрейларга кереп китте. Чыккач: «Нишләп йөрисең?» — дип сорашам.

— Мин татар гимназиясенә барам, дип әйттем, китабымны да күрсәттем.

Сүзсез генә аңлаша алуга барыбыз да җиңел сулап куйдык. Гап-гади бер гаиләдә зур бер мәсьәләне хәл итешкән, чып-чын бәйрәм ясаган, барыбызны да сөендергән өчен Робертка бик зур рәхмәт. Бүгенге көннең шаян, шук, тапкыр, акыллы, хәйләкәр, усал малайларына-кызларына хуш килерлек китап чыгарган өчен «Мәгариф» нәшриятына да, Татарстан газета-журналлар нәшрияты басмаханәсенә дә рәхмәт яусын. Тик аптырап калдым. Булатка шундый китап бүләк иткәнемне ишетсәләр, башка нәни туганнарым үпкәләр кебек. Мин аны Камилгә, Ләйсән, Наилә, Айрат, Әлмира, Радик, Нәфисә, Фәнис, Ришат, Салават, Әнисә, Гөлназга да бүләк итәр идем. Барысы да мәктәп балалары. Ләкин, бик кызганыч, китапның тиражы биш мең генә, күрми дә калуыбыз бар. Хәер, бу китапның авторы Роберт Миңнуллин — Дәүләт Советының даими комиссиясе рәисе. Үз китабын күбәйтүне дә, балалар өчен затлы, зәвыклы шундый китаплар чыгаруны да, бәясен арзанрак итүне дә турыдан-туры кайгыртыр өчен сайлап куелган халык депутаты да. Чаллы малае Булаттан зур рәхмәт, сәлам аңа — яңа китап көтеп, борынын уа-уа шулай диеп калды.

Фәния Хуҗахмәт

1995

«Алма абый»дан күчтәнәч

Кадерле балалар!

Сезгә бу хезмәтне ихластан куанып һәм эчке бер горурлык хисе кичереп тәкъдим итәм.

Беренчедән, «Мәгариф» нәшрияты татар баласы кулына, ниһаять, чын мәгънәсендә күркәм, затлы китап тапшыра. Ул бары тик төсе-кыяфәте белән генә дә күзне иркәләп, күңелне яктыртып, югары зәвык тәрбияләүдә катнашыр иде.

Икенчедән, сезнең кулда — «май чүлмәге тышыннан билгеле булыр» дигән әйтемне раслап — тышкы кыяфәте-рәвеше белән эчтәлеге дә тәңгәл килгән китап. Дөресрәге (һәм иң мөһиме) — балалар өчен чын әдәбиятыбыз, ниһаять, үзенә лаеклы сурәттә укучыларына тәкъдим ителә. «Балаларга — яхшының да яхшысын» дигән сүздән эшкә күчүнең бер мисалы ич бу.

Өченчедән, әлегәчә чыккан китаплары бик гадәти, кайчакта бизәлеше белән «ямьсез генә булса да», Роберт абыегыз Миңнуллинның иҗаты, «бернигә дә карамый», дөнья күзендә танылуга иреште. Менә мондый китап рәвешенә кергәч инде, әлеге шигырьләр үзебездә дә, ниһаять, чын бәһасен алыр.

«Ниһаять, ниһаять...» дип кабатлыйм, чөнки өмет һәм теләк зур: милли яңарыш язбызда бу беренче карлыгач ялгызы гына калмасын, балалар өчен шундый затлы басмаларыбызга юл ачсын иде. Татар китабы, халкыбызга борын-борыннан хас булганча, милли горурлык тойгысының мөһим бер күрсәткеченә әверелсен иде!

Китапның исеменә дә игътибар иткәнсездер, әлбәттә. Алма апа — алма абый — алма бабай... Кардәшлекне шундый мәгънәле сурәт аша тою, шул рәвешле белдерү — монда татарның тел хасияте генә түгел, милли холкы-фигыле дә, әхлагы һәм яшәү конституциясе дә сыйган.

Кадерле балалар! Алдан белеп торам: бу китапны укыганда, сезнең күңел күзегез матурлыкны күбрәк күрә башлар, зиһенегез зирәк фикерләр белән ачылыр, телегезгә татлы һәм тапкыр сүзләр генә килеп торыр. Татар балалар әдәбиятының «алма абыйсы» шәп шигырьләр язганлыгына үзегез дә ышанырсыз әле.

Мөдәррис Вәлиев

1997

## «Алма абый» алмалары

Хәтерлим әле, мин нәни чакта күршебездә бер бабай тора иде. Аның бакчасында алмагачлар үсә. Һәр алмагачта алмалар санап бетерерлек түгел, күктәге йолдызлар санынча булгандыр, мөгаен. Җәй буе кояшның алтын нурларын үзләренә җыеп, көзгә алланып-балланып пешеп җитә иде алар. Без җәй буе авыз суларыбызны китереп аларга кызыгып йөри идек. Ә аннары көннәрдән бер көнне күрше бабай без сабыйларны бергә җыеп ала иде дә шул алмаларны безгә өләшә иде. Һәркемгә иң алы, иң тәмлесе, үзе кызыкканы эләгә иде.

Роберт абый Миңнуллинның «Кояш алмасы» дигән яңа китабын кулыма алгач та, әллә нигә генә күңелемдә шушы балачак хатирәсе яңарды, юмарт бабай искә төште. Роберт абыйның бала чагында да күршесендә шундый алма бабай яшәгәндер, юмартлыкка ул аңардан өйрәнгәндер дип уйлап куйдым. Әйе, әйе, мөгаен, шулайдыр. Югыйсә балаларга ел саен «бер бакча алма» бүләк итмәс иде. «Дөньядагы иң зур алма», «Алма бабай», «Кояш алмасы». Исемнәреннән үк авызга сулар килеп тора. Ә тышлары, рәсемнәре! Шаяртуымны төшенгәнсездер инде, шәт, сүзем Роберт Миңнуллинның соңгы елларда дөнья күргән китапларының алмалылары хакында. «Дөньядагы иң зур алма» китабының тышлыгында алма ашап, эче авыртып тәгәрәп яткан малай рәсеме. Шигырьләре дә кызык, көлә-көлә эчләр катып бетә. Китапның соңгы битен япканда эче авырткан малайның хәлен бик яхшы аңлыйсың. Аның комсызлыктан авырта, синең — күп көлүдән.

«Алма бабай» («Мәгариф» нәшрияты, 1997) — монысы алманың тагын да дәүрәге, тагын да тәмлерәге, тагын алланыбрак-балланыбрак пешкәне, сиңа гына дип өзелеп төшкәне. Кәгазе ап-ак, шома, рәсемнәре салават күперенең бар төсләрен үзенә җыйган. Шигырьләре мыек астыннан гына елмаеп нәниләрне тырышлыкка, җыйнаклыкка, тәртипкә, туган телне яратырга өйрәтәләр. Шагыйрь абыйның нәкъ үзе төсле. Аны укып чыккач... «мәктәптә күңеллерәк» икәнен беләсең (җәйге каникулдан соң шулай тоела икән ул). «Хикмәтле курай» эченә берьюлы тургайлар, былбыллар, аккошлар белән бергә чыпчыклар, каргалар, саесканнар кереп тулган икән. Ничек уйнап, кайсын чыгарасың инде... Безнең ил балалары гына түгел, Америкада яшәүче малай-кызлар да сугыш теләмиләр икән. Алар да атом, бомба, үлем дигән сүзләрдән куркалар, алардан котылу юлын эзлиләр. Ул чагында кемгә генә кирәк икән соң ул сугыш, кан коеш? Ничә яшеңдә булуыңа карамастан, китапны укыганда әнә шул сорауга җавап эзлисең. Латыш малайлары белән дуслашып, «Шигъри әлифба» укып, арып китсәң, рәхим ит — уен-шигырьләр. Аларны укып чыгып кына калмыйсың, рәхәтләнеп уйныйсың да. Авызың ачыла башладымы — алайса, әкият тыңларга вакыт. Үзең укый белмәсәң, әбиеңә йә абыеңа ялын. Китапта аз да түгел, күп тә түгел, төптөгәл биш әкият. Кечкенәкият дип аталсалар да, тыңлап бетергәнче йоклап киткәнеңне сизми дә калырсың. Әмма кайгырма, шүрәлеләр, батыр куяннар, куян йөрәкле бүреләр әкиятнең дәвамы булып төшеңә керер.

Алма күргәч, ашап карамыйча калып булмаган төсле, китапны да ачып, укып карамыйча түзеп булмый. Бигрәк тә мондыен.

«Алма бабай»ның алмаларын укыганда, шигырьләрен ашаганда (бәлки, киресенчәдер), «Их, күршедәге урыс малае Саша да, татар булса да, үз телен белмәүче Руслан да сыйлана алмый кала инде», — дип борчылган идем. Чөнки китаптагы шигырьләр тап-татарча гына. Татарстан Югары Советында Милли мәсьәләләр буенча комиссияне җитәкләүче шагыйрь абыйны да борчыган икән бу. «Кояш алмасы» (1998) дигән яңа китабын нәкъ телләр турындагы Законга туры китереп ике телдә — татар һәм рус телләрендә бастырган. Бер китапта ике телдә иң әйбәт илледән артык шигырь. Рәхәтләнеп укы, ятла, файдасы да икеләтә тияр. Татарча начаррак белсәң, йә булмаса, бөтенләй белмәсәң, өйрәнерсең. Кызык шигырьләр истә шәп кала. Әнә шулай алма ашап кына да тел өйрәнергә була. Рус телең чамалы икән, аны да биш бармагың кебек беләчәксең. Чөнки китап нәкъ әнә шул максат белән дөньяга чыккан да инде.

Алма дип сөйли торгач, авызыгыздан сулар килдеме? Юмарт абыйның тәмле алмаларыннан авыз итәргә уйладыгызмы? Барыгыз, алайса, тизрәк китап кибетләренә. Исемнәре «алма» булса да, алыгыз сез аларны, алданып алмый калмагыз тагын. Рәхәтләнеп сыйланыгыз ал, кызыл, баллы, татлы алмалар белән...

Йолдыз Шәрапова

Гомерлек юлдашыгыз

Хөрмәтле укучым! Бүген син, бәлки, кулыңа беренче мәртәбә китап алгансыңдыр. Төртелә-төртелә беренче шигырь юлларын укыйсыңдыр. Хәреф танудан, иҗекләрдән сүзләр, сүзләрдән җөмлә җыеп алуыңа шатланасыңдыр. Әйе, укый белү — шатлык, китап — җиде кат күкләрнең ишегенә ачкыч. Шушындый тылсымлы ачкычны безнең кулларыбызга кем тоттыра соң? Әлбәттә, шагыйрьләр, әдипләр. Бүген без шундый тылсымлы ачкыч өләшүче шагыйрь Роберт абыегыз Миңнуллин турында сөйләшербез.

Дустым, син әле, бәлки, балалар бакчасына йөрүче иркә кыз яки шаян малайдыр. «Акбайга», «Өлкәннәр», «Туган илнең улы мин», «Бакча белән хушлашу» кебек шигырьләрне сиңа тәрбияче апаң өйрәтәдер. Син аларның авторы кем икәнлеге турында да уйламыйсың. Сине шигырьләрнең сыгылмалылыгы, сүзләрнең бер-берләре белән ярашып килүе, шигырьләрдәге тапкырлык-җорлык җәлеп итә. Тәрбияче апаң артыннан кабатлый-кабатлый күңелеңә образлы шигырь юлларын сеңдерәсең. Ә өеңә кайткач, зур батырлык эшләгәндәй, ул шигырьне әти-әниләреңә, әби-бабаларыңа сөйлисең. Синең белән алар да шатлана.

Соңыннан гына сиңа шундый бәхетле мизгелләр бүләк итүче шагыйрь абыйның Роберт Миңнуллин икәнен белерсең. Бәлки, син әлегә татарчаны бик үк тирәнтен аңлап бетермисеңдер. Теләгең булса, туган телне өйрәнергә дә Роберт абыеңның шигырьләре ярдәм итәр. Алар бер укуда истә кала торган итеп җиңел тел белән язылган. Ә инде бөтенләй төшенеп җитмәгән җирләр булса, русчасы белән чагыштырып укырга мөмкин. Роберт абыең Миңнуллинның «Наш тигренок», «Глядит в окошко человек», «Сладкая крапива», «Утренний снег» китапларын, бәлки әле, әти-әниең синең туган көнеңә бүләк тә иткәндер. Алар ярдәме белән син андагы кызыклы, маҗаралы, серле шигырьләр дөньясына чумарсың. Бәлки, синең күңелең җырга тартыладыр. Рәхим ит, радиоалгычыңны кабызып кирәкле дулкынга көйлә. Роберт абыеңның синең кебек нәниләргә атап язган «Әйлән-бәйлән», «Чишмә җыры», «Әни кирәк» кебек җырлары бик күп. Әгәр инде йоклар алдыннан әкият тыңлыйсың килсә, ул сиңа күптән таныш авторның шигъри әкиятләрен укып, күңелеңне тынычландырыр. Син матур әкияти төшләр күрә-күрә йокларсың.

Менә син, балалар бакчасы белән хушлашып, мәктәпкә керәсең. Китапларны инде кеше ярдәменнән башка гына укый аласың. Балалар бакчасыннан ук сиңа таныш Роберт абыең белән инде кабат очрашасың. Дәреслек битләрендәге шигырьләр генә сиңа аз тоелса, китап кибетенә кереп «Балачак бәйрәмнәре», «Безнең авыл зоопаркы», «Энекәш кирәк миңа», «Җәйнең яшел аты» кебек нәкъ сиңа адреслап язылган китаплар алып кайта аласың.

Кайчак шигырьләр укыганда шатлык йөрәккә сыймый башлый, ул шатлыкны дустың белән уртаклашасы килә. Шигырьләр үзара бәхәс тудырырга да мөмкин. Бәхәсләшегез, дәреслекне эзләгез, матурлыкка юл салыгыз.

Балачак — җиде кат күкнең беренче ишеге. Сиңа шагыйрь абыең менә шушы ишекнең ачкычын бирде.

Бәйрәмнәр бик күп булай да,

Ә шулай да, ә шулай да

Иң шәп бәйрәм — балачак, —

ди шагыйрь.

Әйе, балачак — бәйрәм. Ләкин әле шушы бәйрәмнәр эчендә дә бәйрәмнәр бар. Сабантуй бәйрәмен генә алыйк. Бу бәйрәмдә шатлык салават күпере булып балкый. Роберт абыеңның китапларыннан да син бу бәйрәмнәрнең бик күп бизәкләрен, бик күп төсләрен табарсың.

Ниһаять, син үсмер булдың. Күңелеңә беренче мәхәббәт кошы оя корды, җаныңны каядыр ашкындыра; син үзеңнең хисләреңне күз төшеп йөргән кешеңә аңлатырлык сүзләр эзлисең. Монда тагын ярдәмгә сиңа шагыйрь Роберт абыең килә. Аның узган ел гына чыккан «Сандугачның туган көне» дигән китабы нәкъ менә синең өчен. Андагы лирик шигырьләр синең күңелеңнең тетрәнүләрен, ашкыну-җилкенүләрен, мәхәббәт газапларының татлылыгын, аерылып торуларның сагышын сөйли.

Бәлки әле, син аның ун елга якын телевизордан алып барган «Шигъри тәлгәшләр»ен карап үскәнсеңдер.

Кыскасы, Роберт абыең шигырьләре гомер буе сиңа юлдаш. Алар сине һәрвакыт озата, каршы ала, сөенечләреңне уртаклаша, көенечләреңне киметә. Шагыйрь Роберт Миңнуллин нәкъ менә шуның белән бәхетле дә инде.

Бик күп укучыларның үз шагыйре, яраткан шагыйре Роберт Миңнуллинның «Энекәш кирәк миңа», «Балачак бәйрәмнәре», «Наш тигренок» дигән китаплары быел Республикабызның Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә тәкъдим ителде.

Танылган рус шагыйре С.Михалков Роберт Миңнуллинның иҗаты турында болай дип язган иде: «Бик акыллы, бик файдалы булсалар да, кызыксыз китапларны беркем дә укырга яратмый. Роберт Миңнуллин кызыклы итеп, күңелле итеп яза. Аның шигырьләре татар шигъриятенә курай моңы булып килеп керде».

Әйдәгез, дуслар, без дә Роберт Миңнуллинга уңышлар телик. Курай моңы тагын да көчлерәк яңгырасын!

Фәнис Яруллин

1998

«Тәмле күчтәнәч»

Авыл күчтәнәчләре төяп, киң болыннарда печән чабып, Сөн буендагы әрәмәлекләрдән бөрлегән, урман аланлыкларыннан җиләк җыеп, кыскасы, еллык энергия туплап, Актаныштан Казан аэропортына очып төштек. Кайбычка кайтасы автобус китәргә әле шактый вакыт булганлыктан, гаиләбез белән Бауман урамына юнәлдек. Иң беренче каникулын Байсар әбиләре янында үткәргән Резедә дә, апасы белән ял итеп, безнең якларча «нәмә, нәмәкәй, бармаем, ашамаем» дип сөйләшергә өйрәнеп килгән өч яшьлек Эльвира да шәһәр тәм-томнарын сагынганнар. Кибетләр карап, Бауман урамының матурлыгына сокланып йөри торгач, «Китаплар» кибетенә дә килеп җиткәнбез. Хәрефләр, сүзләр дөньясы белән таныша гына башлаган Резедәбезнең күзе матур рәсемнәр белән бизәлгән китап киштәсенә төште, ә укырга теләге булган сабыйга каршы килеп булмый инде: «Ошаганнарын сайлап ал, кызым», — дидем.

Ул җыйган бер кочак китап арасында барыбызның да күңеленә хуш килгәне, әлбәттә, балалар шагыйре Роберт Миңнуллинның «Күчтәнәч»е булды. Автобуста да балаларның кулыннан төшмәде бу китап.

Татарстан Республикасының халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, Г.Х.Андерсен исемендәге Халыкара диплом иясе Шәүкәт Галиевнең «Сөенсеннәр әле сабыйлар» дип исемләнгән кереш сүзе белән башланып киткән бу китап чынлап та сөенерлек шул. «Мәгариф» нәшриятында төсле рәсемнәр белән бизәлеп чыккан ул, берсеннән-берсе матур, эчтәлекле шигырьләре тупланган. Кызганыч, без үскәндә «Күчтәнәч»тәй дизайнда эшләнгән китаплар юк иде. Тирән эчтәлекле, беркемне кабатламый торган итеп бары тик балалар психологиясен аңлаучы, үзенең дә күңеле сабыйларча саф, эчкерсез булган шагыйрь генә иҗат итә. Роберт абый, һичшиксез, шундый шагыйрь. Балалар теле белән язылган бу китапта бернинди купшылык, рәсмилек юк, шигырьләре нәкъ балаларча «сөйли». Юкка гына кызларым китапны укыган саен шигырьләрдә үзләрен күрәләрмени?!

Әни кайтып керде дә:

— Пыр тузган өй эче! — ди. —

Ах, тәлинкәм ватылган,

Кайсыгызның эше? — ди...

Соң, минекеләр булмыйча, кем булсын инде бу өй туздыручылар. Әти белән әнине дә еш очратабыз без бу шигырь дөньясында.

Китаптагы рәсемнәр дә шигырьләргә тәңгәл килә. Тышлыкта сурәтләнгән эчкерсез елмаюлы ак әби белән көләч йөзле бабай, кунакка килгән оныклары белән әнисен әнә ничек шатланып каршы алалар!

Шушы рәсемгә карап, «Күчтәнәч»не укып, кызларым әледән-әле авылда яшәүче әби-бабайларын искә төшерәләр, аларны сагынып сөйлиләр. Әнә нинди тәрбияви рольгә ия ул китап. Онытмасыннар, игелекле булып үссеннәр, буш күңелле булмасыннар иде алар. Кышкы шәһәрдән стадионда балалар уенын, авыл табигатен сурәтләгән рәсемнәргә дә күпме мәгънә салынган! Ирексездән туган авыл, ваемсыз балачак еллары искә төшә.

Ятабыз Сөн буенда,

Барыбыз да — уенда.

Коену да кызыну

Барыбызның уенда.

Шомырт, чия, бөрлегән,

Җиләк җыябыз аннан.

Телләр ачыта башлый

Кып-кызыл карлыганнан.

...Беркөнне Резедәне күрше малаеның туган көненә чакырдылар. Нәрсә бүләк итик икән дип бераз югалыбрак калдым. Кыз бала булса, кызлы өйдә һәрчак ни дә булса табарга мөмкин. Ә менә ир балага бүләк сайлау авыррак булды. «Кызым, әйдә без аңа «Күчтәнәч»не бүләк итәбез. Менә күреп торырсың, Илнар аңа һичшиксез шатланачак!» Ләкин аның яраткан китабыннан һич кенә дә аерыласы килмәде. Әтисе бу китапны, һичшиксез, яңадан алып кайтам дигәч кенә ризалашты. Әти сүзендә торды: яңадан «Күчтәнәч»ле булдык.

Рәхмәт сиңа, Роберт абый, чын күңелдән язылган шигырьләр өчен! Рухи азык кына түгел, йөрәккә дәва да әле ул сезнең шигырьләр.

«Күчтәнәч» китабы өчен шагыйрь Р.Миңнуллинның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә тәкъдим ителүенә безнең гаилә кебек меңләгән гаиләләр шатлангандыр дип уйлыйм. «Күчтәнәч» чынлап та бик тәмле бит.

Луиза Сөнгатуллина

1998

Татар теле –

шагыйрьләр теле

Азаматның төн буе теше сызлады. Мендәрен кочаклап, кырык кат җәймәгә чорналып, ятагының барлык почмакларында да булып чыкты. Алай да елап әнкәсе янына кермәде, таң атканчы түзде.

Иртән әнисе, улының йөзенә карауга ук хәлен аңлап, дару каптыргач кына бераз тынычланды малай. Әмма мәктәпкә барырлык чама барыбер юк, теш табибына — бигрәк тә.

Олылар һәрчактагыча эшкә ашыктылар, Азаматка көнозын өй саклап утыру күңелсез буласы билгеле иде. Улының рәсемле китаплар яратканын белгән әтисе, портфеленнән алып, өстәлгә өр-яңа китап куймаган булсамы!

Ишек шалтыр-шолтыр бикләнеп, аяк тавышлары тынуга, сөенеп, яңа танышын кулына алды малай.

«Дуслашасым килә», «Мәгариф» нәшрияты дип тиз-тиз генә йөгерде күзләре китап тышыннан. Китапның беренче битенә үк «Стихи поэтов России, стран СНГ и Прибалтики для детей» дип куелган һәм «Роберт Миңнуллинның ирекле тәрҗемәләре» диелгән икән.

Роберт абыйсының китапларын укырга ярата Азамат. Чөнки аның шигырьләрендә балалар шук та, шаян да, тиктормас та; шул ук вакытта алар җитди дә, батыр да, уйчан да була беләләр. Ә бу китап тагы да кызыграк булырга тиеш! Төрле ил шагыйрьләре иҗаты туган телемдә — татарчага тәрҗемәдә матуррак та яңгырыйдыр әле, дип уйлады малай.

Шул ук «Мәгариф» нәшриятында дөнья күргән «Алма бабай» китабын бергәләшеп укыганда, апалары, Роберт абый Миңнуллинның шигырьләре дә рус, башкорт, чуаш, төрек, украин, белорус, эстон, казах, удмурт, мари, каракалпак телләренә тәрҗемә ителгән, дип әйткән иде бит. Әле «Мәгариф» нәшриятында басылган «Күчтәнәч» исемле китабының Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булганын да яхшы хәтерли Азамат. Ник дисәң, Тукай туган көнне Шигырь бәйрәменә класслары белән җыйнаулашып барганнар иде...

Беренче укыган «Дустымны эзлим» дигән шигыре үк үзенә охшаган булып чыкты малайның. Азамат та этен югалткач ничек борчылган иде! Бәхеткә, табылды тагын Актәпие.

Китапның алдагы битләрен бер-бер артлы ачып укый башлагач, һәр шигырендә йә үзен, йә дусларын танып гаҗәпкә калды Азамат. Ә рәсемнәре! Рәссам Нияз абыйсы Хаҗиәхмәт тә үзенең малай чагын исенә төшереп утыргандыр, ахры, ул сурәтләрне ясаганда.

Кара син аны, башка ил балалары да нәкъ Азамат һәм аның иптәшләре кебек икән бит. Аларда да шул ук «проблемалар»... Мәсәлән, җәнлекләр уйлый микән, дип, үзенең генә түгел, әтисенең дә башын катырган иде малай. Баксаң, уйлый-сагышлана белә алар да. Малайлары «икеле» алганга барлык әти-әниләр бертөрле борчыла икән. Аларда да җәйләр — җылы, кышлар — кырыс, көзләр — көләч, язлар — ямьле, яңгырлар — ягымлы, җилләр сөзгәк икән.

Китап юкка гына «Дуслашасым килә» дип аталмыйдыр шул. Менә шундый гаҗәеп уртак уй-фикерле китапларны укып үскән малай-кызлар дәү булгач та дус-тату яшәргә тиеш ич инде! Бәлки, киләчәктә Җир шарында сугышлар гел дә булмас әле...

Ахырдан, китапны рәхәтләнеп укып чыгып, кат-кат әйләндерә торгач, «Издается по Федеральной программе книгоиздания России» дигән җөмләне дә табып алды Азамат. Анысын бик үк төшенеп җитмәде, иртәгә үк укытучысыннан сорарга уйлап куйды. Ул арада төн йокламау үзен сиздерә башлады: малайның керфекләре йомылды, һәм ул китабын кочаклап йоклап китте. Мизгел эчендә китапның шигырьләре генә түгел, рәсемнәре дә җанланып, Азамат белән бергә салават күпере сиртмәсендә кояш нурларына тотынып, таган атыналар иде инде.

Нурзидә Нотфуллина

2000

Көчтәнәчле күңел

Озак еллар инде Башкортостанда шушындыйрак сүзләр телдән төшми:

— Иң оста игенчеләр кайда?

— Илештә.

— Иң нурлы каеннар кайда?

— Илештә...

Һәм башкалар, һәм башкалар... «Илештә — ил эштә» дигән сүзләрне дә еш кына ишетергә туры килә. Илештә уңган, тырыш кешеләр яши һәм эшли дигәнне аңлата булары.

Илеш дисәм, дустым, каләмдәшем Роберт Миңнуллин исемә төшә. Ул да шушы төяктә, Сөн буйларында, 1948 елда дөньяга килгән. Ул да илешләр шикелле. Озын-озак сүз куер-тып, теленә бизәлмәс. Мыек астыннан гына елмаеп, үз эшен эшләп йөрер. Бу хакта мин дөрес әйтәмдер. Чөнки Роберт белән кайчан очрашып, дуслашып киткәнбездер — хәтер-ләмим дә. Әмма бер-беребезне туганнан бирле беләбез төсле, хәтта яшь аермалары да онытыла: бер сукмакларда йөгерә-йөгерә үскәнбез, бер суларны чәпелдәтә-чәпелдәтә кич-кәнбез кебек.

Бу дөньяда (бәлки, бөтен заманнарда да шулай булгандыр инде) шагыйрь булулары җиңел түгел. Язмыш биргән бер могҗиза — татлы газап ул. Өстәвенә гомер буе журналистлык йөген дә армый-талмый тартып баручыларга мин сокланып бетә алмыйм. Кушйөрәкле әкият батырларына охшаган алар. Роберт Миңнуллин да, Казан дәүләт университетын тә-мамлагач, Татарстан телевидениесендә, «Казан утлары» журналында, балалар матбуга-тында күпме көч салды! Хәзер килеп, шагыйрьгә «дәүләт эшлеклесе» дигән олы бурыч та өстәлде: ул озак еллар инде халык депутаты, алай гына да түгел, Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары. Нихәл итәсең инде, саулык бирсен дә каләмдәш дустыбызга, түземлек-ләр бирсен, дияргә генә кала. Бирешмәс! Илеш улы бит ул! Теленә бизәлмәс, мыек астын-нан гына елмаеп, үз эшен эшләп йөрер...

Нинди генә заманнар, нинди генә шартлар туса да, шагыйрь шагыйрь булып кала. Роберт моны үз язмышында, үз иҗатында кире каккысыз итеп раслый килә. Яңадан-яңа җыентык-лары дөнья күрә. Әгәр аларның бөтенесен дә саный китсәң, миңа бу мәкаләне язу ансат булыр иде: берничә биткә китаплар исемлеген тез дә чык. Уйлый төшсәң — таң калыр-лык! Һәр китабың дөнья күрсен өчен күпме көч-дәрман, азмы алсыз-ялсыз тырышлык, тынгысыз көннәр, йокысыз төннәр кирәк.

Роберт Миңнуллинның тормышы да, иҗаты да киң колачлы. Ул өлкәннәр өчен дә менә дигән китаплар чыгара. Ә җырлары соң? Үзләре генә дә аерым җыентык булып дөнья күр-де. Сирәк талантларга гына эләгә мондый бәхет. Чыкты да юк та булды ул китап. Чөнки бер-ике тыңлау белән күңелләрдән күңелләргә, йөрәкләрдән йөрәкләргә очып китә аның җырлары. Шуның өчендер дә Роберт Миңнуллин — башкорт һәм татар халыкларының иң популяр, иң яраткан шагыйрьләренең берседер.

Ә каләмдәш дустымның балалар өчен язган китаплары миңа аеруча кадерле. Бәләкәчләр өчен яза алу сәләте дә бик сирәкләр өлешенә төшкән бәхет. Сабыйның теле ачылганда ук синең сүзләреңне тәтелди, балалар бакчасында, мәктәптә синең сүзләреңне сөйли яки көй-ли икән — шуннан да зуррак куаныч бармыни?! Алар үзләре белән сине дә киләчәккә алып барачак лабаса!.. Гадилектә — бөеклек, диләр. Балалар өчен язылган әсәрләрендә Ро-бертның осталыгы, таланты аеруча ярылып ята. Менә бер генә мисал. «Көләч шигырь» дип атала ул: «Кояш көлә, Гел көлә, Кояш көлгәч, Көн көлә. Көн көлгәчтен, Гөл көлә, Гөл көлгәчтен, Кем көлә? — Гөл көлгәчтен, Мин көләм. Кояш көлә, Мин көлгәч... Шуңа да мин Гел көләч!» Бу әсәр хакында әллә күпме сөйләргә, аңлатырга тырышырга мөмкин бу-лыр иде. Әмма аның бөтен серлелеге дә шунда шул: һәйбәт шигырь үзе хакында үзе сөйли дә куя, башка бер сүзең дә кирәкми төсле.

Роберт Миңнуллин китапларының исемнәре үк укучыны серле шигърият дөньясына әйдәп тора: «Акбай цирк карый», «Җиде абый тай җигә», «Җәйнең яшел аты», «Безнең авыл зоопаркы», «Дөньядагы иң зур алма», «Күчтәнәч» һ.б., һ.б...

«Дөньядагы иң зур алма»ны да тапкан шагыйрь. Татарстанның Муса Җәлил исемендәге яшьләр премиясе лауреаты Роберт Миңнуллинга бу китап дөнья күләмендә дан китерде — аңа Г.Х.Андерсен исемендәге Халыкара әдәби бүләк тапшырылды. Бу тәңгәлдә шуны да әйтеп үтәсем килә, татар әдәбияты белән башкорт әдәбияты балалар шигърияте буенча тын гына ярыш ачканнар төсле. Ярый әле үпкәләшерлек түгел, исәп әлегә тип-тигез: Г.Х.Андерсен исемендәге Халыкара бүләк Татарстанда Шәүкәт Галиев һәм Роберт Миңнуллинга, ә Башкортостанда Мостай Кәрим һәм миңа («Тылсымлы шар» китабы өчен) бирелде...

«Күчтәнәч» дигән җыентыгы да олы шатлык китерде шагыйрьгә. Роберт Миңнуллин шушы мәһабәт китабы өчен бөек Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды.

Бер-беребез белән очрашыр булсак, йөгерә-ашыга күчтәнәчләр эзләргә тотынабыз. Кадерле дустыңа әллә ниләр табасы, тапшырасы килә. Ләкин безнең өчен иң кадерле күчтәнәч-бүләк — үзең язган китап! Хөрмәт иткән дус-ишләрең, иптәшләрең янына барганда татлы-затлы күчтәнәчләр эзлисең. Күчтәнәчле кунак килсә, бездә сөенчеләп каршы алалар. Юмарт күңелле шагыйребез Роберт Миңнуллин да туар елларда тагы да күбрәк әсәрләр язар, аларны күчтәнәч итеп алып килер. Сөенчеләп каршыларга язсын!

Сафуан Әлибай

2001

## Айга бергәләп очыйк!

Кем генә башындагы бүреге шапылдап җиргә төшкәнче йолдызларын ияртеп йөргән Айны күзәтми?! Кайсы гына малайның йә кызның Айга менеп түбән карыйсы килми икән?.. Бик килә, бөтен кешенең дә менәсе килә Айга! Тик бер дә ансат эш түгел шул.

Ә шагыйрь Роберт абыегыз Миңнуллин исә, теләгән кешене Айга алып менәм, ди. Үзенә команда туплый. Ышанмасагыз, әнә аның күптән түгел генә басылып чыккан яңа китабын укып карагыз. Ышанмаган кеше шуннан соң ышаныр. «Айга очтык!» дип атала ул китап.

Әгәр дә кем дә кем аның командасына эләгә алмый кала икән — офтанмасын, бу китапны укыса болай да очачак. Әйе, чынлап та! Чөнки бу китап яхшылыкка өйрәтә. Ә яхшы кеше Айга оча да оча инде ул!

Айга нинди кешенең очканын, ниндиенең җирдә генә калганын үзегез дә белерсез әле. Әнә анда «Үч итеп» дигән шигырьдә берәү очарга хыяллана. Тик, белмим, оча алыр микән? Чөнки трамвайда билетсыз, «куян» булып йөри бит ул!

Һәрнәрсәдән үзенең даны өчен батырлык эзләп йөргән малай да ерак китә алмастыр. Башта батырлыкның нәрсә икәнлеген белсен, аңласын.

Ә менә «Бүтәннәр күрмәсә дә» дигән шигырьдәге малай Айга менәр. Уенда гел яхшылык кына бит аның. Андыйлар исә космонавт булырга лаеклы инде!

«Әни эштән кайтканчы» шигырендәге малайлар-кызлар да яхшылык эшләргә тырышып карыйлар каравын... Әмма мин аптырап калдым әле. Алар эшләгән эш яхшылыкмы соң? Әйдәгез, бу турыда бергәләшеп уйлашыйк!

Китаптагы һәр бүлек бик кызыклы. Теләгән кеше «Шигъри зоопарк» бүлегенә керә ала. Ни генә юк ул зоопаркта! Чебиләренә тисәң, авырттырып тәпиеңне чукый торган кызыл тавык дисеңме, атказанган сандугач, нәни поши, аерылмас өч дус — Акбай, Актүш, Актырнак, шапырынган малайны мөгезсез килеш тә сөзеп еккан бозау — һәммәсе дә бар.

Аннан соң, кемнең мөгезле болыт күргәне, кемнең җәяүле буран белән бергә автобуста утырып йөргәне бар? Ничек һәм нинди икәнен әйтеп тормыйм. Китапны укыган кеше үзе күрер, үзе утырып та йөрер.

«Айны ничек менгезим?» исемле шигырьдә берәү айның яртысы Иделдә йөзеп йөргәнен күргән. Шуны тотып алып, космонавт абыйларга биреп менгезмәкче була. Аның урынында булсам, мин бер дә ашыкмас идем әле. Бераз гына көтеп, түзеп торыр идем. Ә аннан шушы китапны укып, киләчәктә космонавт булачак малайга яки кызга бир дә җибәр.

Зиннур Хөснетдинов

1982

«Шигъри тәлгәшләр»

— Безнең мәктәпкә шагыйрь Роберт абый Миңнуллин килгән.

— Ялгышасың...

— Ничек ялгышыйм инде?! Мин бит телевизордан «Шигъри тәлгәшләр» тапшыруын калдырмыйча карап барам.

— Мыеклымы ул абый?

— Әйе!

— Алайса, Роберт абый Батуллин инде ул. Син аларны бутагансың.

— Шагыйрь абыйлар мыек йөртмиләр. Әкиятче абыйлар гына мыеклы була, аларга мыек килешә дә, бик беләсең килсә.

— Юк, бу — Роберт абый Миңнуллин.

— Ышанмасаң, бүген «Кичке әкиятләр» тапшыруын кара. Аны Роберт абый Батуллин алып бара...

Әгәр дә шигырь сөючеләр белән әкият яратучылар арасында мондый бәхәсләр килеп чыга икән, бер дә гаҗәпләнмәгез: ике якта да хаклык бар. Чынлап та, Роберт Миңнуллин да, Роберт Батуллин да телевизордан тапшырулар алып баралар, икесе дә мыек йөртәләр.

Шуңа күрә без сезне, кадерле укучылар, журналыбызның бу сәхифәсендә шагыйрь Роберт Миңнуллин белән таныштырырга уйладык. Әкият яратучылар тагын теге сүзләрне кабатлый калса, шагыйрь абыегыз мыек астыннан гына елмаер да: «Шаяртмагыз!» — дияр. Әйе, ул шулай тыйнак кына, эчкерсез итеп елмая белә. Әллә шул тыйнак шаянлыгы, эчкерсезлеге балалар өчен шигырьләр язарга булыштымы икән аңа?.. Юкса сез тын да алмыйча укырлык шигырьләр яза алыр идеме икән ул?!

Тик иң мөһиме Роберт Миңнуллин балаларны ярата, инде менә алты ел буе Казан телевидениесе буенча «Шигъри тәлгәшләр» исемле тапшырулар оештыра. Телевидениенең атналык программаларын карасагыз, анда еш кына шундый сүзләрне очратырсыз:

«Шигъри тәлгәшләр». Тапшыруны шагыйрь Роберт Миңнуллин алып бара.

Беренче тапшыру 1976 елның 22 сентябрендә булган иде. «Шигъри тәлгәшләр» ул чакта шагыйрьнең үз иҗатына багышланган иде. Шуннан соң «Шигъри тәлгәшләр»нең саны илледән артып киткән.

«Авылда егетләр күп була, ә менә көтүе белән малайлар ияртеп йөргәне бер була, — дип яза Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты шагыйрь Шәүкәт Галиев Роберт Миңнуллинның быел дөнья күрәчәк «Айга очтык» исемле китабына кереш мәкаләсендә. — Рәхәт аның янында — төрле кызыклар уйлап чыгара ул, мавыгып киткәнеңне сизми дә каласың. Кирәк андый башлап йөрүчеләр. Сокланып, охшарга тырышып үсү өчен кирәк. Егет үзе дә малайларсыз тора алмый: ник шунда сакаллы сабый дип әйтмиләр, олыгайса да малайлыгын онытмас, һәр яңалыкка гаҗәпләнеп, тагын нинди кызыклар тудырып булыр микән дигән шаян, шук күзләр белән карар ул».

Әйе, шул «Шигъри тәлгәшләр»нең бер генә тапшыруын карагыз сез: Роберт абыегыз янында төркеме белән малайлар һәм кызлар утырыр. Алар шагыйрьләребезнең шигырьләрен укыйлар, һәм, әлбәттә, матур итеп укыйлар. Бәлки, ул кадәр үк матур укый да алмаслар иде, Роберт абыегыз Миңнуллин һәм «Шигъри тәлгәшләр» тапшыруының даими режиссеры Лилия апагыз Нигъмәтова өйрәтә шул аларны! Аннары, тапшырулар кайда гына оештырылмый: болын-урманнарда, зоопаркларда... «Шигъри тәлгәшләр»дә йөзгә якын балалар шагыйренең шигыре яңгыраган.

Таныш булыгыз: «Шигъри тәлгәшләр». Тапшыруны шагыйрь Роберт Миңнуллин алып бара.

Хәйдәр Гайнетдинов

1982

Шагыйрьнең дөнья балаларына әйтер сүзе

Авылда чишмәләрне карап-чистартып торучы агайлар була. Балалар язучыларын мин әнә шул мәрхәмәтле кешеләргә охшатам. Алар да халкыбызның, әдәбиятыбызның киләчәк чыганагы булган балаларны — күңел чишмәләренең чисталыгын кайгыртып яшиләр, аларга үз юлларын табарга, алга омтылырга булышалар.

Татар балалар шигъриятенең бүгенге Иделе дә халык иҗаты дигән бик борынгы чишмәләрдән башланган. Сигез гасыр элек Кол Гали бабай баккан аны, йөз ел элек бөек Тукаебыз агымын көчәйтеп җибәргән. Такташ, Җәлил, Фатих Кәрим, Әхмәт Фәйзи, Бари Рәхмәт, Хәсән Туфан, Шәйхи Маннур кебек ихлас җаннар кайгырткан ул чишмәне.

Безнең бүгенге татар совет балалар поэзиясе турында сүз барганда, без ул бөтенсоюз дәрәҗәсенә җавап бирерлек таләпләр югарылыгында тора, бөтен дөнья аренасында ярышырлык чамасы бар дип икеләнмичә әйтә алабыз. Күптән түгел дөнья күргән «Татар балалар поэзиясе антологиясе» — моның ышандыргыч дәлиле.

Балалар поэзиясенең бүгенге уңышларында шагыйрь Роберт Миңнуллинның да зур хезмәте бар. Соңгы елларда иң актив һәм киң колач белән эшләүче шагыйрь ул. Аның лирик шигырьләрен, җырларын да укучы яратып кабул итте. Әмма аның балалар поэзиясе өлкәсендә ирешкәннәре аеруча вакыйга булды дип саныйм. Роберт балалар дөньясына баш-аягы белән чумды, бу жанрны үзенең төп миссиясе итеп кабул итте.

«Акбай цирк карый», «Җиде абый тай җигә», шулай ук быел чыккан «Айга очтык!» исемле китаплары, аннары телевидение буенча алып бара торган «Шигъри тәлгәшләр» исемле тапшырулар циклын республикабызның М.Җәлил исемендәге комсомол премиясенә тәкъдим итү Р.Миңнуллинның балалар поэзиясендә ирешкәннәрен тану, балалар әдәбиятында игътибарга лаеклы вакыйга булуын билгеләү дип беләм. Ул шигырьләр якты, оптимистик рухлы, кызыклы һәм мавыктыргыч — нәкъ менә бүгенге бәхетле балалар тормышы аларда. Тынгысыз һәм зирәк, эзләнүчән һәм ихлас бер дөнья ул. Роберт шул дөньяга яратып һәм үзенчә елмаеп катнаша тора, балаларның яхшы булып үсүләрен тели. Моңа ирешүнең төрле чараларын — мөлаем юмордан ачы сатирага хәтле булган барлык төсмерләрне файдалана. Теле гаҗәеп табигый һәм халыкчан — шигырьләренең бала күңеленә тиз үтүенең бер сере шундадыр.

Баланың мәгълүм яшенә хас булган үзенчәлекләрен яхшы белә Роберт, бу өлкәдә өйрәнүэзләнүләренең тирәнлеге, фәннилеге күренә. Балалар һәм олылар дөньясының бергә яшәвен, өлкәнәйгәч ачыласы сыйфатларның балаларда борынлап килүен шагыйрь яралгы хәлендә күрсәтә, балаларны олы тормышка әзерләү турында кайгырта. Шаярган булып кына җитди фикерләр салып куя, бала күңелендә тынгысыз уйлар кузгата.

«Айга очтык!» исемле җыентык «Дөнья балаларының кешелеккә әйтер сүзе» дигән шигырь белән тәмамлана. Шагыйрьнең балалар дөньясына һәм олыларга әйткән сүзләренең иң югары ноктасы бу. Катлаулы һәм хәвефле көннәребезнең кайнар сулышы сизелә анда, уйсыз-кайгысыз нарасыйларны да читләтеп үтмәвен күрсәтә.

Без мәктәптә укыган елларда дәреслекләрдә Испания вакыйгаларына багышланган «Сез миңа да мылтык бирегез!» исемле шигырь бар иде. Чын гражданлык, интернациональ дуслык тойгысы булып күңелдә калган ул. Робертның шигыре әнә шул әсәр белән аваздаш, Ливан вакыйгалары уңае белән ул гаҗәеп актуаль яңгырап китте, «Юк, үләргә теләмибез — безнең яшисе килә! Я-ш-и-с-е к-и-л-ә!» дип әйтерсең лә кулына автомат күтәргән Палестина балалары кычкыра!

Әйе, бер генә җитди теманы да, монысы балалар өчен түгел, дип читләтеп булмый. Хикмәт шуңа үз ачкычыңны таба белүдә. Иҗатның уй-хыялны кабындырып торган көче әнә шундый бурычлар куеп яшәүдә, яңа сыйфат, яңа биеклекләргә ирешеп яшәүдә. Шагыйрь иҗатыннан мондый мисалларны шактый китереп булыр иде.

Р.Миңнуллинның — телевидениедән «Шигъри тәлгәшләр» тапшыруын 1976 елдан бирле даими оештырып, балалар әдәбиятын моңача булмаган эзлеклелек, колач һәм тирәнлек белән пропагандалавы аеруча игътибарга лаек. Бу тапшыруның киләчәге зур, моннан соң да бик күп балаларның күңел юлдашы булып яшәр ул, яңадан-яңа буыннарны үзенә каратыр, шигърияткә тартыр.

Р.Миңнуллин балалар поэзиясенә гомерен багышлаган, балалар өчен яратып иҗат итүче, бар табигате белән балалар шагыйре булган бәхетле кеше. Мин аның зур киләчәгенә ышанам һәм өмет белән карыйм. М.Җәлил премияләре тарихында беренче тапкыр балалар өчен язылган шигырьләр тәкъдим ителде. Роберт Миңнуллин шигырьләре шул беренчелеккә бик туры килә дип исәплим. Балалар әдәбиятының бишеге янында торган, аның үсүе турында кайгырткан Муса Җәлил дә, сиксәненче елларда илһамланып иҗат итүче талантлы шәкертен күрсә, ихлас сөенер иде, «традицияләрне лаеклы дәвам итәсез, яшьләр, матур үстерәсез» дип хуплар иде!

Шәүкәт Галиев

1982

Бәйрәмле өй

Авыл урамы буйлап атлыйм. Ирексездән бер йорт каршында тукталып калам. Бу чаклы да күркәм, чәчәкле-бизәкле итеп аны салу өчен чын оста, чын тылсымчы булырга кирәктер. Өйнең ямен тагын да арттырып, аның тәрәзәләреннән балаларның шатланып уйнаган тавышлары ишетелә.

Нәкъ менә шундый уй кичердем мин Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән «Балачак бәйрәмнәре» дип исемләнгән шигырьләр җыентыгын укып чыкканнан соң. Күптән инде балалар үзләренең яраткан шагыйрь абыйлары итеп таныган һәм үзе дә нәни дусларын бөтен күңеле белән яраткан Роберт Миңнуллин хыялында туган бәйрәмле өй ул. Әйдәгез, сезнең белән бергәләп шушы өйнең кояшлы тәрәзәсенә күз төшерик.

Тәрәзәмне ачуга,

Безгә яз килеп керде,

Елмаеп-көлеп керде.

Керде дә гөлне күрде,

Күрде дә килеп кунды,

Килеп кунуы булды,

Гөл дә тиз җаен тапты —

Тотты да чәчәк атты, —

ди шагыйрь самими җылылык белән. Яз сулышы белән өртелгән шушы мөлаемлык шигырьдән шигырьгә күчә.

Бу бигрәк тә аның Ленинга багышланган шигырьләрендә ачык чагыла.

Без бәхет турында гына

Җырларга тиеш!

Һәм үсәргә тиеш җирдә

Бәхетле килеш!

Бәхетле чорыбыз өчен,

Бәхетле җиребез өчен

Мең рәхмәт, Ильич!

Кадерле Ильич! —

дип яза ул «Рәхмәт сиңа, Ильич!» дигән шигырендә. Ильичка олы мәхәббәт хисе, аның үрнәгендә яшәргә һәм укырга омтылыш «Ленин бабай», «Кокушкино», «Ул гади малай булган» кебек шигырьләрендә тагын да үстерелә.

Балачак бәйрәмнәренең гомер буена безне озатып барганы, әлбәттә, сабантуй. Шагыйрь үзе дә кечкенәдән үк сабантуйда катнашып, аның төрле хикмәтләрен күреп, көрәшеп үскән. Аның шушы халкыбызның буыннан буынга калган матур бәйрәменә багышланган шигырьләрен укыгач, күңелдә көрәш дәрте уяна. Йөгерешәсе, узышасы, колга буйлап менәсе һәм бил алышасы килә башлый.

Бар да бүләк алалар:

Йөгереп тә алалар,

Көлдереп тә алалар... —

ди шагыйрь, шаян елмаеп. Хәер, без дә бу бәйгедә бүләксез калмадык. Бүләкнең әле ниндие — шагыйрьнең шигырьләре...

Җыентыктагы һәр шигырь гади һәм җор тел белән, шаян юмор хисе белән, истә калырлык итеп язылган. Шагыйрь иҗатын нәни дусларының шулай яратуы күп яктан шуңа да бәйледер, минемчә. Ул шигырьләр балалар дөньясының үзе кебек табигый, җырлы-уенлы, күңелле һәм әкиятле...

Яшәгән, ди, булган, ди, Ничекнигәниөчен атлы берәү, гөр китерә, ди, бу өен... Шуннан ни булган? Калганын сөйләп тормыйм. Сез анысын шагыйрьнең китабын кулга алгач, үзегез укып белерсез һәм анда бик хикмәтле, гыйбрәтле шигъри әкиятләр һәм балачак иленең үзе кебек шат шигырьләр белән танышырсыз.

Шагыйрь хыялында туган бу өй әнә шундый бәйрәмле.

Илдә — бәйрәм! Өйдә — бәйрәм!

Менә шуңа күрә без

Шатланабыз, сөенәбез,

Елмаябыз, көләбез! —

дип, шагыйрь абый безне бәйрәмгә чакыра. Ә аның бәйрәмле өенең ишеге һәрчак ачык. Аннан күңелле җыр ишетелә:

Уртак безнең бәйрәмебез!

Уртак Туган илебез!

Госман Садә

1985

Күңел тәрәзәләре

Сабантуй бәйрәме... Мәйдан уртасында — шома, озын колга. Колгада — әтәч. Җирне, кешеләрне шулкадәр биеклектән күргәне булмагандыр әле — аптыраган кыяфәт белән аска караган. Кем менеп алыр аны? Бүләккә — әтәч!

Кайсы авылда, кайсы шәһәрдә бара соң бу бәйрәм? Хәер, анысы әллә ни мөһим дә түгел. Сабантуй кайда да Сабантуй инде ул. Олы бәйрәм!

Колгага менүчеләр күп. Менеп кенә җитә алмыйлар. Менә мәйданга бер малай чыга. Үзе шаян, үзе... Йөзендә хәйләкәр елмаю. Учына төкереп ала да колгага ябыша ул. Алса, бу ала инде әтәчне. Һәм, чыннан да, җитез генә үрмәләп менеп тә китә малай. Тик нигә әтәчкә килеп җиттем дигәндә генә туктап калды соң? Менә хәзер...

Менә хәзер без дә туктап бераз тын алыйк әле. Хикәятне дә туктатыйк. Ахырына кадәр сөйләсәң, сезгә дә кызык булмас бит. Бу шигырь кебек дистәләгән кызык, гыйбрәтле шигырьләр — шагыйрь Роберт абыегыз Миңнуллинның Мәскәүдә «Детская литература» нәшриятында рус телендә чыккан «Тәрәзәдән карый бер кеше» («Глядит в окошко человек») исемле китабында... Аны кулыгызга алгач теге шаян малай белән дә танышырсыз, әллә нинди кызыклы вакыйгаларга тарырсыз, яңа дуслар табарсыз.

Китап күренекле рус совет шагыйре Сергей Михалковның кереш сүзе белән ачыла: «Күңелсез китапларны беркемнең дә укыйсы килми, — дип яза ул. — Хәтта алар бик акыллы һәм файдалы булсалар да... Ә Роберт Миңнуллинның шигырьләре кызыклы һәм мавыктыргыч...»

Шагыйрь балаларның тормышын бик шәп белә, чөнки ул озак еллар «Яшь ленинчы» газетасында эшләгән.

Шуны да искә алырга кирәк: китаптагы шигырьләрнең күбесе үз вакытында безнең газетада басылды. Ә хәзер алар шагыйрә Эльмира Блинова тарафыннан русчага тәрҗемә ителеп, тагын да меңләгән балаларны сөендерә.

Газетабызның күптәнге дусты, республика комсомолының М.Җәлил исемендәге премиясе лауреаты Роберт абый Миңнуллинның бу яңа китабын укыгач, һичшиксез, сез дә куанырсыз, хөрмәтле укучылар. Ә теге шаян малай белән дуслашып, серегез килешсә, ул сезгә колгага менү серен дә чишәр әле. Колгага менеп бүләк алу һәркемнең дә изге хыялы бит ул. Күңел тәрәзәләрең генә кояшлы булсын.

Ркаил Зәйдуллин

Безнең өй зоопаркы

Редакциягә Актаныштан мондый хат килеп төшкән иде: «Хөрмәтле абыйлар, апалар! Сезгә бер үтенеч белән язам. Безнең авылга цирк йә зоопарк җибәрегез әле. Без шәһәр малайларыннан кайсы ягыбыз белән ким?! Безнең дә көн саен маймылларны, филләрне күрәсебез килә. Авылда ул җанварларга әйбәтрәк тә, рәхәтрәк тә булыр иде.

Мин зоопаркка урын да карап куйдым инде. Кәнушнәй яны бик әйбәт булыр. Кәнушнәйдә бер-ике ат кына торып калды. Алары да өйрәтелмәгән — кыргыйлар. Ул ат-тайларны берочтан зоопаркка ябып куярбыз.

Җәйдә үк җибәрегез зоопаркны!

Сәлам белән Фердинанд Б.».

Кызганыч, Фердинандның үтенечен канәгатьләндереп булмады. Казан зоопаркы аларның авылына күчәргә бик теләсә дә, бара алмады. «Бездән башка шәһәр балалары нишләр?» — дип пошаманга калдылар.

Без дә, малайның өметен өзеп, җавап хаты язарга базмадык. Ләкин көннәрдән бер көнне Фердинандтан янә хат килеп төште: «Исәнмесез, абыйлар, апалар! Цирк белән зоопаркны җибәрмәсәгез дә сезгә ачу сакламыйм. Уйладым-уйладым да ялгышканмын дигән фикергә килдем әле: цирк белән зоопарк безнең авылда гына булса, башка авыллар үпкәләр. Булгач-булгач, барысына да булсын! Ә Казан зоопаркы калсын кала малайларына. Мин үземә өйдә зоопарк ачтым. Ничек дисезме?!

Роберт Миңнуллин дигән шагыйрь абыйның «Безнең авыл зоопаркы» дигән яңа китабын укыгач ачтым мин аны.

Шәһәр малайларының

Күргәне юк гомергә

Бездәге җәнлекләрне,

Бездәге кош-кортларны.

Теләсәләр күрергә

Килсен алар авылга,

Аптыраашта калырга!

Шәһәр малайлары кадәр шәһәр малайларын аптыраашта калдырырлык җәнлек, кош-кортларыбыз бар икән, нишләп әле ачмаска ул зоопаркны. Алар, әлбәттә, читлек эчендә яшәмиләр. Читлекнең кирәге дә юк. Ачуын чыгармасаң, сыер сөзми бит, үртәмәсәң, күркә дә чукымый. Ә инде...

Курыкмагач,

Син дә үртә!

Күрсәтер ул

Сиңа күркә!

Сыерның читлектә яшәмәве кайбер малайларга кыенлык тудыра тудыруын...

Безнең сыер

Бигрәк сөзгәк —

Тәртипсезрәк

Малайларны

Йөри күзләп.

Сөзәргә дип

Йөри эзләп...

Аксакал шикелле вәкарь белән атлаучы кәҗәләрне, канат очларын тәвәдән дә матуррак итеп җәйгән күркәләрне, аяк тибеп ачулана белгән бәкәйләрне күреп, шәһәр малайлары миннән һичшиксез көнләшәчәк. Менә бу зоопарк ичмаса, диячәкләр. Зоопаркның да ниндие әле: теләсәң, җәнлекне сыйпый аласың, уйный аласың, җим сибеп, печән биреп сыйлый аласың.

Минем бу зоопаркым күптән булган. Күрмәгәнмен генә. Шагыйрь абыйның китабын ачкач, күзләрем ачылды да, өйдәге зоопаркны ачтым. Исемен дә табышты китап: «АБЗАРПАРК». Абыйлар, апалар! Минем кебек зоопарк сорап язучылар булса, шул китапны җибәрегез. Үз өйләрендә менә дигән зоопарк барлыгын белсеннәр.

Сезгә үтенечем бар: шагыйрь абыйга миннән һәм әбидән рәхмәт тапшырсагыз иде. Бигрәк тә әбидән инде. Әби әйтә, шәп китап язган ул абыең, ди. Үзгәртте дә куйды ул сине, ди. Җил куып, сукбай булып йөри идең, хәзер кәҗәмә тикле савып бирәсең, рәхмәт яусын ша-

гыйрьгә, ди. Әйе, мин кәҗә дә савам, нигә саумаска?! Шәһәр малайларына андый бәхет тәтеми дә ич. Сәлам белән Фердинанд. Актаныш».

Фердинандның хатларын Ләис Зөлкарнәев укыды

1988

## Авылда, зоопаркта

Борын-борын заманда түгел, безнең көннәрдә генә яшәгән, ди, бер бабай. Аның берсеннән-берсе җитез, берсеннән-берсе елгыр җиде улы булган, ди. Көннәрдән бер көнне бабай улларын үз янына җыйган.

— Сезгә әйтергә теләгән сүзем мондый, оланнар, — дигән ул. — Әле күптән түгел генә Татарстан китап нәшриятында «Безнең авыл зоопаркы» дигән китап чыкты. Аның авторы барча балаларның яраткан шагыйре Роберт абыегыз Миңнуллин. Авыл зоопаркындагы җәнлекләр шәһәрдәге кебек читлекләрдә интегеп ятмыйлармы икән? Белешегез әле. Әгәр шулай икән, аларны тизрәк коткарырга, ireккә чыгарырга кирәк...

Малайлар юлга җыенган. Үзләре белән шагыйрьнең китабын да алганнар. Бик озак барганнар алар. Бара торгач, шагыйрь абыегыз әйткән авылга килеп җиткәннәр. Әмма бернинди дә зоопарк күрмәгәннәр.

Урман янындагы болынлыкта бик күп сыерлар, бал кортлары, кошлар күргәннәр. Инеш буенда үрдәкләр, бакалар, тайлар, атлар очраган. Иң гаҗәпләндергәне дә, иң шатландырганы да шул булган: барча кош-корт, барча мал-туар иректә йөри, ди, биредә.

Кичен, көтү кайткач, дуслар яңадан бергә җыелганнар. «Ә зоопарк, читлектәге җәнлекләр кайда? Кемне коткарырга соң?» — диешкән алар. Шунда берсе: «Шагыйрь абыйның китабын янә игътибар белән укып чыгыйк! Ялгыш язмаган микән ул?» — дигән. Батырлар китапны рәхәтләнеп укыганнар һәм... барысын да аңлаганнар. Роберт абыйлары мал-туар асрый торган абзарны зоопарк дип атаган икән ич!

Мен-нә бит ул ничек! Шуннан соң малайлар бик нык сөенешкәннәр һәм, дуслары күбәюенә куанып, китаптагы башка шигырьләрне дә укырга керешкәннәр.

Ирек Нигъмәтҗанов

1989

## Игелек кылу бәхете

Сезнең гүзәл Сөн буйларын күргәнегез бармы? Сөн елгасының ике як ярында җәелеп яткан чәчәкле болыннар, шомыртлы, карлыганлы, кура җиләкле һәм Сөн буйларында гына үсә ала торган татлы юалы әрәмәләр мәңгелекнең үзе кебек борынгы һәм сәнгатьнең үзе кебек гүзәл. Бу яклар — табигатьнең бөек иҗат җимеше.

Үз туган җирен, туган төбәген назлы хисләр белән тоеп яши алу — кешенең иң зур бәхете. Танылган татар шагыйре, татар балалар әдәбиятының тарихи эстафетасын ышанычлы һәм лаеклы рәвештә алга таба алып баручы Роберт Миңнуллинны мин әнә шундый зур бәхеткә ия әдип дип санар идем. Әйе, шагыйрьнең үз иҗатында туган якларны, атаклы Сөн буйларын, Башкортстанның Илеш якларын сагынып, өзгәләнеп, яратып, кадерләп җырлый алуы аның иң зур бәхете ул. Татар халкы күңеленә хуш килгән җырларында булсын, олыларга багышланган шигырьләрендә булсын, матбугаттагы чыгышларында булсын, Роберт Миңнуллин үзенең туган төбәген, Сөн буйларын, димәк ки, олы мәгънәдәге Туган илне, Ватанны мактый, шуны зурлый. Мондый әсәрләр туган телгә һәм гореф-гадәтләребезгә нигилистик карашларга бай булган бүгенге заманыбыз өчен сусаганга су бирү кебек кирәкле гамәл. Мин үзем Роберт Миңнуллин иҗатының буеннан-буена сузылып килгән ике образга сокланам: аның берсе туган як образы булса, икенчесе — Ана образы. Р.Миңнуллин үзенең җырларында һәм шигырьләрендә татар халкы мең еллар буе иҗат итеп килгән Ана образын камилләштерүгә тиңдәшсез иҗади көч куйды.

Шулай да... Шулай да Роберт Миңнуллинның төп иҗат юнәлеше, иҗатының иң көчле мавыгуы, сулышы, яшәеше — балалар әдәбияты, балалар шигърияте. Бүгенге көндә мин татар әдәбиятында Шәүкәт Галиевләрдән соң килгән яңа буын язучылар арасында балалар әдәбиятына Роберт Миңнуллиннан да ныграк бирелеп, бөтен иҗади фидакарьлеген шушы жанрга багышлап яшәүче бер генә әдипне дә әйтә алмыйм. Сүз дә юк, бездә татар балалар әдәбияты өлкәсендә эшләүче сәләтле, уңган һәм нәтиҗәле иҗат итүче язучылар бар — бу безнең әдәбиятның бәхете һәм уңышы. Роберт Миңнуллин әнә шул чын мәгънәсендәге фидакарь язучылар төркеменең иң алгы сафларында. Мин бүген бу мәкаләмдә шагыйрьнең шигырьләрен искә төшереп, аларның эчтәлекләрен сөйләп торасым килми. Бәхеткә каршы, әдипнең һәр китабы, һәр җыры, һәр шигыре укучыга таныш. Аның исеме һәм иҗаты инде илебезнең татар җәмәгатьчелегенә киң билгеле. Шагыйрь китаплары Татарстанда туган телдә басылу белән бергә Мәскәүдә рус теленә тәрҗемә ителеп тә дөнья күрә. Шулай итеп, татар шагыйренең исеме тугандаш халыкларга да билгеле.

Соңгы ун ел эчендә Р.Миңнуллин үзенең иҗатын гына түгел, ә бөтен җәмәгать эшчәнлеген дә тулысынча балаларга багышлап яши. Ул, Республика балалар фонды председателе буларак, безнең бәхетсезлеккә дучар булган балаларыбызга ата-аналарча игелекле ярдәм кулы суза. Бу яктан мин әдипнең эшчәнлегенә чын күңелдән игелекле, изге бәя бирер идем. Шул ук вакытта менә ничә ел инде Р.Миңнуллин ТАССР Язучылар союзы идарәсенең балалар әдәбияты секциясенә җитәкчелек итә. Ул «Яшь ленинчы» газетасының редакторы да.

Быел Р.Миңнуллин иҗаты Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә тәкъдим ителде. Әле дә хәтеремдә, 1972 елда ТАССР Язучылар союзы партия оешмасының гомуми җыелышы балалар язучысы Шәүкәт Галиевнең иҗат отчеты турындагы мәсьәләне карады. Төп докладчы итеп мин билгеләнгән идем. Шунда мин гаҗәеп зур традицияле, тугандаш әдәбиятлар арасында иң зур үсештәге татар балалары әдәбиятын тудыручы бер генә язучыбызның да Г.Тукай исемендәге бүләккә тәкъдим ителмәгән булуына ризасызлык белдердем һәм, балалар язучыларыбыздан беренчесе буларак, Ш.Галиевнең шушы премиягә лаеклы икәнлеген әйтеп чыктым. Җыелыш бу тәкъдимне хуплады һәм Ш.Галиев 1972 елгы премиягә лаек булды. Аннан соң инде 18 ел вакыт үткән. Әдәбият үскән, балалар әдәбиятының Рөстәм Мингалимов, Роберт Батулла, Хәкимҗан Халиков, Җәүдәт Дәрзаман кебек җитди вәкилләре үсеп җиткән. Бу еллар эчендә Роберт Миңнуллинның балалар поэзиясе өлкәсендәге эшчәнлеге чын мәгънәсендә һәм әдәби, һәм иҗтимагый күренеш буларак өлгереп җитте.

Кеше бәхете — кешегә игелек кылуда, ярдәм итүдә һәм аны үстерүдә. Роберт Миңнуллин иҗаты нәкъ менә шул юнәлештә бара, аның китаплары кешегә бәхет юрыйлар, бәхеткә дәшәләр һәм шул бәхетнең булуын бик тә телиләр. Кешене бәхетле итүдән дә игелеклерәк эш юктыр да ул дөньяда.

Без бүген татар балалар әдәбияты Роберт Миңнуллин иҗаты белән үзенең олы бурычын үти алды һәм бу иҗат, һичшиксез, ТАССРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек дип ышанып әйтә алабыз!

Гәрәй Рәхим

1990

Рәхмәт сиңа, шагыйрь!

Минем Алсу белән Нияз исемле оныкларым бар. Нияз мәктәптә укый гына башлады әле, Алсу балалар бакчасына йөри. Абыйсыннан күреп, китап җене кагылган үзенә. Беркөнне Алсу яныма Роберт Миңнуллинның «Безнең авыл зоопаркы» дигән китабын күтәреп килде. Алган гына идем әле, укырга да өлгермәгән идем. Татарча китапны беренче күрүе икән, алты яшьлек Алсуыбыз хәрефләрне кушып укып-укып карады да, аңламагач, укы да

укы, дип бәйләнә башлады. Икесен ике ягыма утыртып, китапны укый башладым. Мәктәптә, балалар бакчасында русча гына тәрбияләнгән оныкларым, өйдә татарча сөйләшсәләр дә, китапның бөтен серен, моңын аңлый алмыйлар иде, әлбәттә. Алар, мине сүз саен туктатып, шигырьнең русчага тәрҗемәсен сорый башладылар. Мин оныкларым белән бергә балалар дөньясына кереп киттем һәм бик рәхәтләнеп, бик мавыгып балаларыма гади һәм серле дөньяның пәрдәсен ачтым.

Бигрәк тә китапның «Көтү кайта авылга» дигән бүлеге ошады.

Шәһәр малайларының

Күргәне юк гомергә

Бездәге җәнлекләрне,

Бездәге кош-кортларны...

Без бу китаптан көне буе кешегә ярдәм итә торган атлар белән дә, колыннар, яшь тайлар белән дә, кәҗә-сарык, әтәч-тавыклар белән дә, каз-үрдәк белән дә таныштык, сыерның һәммәбезгә сөт эчертүен, күркәнең ысылдавын белдек, йомры-йомшак каз бәбкәләрен күрдек, этләр, мәчеләр белән уйнадык. Боларның берсен дә якыннан күрмәгән шәһәр балаларына гаҗәеп дөнья ачылды. Шунда мин шагыйрьнең осталыгына хәйран калдым. Балаларның дөньяны танып белүен арттыру өчен нәкъ менә шушылай, гади һәм образлы итеп, фикерле һәм тылсымлы итеп язарга кирәк икән.

Ниязга бигрәк тә «Аптыраш!» дигән бүлектәге шигырьләр ошады. Менә «Булмаган, ди, бер малай» шигыре. «Ничек инде булмасын, менә бит мин, — ди Нияз, — мин укыйм да, җырлыйм да, көләм дә, юк, шагыйрь абый шигырьне дөрес язмаган», — ди. Шигырьне тагын укыйбыз, сорау артыннан сорау биреп кенә торалар балалар, ахырдан гына, әле ул малайның тумаган булуы гына ышандыра аларны. Бу бүлектәге шигырьләрне без кат-кат укыдык, аптырап беттек, уйландык, табышмакларын таптык, кыска шигырьләрне ятладык.

Рус мәктәбендә укыган, русча сөйләшкән татар балаларына туган телне өйрәтү өчен иң уңай китап — шагыйрь Роберт Миңнуллинның балалар өчен язган китаплары дип һич икеләнүсез әйтәм. Алар телнең матурлыгын, аһәңен тоя белергә ярдәм итәләр, тирә-якны танырга да булышалар, балалар дөньясының эчендә кайнарга, алар күзе белән күрергә, катлаулы төшенчәләрне дә гади итеп аңларга ярдәм итәләр. Бу кыска мәкаләдә мин шагыйрьнең бөтен иҗатына күзәтү ясауны максат итеп куймадым. Минем өчен иң мөһиме Роберт шигырьләренең балаларда татар теленә, татар китабына мәхәббәт уята алуы булды. Балалар шагыйренең Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә тәкъдим ителүе — бик шатлыклы күренеш. Бу, беренчедән, бездә балалар әдәбиятының югарылыгын күрсәтсә, икенчедән, шушы югарылыкны үз җилкәсендә тотучыларның берсе буларак, Роберт Миңнуллинның милли политикабызны тормышка ашыруда тырышып эшләвен күрсәтә.

Кичләр җиткән саен мин, ике оныгымны ике ягыма утыртып, татарча китап укыйм. «Безнең авыл зоопаркы» дигән китап нәниләремнең иң яраткан китабына әверелде.

Рәхмәт сиңа, Шагыйрь!

Венера Ихсанова

1990

Колачында –

җиһан, галәм...

Татар халкында бер гыйбарә бар: җиһанны кочаклап булмый. Шушы урында «ләкин» дип әйтәсе килә. Шагыйрь күңеленә җиһан да, галәм дә сыя. Менә минем бүгенге сүзем дә үзенең йөрәгенә колачлап ала алмаслык җиһанны, меңнәрчә-меңнәрчә йолдызлы галактиканы сыйдырган олуг шагыйрь хакында.

Сез барыгыз да аны әйбәт беләсез. Белү генә түгел, яратасыз. Мин моның шулай икәнен һич шикләнмичә әйтәм. Чөнки көннең-көнендә бертуктаусыз телефон шалтырап тормас иде. Кемнәр шалтыратса да, аның исемен кабатлый:

— Безгә Роберт Миңнуллин кирәк иде.

— Роберт абый безнең мәктәпкә килә алмас микән?

Бу сорауларның һәркайсына үзем шаһит.

Беләләр Роберт Миңнуллинны. Яраталар үзен. Һәркайда көтәләр. Шигырьләрен укыйлар, күңелдән өйрәнәләр, җырларын җырлыйлар, мәктәпләрдә аңа багышлап кичә оештыралар, бәйрәм ясыйлар...

Менә монысы әле яңа гына булды. Безнең бүлмәбезгә бер бабай килеп керде. Хәл-әхвәл аңлашуга аның безнең янга түгел, ә Роберт Миңнуллин янына килүен аңладык.

«Мин үзем Үзбәкстанда яшим, — дип башлады сүзен ул бабай. — Без татар китабына бик мохтаҗ. Татар китабы безгә килми дә килми инде. Менә Казанга татар китаплары алырга дип кайттым. Роберт Миңнуллин китаплары булмасмы дип уйлаган идем. Аның «Дөньядагы иң зур алма» дигән китабы чыккан икән. Бу хакта мин радиодан ишетеп белдем. Шул китапны эзләп Казанда әллә ничә кибетне әйләнеп чыктым. Юк, диләр. Сатып бетердек, диләр. Безгә ул китап әз килде, диләр. Аптырагач, сезгә — «Сабантуй»га килдем. Табып бирегез инде миңа шул китапны...».

Шушы бер очрашу гына да күп нәрсә хакында сөйли... Шагыйрьнең даны Татарстан белән генә чикләнми. Ул ерак, бик ерак чикләргә барып җиткән... Кайда татар яши — анда Роберт шигырьләре, Роберт җырлары яңгырамыйча калмый.

Хәлләремне җиңеләйтә

Әнкәмнең догалары...

Бу җыр безгә — татар мохитенә — иманны алып кайтты. Шушы җыр үзе генә дә татарның татар икәнен аңлатты, аларны җылатты, иртәләрен юатты, күңелләрендә горурлык хисе уятты...

Менә шундый шигырьләр яза, җырлар иҗат итә Роберт Миңнуллин. Саный китсәң, санның очына чыгарлык, колачлыйм дисәң — колачлап алырлык түгел аның иҗаты. Бүген дә, иртәгә дә балалар телендә булачак аның шигырьләре.

Моңа минем иманым камил. Моңа «Сабантуй»ны алучы һәммә укучылар шаһит.

Роберт Миңнуллинны укып үсүләре белән бәхетле алар. Бөтен татар балалары укыган, аларга куаныч, сөенеч алып килгән шагыйрь үзе дә бәхетле, дип әйтәсем килә. Бу колачка җир дә, җиһан да, галәм дә сыя...

Шагыйрь безгә бәхет юллый. Без дә аңа бәхет телик.

Тагын килеп бер сүз әйтим. Роберт Миңнуллинны быел Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә тәкъдим иттеләр. Бу безгә дә сөенеч, сезгә дә күңелле хәбәр.

Госман Садә

1994

Заказное литературно-художественное издание

**Миннуллин** Роберт Мугаллимович

ПРОИЗВЕДЕНИЯ В СЕМИ ТОМАХ

**Том 4**

Казань. Татарское книжное издательство. 2007

На татарском языке

Әдәби-нәфис заказ басма

**Миңнуллин** Роберт Мөгаллим улы

ӘСӘРЛӘР

ҖИДЕ ТОМДА

**4 том**

Мөхәррире Р.Х.Корбанов

Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире Р.Х.Хәсәншин

Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы Н.П.Клипова

Корректоры Г.Х.Сундукова

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 03.12.2007. Форматы 84×108 1/32.

Офсет кәгазе. «Times» гарнитурасы. Офсет басма.

Шартлы басма табагы 27,72 + вкл. 0,84. Шартлы буяу-оттиск 29,51.

Нәшер-хисап табагы 17,79 + вкл. 0,86. Тиражы 2000 д. Заказ С-1260.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.

**http://tatkniga.ru**

**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет JahatTM программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.

420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.